

Шәмсия Җиһангирова

# Якты сагыш



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Җ61

**Җиһангирова Ш.Г.**

Җ61 Якты сагыш: Шигырьләр / Шәмсия Җиһангирова; Кереш сүз авт. Х.Г.Әюп. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 207 б.

ISBN 5-298-03956-1

Шагыйрәнең бу китабына төрле елларда иҗат ителгән, ихлас, эчкерсез, самими хисләр белән сугарылган лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды.

ISBN 5-298-03956-1
©Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Җиһангирова Ш.Г., 2006

## *Якты моңнар иясе*

Минем туган ягымда — Мөслим районының Башкортстан белән чиктәш җирендә — гаҗәеп соклангыч, бай табигатькә сыенып утырган Баек авылы бар. Байтак вакытлар әлеге Баек та, безнең авыл да күрше-тирәдәге бүтән авыллар белән бергә бер колхоз тәшкил итеп яшәделәр. Шуңа күрә Баек халкын беркадәр беләм, аның кайбер сыйфатлары миңа таныш. Бераз кайнаррак, ләкин киң күңелле һәм олы җанлы, өлгер-эшчән һәм бер үк вакытта күңелләрендә нечкә моң йөрткән кешеләр яши анда. Менә шушы кайнарлык, тирән моң кайчан да булса бер ни рәвешледер түгелергә тиеш иде, ул гомергә эчкә йомылып, күмелеп кала алмый иде. Һәм ул чыннан да түгелде... Танылган шагыйрәбез Шәмсия Җиһангирова иҗатына килеп орынсам, аның җырларын тыңласам, шул хакта уйланам.

Аның иҗатын Шәмсия Гарипова чагыннан — Мөслимдә чыга торган «Авыл утлары» газетасында басылган беренче шигырьләреннән үк беләм, «бу бәллүр храмны ялгыш җимермәм микән» дигән сыман сагаеп-сакланып кына шигъриятькә килеп кергән чакларын хәтерлим. Шул кыюсыз беренче адымнарында ук ниндидер бүтәннәргә охшамаган яктылык, җылылык, ихласлык бар иде Шәмсиянең. Республика матбугатында басыла башлагач, аның иҗаты турында өлкән әдипләребезнең җылы-җылы гына сүзләре әйтелде, әдәби җәмәгатьчелек аны шагыйрә буларак таныган, кабул иткән иде инде. Әмма...

Нәшриятта эшли башлагач, миңа «Яшел гармун» исемле повесть укып чыгарга туры килде. Авторы — Шәмсия Җиһангирова. Әлеге повесть барыбыз өчен дә көтелмәгән ачыш булды. Чәчмә әсәрләр язарга да кулы ята икән ләбаса Шәмсиянең! Проза белән язылган шигырь кебек тоелды миңа ул повесть. Дөрес, Шәмсия бүтән бастырмады прозаны, шулай да «Яшел гармун» аның бу жанрдагы соңгы әсәредер дип уйламыйм. Күр-

гәннәре-кичергәннәре, тормышындагы борылыш-сикәлтәләр шигырьләргә-җырларга гына сыеп бетмәстер, алар әлегә авторның җанында җылынып-бөреләнеп ята торганнардыр, мөгаен.

Еллар узган саен гаҗәпләндерүдән туктамады Шәмсия. Көтмәгәндә ул матур-матур җырлар авторы буларак ачылып китте. Хәзер аның сүзләренә язылган җыр яңгырамаган концерт булмый да торгандыр. Тышкы яктан гади генә тоелган, әмма эчтәлеге белән тирән мәгънәгә ия булган, халыкның күпкырлы күңел тибрәнешләрен сыйдырган бу җырларны тиз арада үз иттеләр, яратып өлгерделәр. Җырчылар да һәм җыр яратучылар да. Безнең бу катлаулы-кырыс, рәхимсез заманда шулай җанга шифа булып ятуларының сере бардыр аларның: тирәннән, күңел түреннән, бәгырьдән сыгылып чыгып тамганнардыр ул җырлар, чәчәк таҗларына тамган энҗе чык бөртекләре шикелле...

Эзләнүдән, иҗат дәрте белән янудан туктап тормый Шәмсия Җиһангирова. Әле аның балалар өчен язылган, һәрберсе үзенә күрә бер сер сандыгын хәтерләткән матур-матур шигырьләре барлыгын да укучылар онытмаганнардыр дип беләм. Шуның өстенә ул Татарстан радиосында редактор буларак та тыңлаучы күңеленә үз сукмагын салды, бәйрәм булырдай тапшырулар бүләк итте.

Кыскасы, сүземнең башында искә алган Баек авылы кешеләренең, мөслимлеләрнең күңел матурлыгын, җан җылысын халкыбызның уртак рухи байлыгына куша алды Шәмсия Җиһангирова. Шуның белән бәхетледер дә ул. Яңадан-яңа иҗат уңышлары, сүрелмәс илһам шулай гомерлек юлдаш булсын аңа.

*Харрас Әюп*

*Рәхмәт сиңа,*
*сөю,*
*телгәләдең...*



* * *

Шигырь ул — күңелнең Коръәне,
Эзләмә син аннан чыгарма.
Аны бит һәр шагыйрь күңеленә
Күкләрдән иңдереп куйганнар.

Шигырь ул — күңелнең Коръәне,
Тәфсилләп укы һәр сүрәсен.
Укырсың. Үтәрсең. Түзәрсең.
Һәр әйткән сүзенә күнәрсең.

Шигырь ул — күңелнең Коръәне,
Төзәтмә кертергә ярамый.
Акыллы — укый да килешә,
Акылсыз — үлсә дә аңламый.

Шигырь ул — күңелнең Коръәне!
Карама шигырьгә,
Карама шагыйрьгә санламый!

*4.02.2005*

* * *

Яшь чагында, әйтегезче,
Кайсыбыз соң сөймәгән,
Әллә кемгә язганнарга
«Язмышым син!» димәгән.

Минем дә бит бу якларда
Сөйгән ярым бар иде...
Ул чак җиһанда кыш булмый,
Гел мәңгелек яз иде.

Баш очында бер болыт юк,
Аяз күк кебек иде...
Безне бергә булдырмаслык
Сәбәп юк кебек иде.

...Үткән хисләрем яңарды,
Килеп төшкәч бу якка. —
Язмаган ярым гәүдәсе
Чагылып китте күк чатта...

*2.09.1976*

* * *

Әй, туктагыз!
Берни дәшмәгез!
Ап-ак кәгазь бирегез бары!
Сезне уятасы, уйлатасы,
Елатасы уем уянды.

*18.02.2006*

* * *

Рәхмәт сиңа, сөю, телгәләдең
Парә-парә йөрәк итемне. —
Язларында бөре чыгардым мин,
Көз — өзелдем яфрак шикелле.

Шөкер, мине тыныч яшәтмәдең —
Яндырдың, көйдердең, тилмерттең...
Сикәлтәләр, дәрья-сулар аша
Ялгышларга каршы йөгерттең.

Каһәрләмим сине, бирмәдең, дип,
Бер минут та тыныч яшәргә. —
Чәч агарсын, әйдә, үтсен гомер, —
Мин ризамын кабат яшьнәргә!

*2.01.2001*

* * *

Күзләремә сөрмә, әй, тартаем,
Урамнарны урап кайтаем...
Җан сөйгәнем гармун уйный тышта,
Ни җан белән йоклап ятаем?!

Урамнарга гына, әй, чыгаем,
Кулларымны аңа сузаем, —
«Яр куйнына иртә кермә!» дигән
Үгет-нәсихәтне бозаем.

Кеше күрер диеп курыкмыйча,
Урамнардан парлап үтәем;
Җан теләгән ярым белән кавышып,
Моңаймыйча гомер итәем.

*30.08.1988*

* * *

Дөрли-дөрли яна-яна
Мәхәббәт утларында,
Күпме йөрдем чык элдереп
Керфегем очларына.

Уйлый идем: яратуым
Бер көн, дип, сизәр әле... —
Керфегемнең очларында
Чыкларым кибәр әле.

Килде дә ул, сизде дә ул,
Урады утларына;
Меңләгән тамчы элдерде
Керфегем очларына.

«Әйдә» диеп салды да ул
Учларын учларыма, —
Чык бөртекләре коелды
Керфегем очларыннан...

«Әче» диләр, «әче» диләр,
Чыннан да әче икән...
Чык бөртекләре дигәнем
Мәхәббәт яше икән.

*16.08.2003*

* * *

Кавыштырды безне август төне —
Тән белән җан бергә кушылды...
Аңламадым: бәхет үземе бу,
Әллә бәхетсезлек шушымы?!

Ачылды җан, бәгырь телгәләнде —
Зая үткән гомер өчендер...
Шул бер төндә мәңге татылмаган
Һәм татылмас хисләр кичердем.

Синең барны сизми калган булсам,
Очрамаган булсаң юлымда,
Үтәр иде гомер, белми генә
Бу рәхәтнең бары турында...

Рәхмәт сиңа, мине бу дөньяга
Тудырганың өчен ихрактан*!
Башладым мин әле яши генә —
Үлеп терелдем дә кабаттан...

*22.09.1989*

---

* Ихрак — ут төртеп яндыру.

* * *

Гомер буе җыйган серләремне
Сөйлисе дә әле, сөйлисе...
Без бит синең белән бер-беребезгә
Каш астында ике күз төсле.

Каш астында ике күз төсле лә,
Бер бәхетне тоткан ике кул.
Гүя бер ананың балалары:
Мин — кыз бала, ә син — газиз ул.

Бер гәүдәгә ике аяк гүя:
Син кая барасың — мин шунда.
Беребездән башка беребез юк,
Мин мең кабат төшендем шуңа.

*24.11.2005*

## *Бер адымга гына...*

Мин йөргәндә уйлап очратырга
Җир йөзенең әллә кай ягында,
Син булгансың икән миннән бары
Бер адымда гына, бер адымда гына...

Уртаклашыр кеше табалмыйча,
Кайгылардан ут йоткан чагында,
Син булгансың икән миннән бары
Бер адымда гына, бер адымда гына...

Гомер юлын синсез кичә алмам —
Бул янымда, гел җанымда гына...
Җирдән киткән чакта син соңга кал
Бер адымга гына, бер адымга гына...

*16.11.1984*

* * *

*...га*

Син булмасаң, бу дөньяның
Матурлыгын тоймас идем.
Уйнак уйлы, шаян сүзле,
Матур йөзле булмас идем.

Син булмасаң, күзләремдә
Янмас иде очкын дөрләп.
Пыскып кына әллә кайчан
Сүнгән булыр иде, көйрәп.

Син булмасаң, белмәс идем
Игелек бар диеп җирдә.
Бәйләмәс идем һәр эшне
Уем белән «мин»гә, «син»гә.

Син булмасаң, яшәү үзе
Гаеп булыр иде миңа.
Барлыгыңа, берлегеңә
Мең-мең шөкер, рәхмәт сиңа!

...Бу фани дөньяда, бәлкем,
Булалмабыз да янәшә. —
Җаның белән ятим булма,
Мәңге яшә, рәхәт яшә!

*28.01.2001*

* * *

Бәхет бит ул, олы бәхет бит ул —
«Сөям!» диеп сузу кулыңны.
Яшьлегеңнең алсу таңнарында
Тиңең белән башлау юлыңны.

Язмышларга сылтап ялгышларны,
Табып уйламаган бер сәбәп,
Җиңел лә ул киту ике якка,
Бер-береңә юкка үпкәләп.

Сөюләрнең мәңгелеге була,
Сөюләрнең булмый яңасы.
Икәү бергә гомер юлы буйлап
Барасы да әле, барасы.

* * *

Синнән элегрәк тусам да мин,
Җаным синең белән бергә туган...
Садә хисләр, син туганны көтеп,
Кабынмыйча торган, янмый торган.

Сулыш өрдең, утлар салдың минем
Сүнәр-сүнмәс торган бу җаныма.
Кая барсам, баскан эзләремдә
Дөрләп торган учак-ут кабына.

Бәхет дәррәү килгәч авыр икән, —
Хәтта шатланырга да куркыта.
Төннәр белән көнне саташтырып,
Сине бер күрергә утлар йотам.

Киләчәген белмим. Тик хәзергә
Гел янәшә атла син янымнан.
Кемнәр белә, бәлкем, соңгы булыр:
Кабат янмам, кабат кабыналмам.

*22.09.1989*

* * *

Белмим: яз таңында иң беренче
Чәчәкнеңме, күбәләкнең микән
Күзе ачылганын.
Беләм: бары синең белән генә
Йөрәк янулары басылганын.

Белмим: карлар китерәме кышны,
Әллә кышмы — карны.
Беләм: меңнәр арасында минем өчен
Синең генә барны.

Белмим: кемнәр ризалыгын күпкә,
Ә берәүләр — азга.
Беләм: бары син булганда гына,
Җаным туя назга...

*16.11.1984*

* * *

Инде кышка җыенып йөргән чакта,
Тәрәзәмнән кояш карады.
Бар җанымны бөтереп алган хиснең
Сөю икәнлеген аңладым.

Туя сөеп калынмады никтер
Гомер язларында, яшьлектә, —
«Син — алиһәм!» диеп әйтмә әле,
Патша да юк монда, тәхет тә.

Очратмасам сине, чын сөюне
Бар дип белмәс идем дөньяда.
Язмыш безне үзе кавыштырды —
Никахы да шулдыр, дога да.

*8.07.2003*

* * *

Сыздырып ла гармун уйнап узды,
Сискәндереп төнге йокымны.
Йөгерепләр чыгып сорар идем:
Сөюләрең, диеп, шушымы?!

Гармун телләренә баскан саен,
Йөрәгемә кучте сагыш-моң.
Кавышу сәбәпләрен уйлый-уйлый,
Сарыларга, ахры, сабыштым.

Уйнап узар микән шулай тагын,
Кара төнгә сихри моң сирпеп.
Яшәтерме мине гомерем буе,
Сөю хисләренә исертеп?!

## *Тик син диеп*

Тик син диеп, яныП-көеп,
Үтә лә гомерләрем...
Үткән гомеремне уйлап,
Ярсына күңелләрем.

Тик син диеп, хисләр өеп,
Утлар ягам наз өстәп...
Ни хәл итим: үз-үземне
Ярattыралмыйм көчләп.

Тик син диеп, җаным көеп,
Нәүмизләнеп, кимләнеп,
Йөргән булам, берәр заман
Аңлар, диеп сөйләнеп...

Тик син диеп өзгәләнәм,
Ут йотам иртә-кичен...
Ике гомер яшәсәм дә,
Янармын синең өчен.

*14.07.1983*

* * *

Үләннәргә чыклар төшеп,
Юа былбыл эзләрен.
Һушларымны ала язды
«Сөям» дигән сүзләрең.

Урман эчләрендә чишмә,
Былбыл кунган ташына.
Сөюләрең чыннан булса,
Мин ризамын барсына.

Кара урман эчләренә
Кердем урау юллардан.
Ни күрсәк тә, аерылмасын
Кулларыбыз куллардан.

Юл буйлары — кара шомырт,
Җимешләре — җирләрдә.
Бәгърем, бергә булсак иде
Без алдагы көннәрдә.

Шомырты кара булса да,
Ак була чәчәкләре, —
Ак шомырт чәчәкләредәй
Булсын киләчәкләре.

* * *

Яныма ук килеп утыр,
Сыен миңа, якыным,
Кушыйк шулай ике утны,
Ике йөрәк ялкынын.

Берләштерик уй-хисләрне,
Якынайтыйк араны.
Яратыйк әле, яратыйк,
Бернигә дә карамый.

Безгә карап, якынлыкның
Ни икәнен белсеннәр, —
Ярларына безнең кебек
«Якыным син» дисеннәр.

Икебезнең якынлыктан
Якынайсын йөрәкләр.
Мин ышандым, син дә ышан
Минем сиңа кирәккә.

«Якыным» дип дәшсәм сиңа,
Якыная аралар.
«Ярым» диеп дәшсәм сиңа,
Җаннар бергә яналар.

*13.10.2003*

* * *

Таңнарда мин изге кояшка бакканчы
Багамын синең газапсыз йөзеңә,
Барча диңгезләрдән серле вә тирән
Һәм дә салкын бөркелгән күзеңә.
Сыенамын синең йомшак тәнеңә,
Балалыкта әнкәмә сыенган кеби;
Әмма никтер шул тәнеңнән җаныма
Яшәү нурлары күчми бер-бер вә килми.
Чыгып китсәң, гәүдәңне миннән аерган
Салкын ишек тактасына сарылам еглап;
Артыңнан чыгып йөгерми чак тыелам,
Кичен бер яныма кайтырың барлыгын уйлап.
Аптырыйм: нинди көч вә сихер берлән
Ябыштырдың садә җанымны үзеңә.
Миндәй шашып ярата алмыйсың беземе
Ни сәбәпләрдән соң? Ник? Нигә?
Юкса минем кимме хур кызыннан
Ходай бирмеш каш-күзләрем, буй-сыным?
Артымнан ник кала соң сезнең зат
Пышылдап: «Кайдан, дип, бу сылу?!»
Акыл-фигылем, гамәлем азат хыйлафтан,
Уем җитмәгән юктыр бер өлкә;
Иренемнән өзелгән һәр кәлимә сүз
Ир дигән асыл затларны тилертә.
Бишәр бармаклы ике кулым
Төйми генәдер төймә: бәйли, тегә, пешерә,
Юа, сыйпап-иркәли, назлыйдыр һәм сөя.
Күңелем чиста, рухым саф,
пакьтер җаным, —
Эзләп тә табалмассың һичбер кара вә кер.
Иза чигәм булмагангамы үз-үземне ярату,
Хәйләм, хөсетлек вә мәкер.

...Әйткән бит урыс:
«Насильно мил не будешь ...» — дип,
Дөрест вә хактыр, ахры, бу тәгъбир...
Көтеп тормактамын: тагын ни язган, дип,
Без фәкыйргә рәхимсез бу тәкъдир...

*17.04.1998*

* * *

Синең белән бергә яшәү
Дөрес түгелдер сыман, —
Көненә мең аерылам,
Көненә мең кушылам.

Көненә мең киңәш сорыйм
Кеп-кечкенә йөрәктән,
Гел шикләнеп кенә торам
Минем синә кирәктән.

Дөрес түгел кебек синең
Сөйләгән бер сүзең дә...
Мөлдер-мөлдер миңа юри
Карый кебек күзең дә...

Гел шикләнеп кенә торам
Алып китәр дип ятлар...
Кая китте дип сагынам
Шиксез яшәгән чаклар.

Тагын мең төрле шигемне
Куа-куа таратам...
Тик бернәрсәдә шигем юк —
Өзелеп-өзелеп яратам!

*23.03.1998*

* * *

Мин яратам сине. Шулай өзелеп
Яраталмас кебек беркем дә.
Иртәләрен син дип күзем ачам,
Көн буена йөртәм исемдә.

Әгәр син дә мине шулай сөйсәң,
Утлар йотсаң минем өченгә, —
Кил каршыма, әйт «яратам» диеп,
Көттермә син, озак көттермә.

Үтә кызыл бик тиз уңа, диләр, —
Безнең сөю алай булмасын.
Чәчебезгә чаллар кунса кунсын,
Мәхәббәткә керләр кунмасын.

Ихлас булса хисләр, сөю үтмәс,
Арта гына барыр елдан-ел.
Җил-давыллар каршы тора алмас,
Тотынышып барсак кулга-кул.

Мин яратам сине, ә син мине —
Бәхет өчен тагын ни кирәк?!
Кулларыбыз — кулда, иңнәр — иңдә,
Җанда — җаның, йөрәктә — йөрәк.

Арабызга кеше сүзләре дә,
Усал җилләре дә үтмәсен.
Яшьлегебез, әйдә, үтсә үтсен,
Тигез сөю генә үтмәсен!

Тормыш дигән тирән бу диңгезне
Икәү бергә парлап кичик без,
Газап-ширбәтләрен уртак татып,
Картлыкка да парлап күчик без.

* * *

Мәхәббәтне әче диләр, —
Шулайдыр. Мин дә тоям. —
Сине яратканым өчен
Көн-төн тозлы яшь коям.

Шул тоз тәме иренемдә,
Җанымда, йөрәгемдә...
Сагыну-сагыш — көннәремдә,
Әче яшь — төннәремдә.

Гел тозлы булмас яшьләрем,
Беркөн балланыр әле;
Җаныбыз, бербөтен булып,
Мәңге ялганыр әле.

Көнләшеп калырлар бездән
«Без парлы!» дигәннәр дә,
Мәхәббәтне баллы диеп
Алданып йөргәннәр дә...

*4.11.2004*

* * *

Сөям дип, сөймим дип
Узышып яшәргә
Сөюнең юк үлчәү-бизмәне.
Ничә ел үтсә дә,
Зарыгып бетсәм дә,
Бизмәдем мин синнән, бизмәдем.

Көтәм дә, көтмим дә
Килер дип яныма.
Тик сөям өзелеп, җан атып.
Уйласаң гомернең
Мәңгелек түгелен, —
Килерсең син, мине яратып.

Сөюгә юл ерак,
Яшәсәң гел уйлап, —
Чык юлга. Аһ! Соңга калма син.
Гомерләр тиз уза,
Кулыңны суз кулга, —
Үкенечләр булып калмасын.

* * *

Әйдә китик әле урманнарга —
Кеше күрми торган җирләргә.
Күңел бушаганчы сөйләшик бер,
Туйганчы бер карыйк күзләргә.

Әйдә китик әле җир читенә —
Кеше йөрми торганякларга.
Чәчик җилгә бөтен серебезне —
Аны нигә эчтә сакларга?!

Әйдә китик әле берәр җиргә! —
Китми йөрәк барыбер тынмас күк.
Син янымда булсаң, мин бәхетле, —
Кая барсам, шунда оҗмах күк.

...Әйдә китик әле берәр җиргә!

*6.10.1994*

* * *

Мәхәббәт хакына
Барын да оныткан
Дөньяда без генә дисеңме.
Көннәрне нурлатып,
Бәхеткә уратып,
Мәхәббәт яшәтә кешене.

Сөюләр бер генә,
Ян әйдә син, дөрлә,
Яши бел сөюең хакына.
Хисләрең зур булса,
Сөюең чын булса,
Көч җитә түзәргә барсына.

Кулыбыз — кулларда,
Без бергә булганда,
Сүрелмәс мәхәббәт хисләре.
Тиң парлар җирдә без,
Елыйбыз, көләбез,
Ярата беләбез бит әле.

*15.19.2003*

## *Шулайдыр...*

Шулайдыр...
Бик сәер тоеладыр
Сыенасы килүем иңеңә.
Нишлисең, гомерем буена
Язмыштан наз сорап тилмерәм...

Шулайдыр...
Бик көлке тоеладыр
Янарга теләвем «яшьләрчә».
Нишлисең, кабыналмый калынды,
Дөньяда ни гомер яшәп тә...

Шулайдыр...
Бик гаеп тоеладыр
«Кешечә» яшәргә теләвем.
Рәхмәт. Айнытып җибәрде
Чакырып та яныма килмәвең...

Шулайдыр...
Көлке дә, сәер дә
Тоелам мин хәтта үземә.
Нишлисең, янудан тукталып
Булмый шул чәчкә чал иңүгә...

*10.11.1989*

* * *

...Сизеп торам: бу, мөгаен,
Сөйми башлавың инде.
Шул сөйми башлавың өчен
Мине ташлавың инде...

Ташла әйдә, ташла, бәгърем, —
Чара тапкач китүдән.
Азат кыл ләкин җанымны
«Килер!» диеп көтүдән.

*1.08.2001*

* * *

Әгәр минем хакта сорасалар,
Син башыңны түбән иярсең,
«Ярар инде, орышмагыз мине,
Ялгышлык булды ул...» диярсең.

Әгәр синең хакта сорасалар,
Мин башымны түбән имәмен!
Орышу түгел, җаным алсалар да,
«Язмышым ул минем!» диярмен.

*9.10.1989*

* * *

Киттең менә тагын...
Өзелеп калды җаным,
Телем-телемнәргә теленеп...
Күпме шулай дәвам итәр икән —
«Бер күренеп, тагын күмелеп...»

Мәхәббәтнең аның
Җиңәр өчен барын
Көче җитә... Үтмәс ара юк...
Тыным белән тартып алыр идем...
Көчем җитә! Ләкин чара юк!

«Язылмаган» дигән
Канун барын беләм.
Ә мәхәббәт... Нинди канунннан?! —
Китсәң дә син минем яннарымнан,
Җибәралмыйм сине җанымнан!

Шулай үтә гомер...
Үкенеч тә түгел,
Рәнҗү, каргыш түгел үткәнгә. —
Өзелеп яратып та кавышалмыйча,
Сабырлыклар бирсен... көткәнгә.

*1.07.2001*

* * *

Бер генә көн сине күрми торсам,
Сусыз гөлләр кебек янып көям.
Исемеңне саклыйм йөрәгемдә,
Өзелеп яратуның кадерен беләм.

Яратасым килә мәңге-мәңге,
Каршы килми җаным теләгенә.
Башкаемны салам күкрәгеңә,
Сөю-назларымны — йөрәгеңә.

Күңел кошым чут-чут сайрый башлый,
Җанга бәхет иңә, сине күрсәм.
Яратуның кадерен төшенерсең,
Әгәр минем кебек өзелеп сөйсәң.

* * *

Син килдең дә... китеп бардың,
Санапмы мине читкә?!
Китәсең икән — килмә син,
Киләсең икән — китмә!

Үзем: «Килмәсен иде!» — дим,
Ә күзем — тәрәзәдә.
Җитеп сагынам үз-үземне
Җуярлык дәрәҗәгә!

Яшәвемнең бар мәгънәсе,
Сулар сулышым — синдә!
Киләсең икән — китмә син,
Китәсең икән — килмә!!!

*19.05.2000*

* * *

Нигә миңа һаман учлап-учлап
Көтү газаплары эчерәсең?
Өзелеп сөйгән кеше китәмени, —
Китәр өчен булгач, ник киләсең?

Барыбер килә ул, тилмермә, дип,
Әмер биреп буламыни җанга. —
Көтмәгәндә генә килеп кер син,
Көтмәгәндә генә китеп барма.

Мин бит сине бер минут та күрми
Тора алмаганга шулай ярсыйм.
«Кит инде!» дип әйттермәче, зинһар,
Китмә миннән, мәңге кал син, кал син!

*14.06.2005*

* * *

Син берзаман мине онытырсың,
Башка берәү өчен ут йотарсың, —
Синең шундый чагың!
Мин беркайчан сине онытмамын,
Синең өчен генә ут йотармын! —
Минем шундый чагым...

*9.10.1989*

* * *

Көнләмә син мине, көнләмә
Чәчемнән сыйпаган җилгә дә...
Юк кына хәлне дә бар итеп,
Үпкәләр сәбәпләр эзләмә.

Эзләмә, бер бөртек кара тап
Тапмассың саф-чиста күңелемнән...
Һәр уем, һәр эшем-гамәлем
Бер синең исемгә төрелгән.

Төрелгән сөюем хисләре
Бер синең исемгә, җисемгә...
Минем бу дөньяда яшәвем,
Барлыгым да синең өченгә!

Бер синең өченгә таңнарын
Күз ачам бу якты дөньяга!
Ут сүнәр дә... төшәр караңгы... —
Көнләмә. Көттермә. Соңлама!

*25.04.2002*

* * *

«...Дүрт ягың кыйбла...» дидең бүген.
Бик вакытлы әйттең әлдә ярый.
Кыйблам кайсы якта икәнлеген
Шөкрана, мин шәп беләм, наный!

Кешегә «... дүрт кыйбла» теләгәнче,
Төптән уйлап карау ярыйдыр ул; —
Синең кебек сай акыллар гына
Көнгә мең кат кыйбла барлыйдыр ул.

Мин китәрмен туры кыйблам якка...
Син кыйблаңны мәңге табалмассың.
Кыямәт көн җиткәч, мең сорап та,
Ходайдан ярлыкау алалмассың.

*9.04.2003*

* * *

Сугышкан да берәү...
Яраларын бәйләтергә
Табибларга йөри...
Уйлап куйдым:
Минем генә, диеп,
Җан җәрәхәтемне
Беркем күрми, белми...

*16.05.2003*

* * *

Син кайчандыр бүтән идең:
Мине сагынып көтә идең.
Чит күзләрне көнләштереп,
Урамнардан үтә идек.

...Син шул хәзер бүтән инде:
«Булды, — дидең, — җитәр инде...»
Мин йөргәндә синең белән
Гомер юлын үтәр булып...

Ятлар белән аруларың-
Талуларың сүталмассың,
Минем яннан китеп кенә
Үз-үзеңнән киталмассың...

*11.05.1984*

* * *

Син миннән сүзеңне кызгандың,
Син миннән үзеңне кызгандың...
Кулларың назларга иренде,
Иренең — үбәргә иренемне.

Курыктың тәнеңә тән тиеп,
Ут кебек кабынып китүдән...
Мин юкка наз эстәп сыенам —
Өшегән шул җаның, өшегән.

Өшегән җаныңнан җаныма
Бәрелде котыплар суыгы.
Тәнемнең туңуы бер хәер,
Салкыннан йөрәгем куырылды...

*8.01.1995*

* * *

Күңеленә уелып калыр
Минем сагышлы тамгам:
Сагынмам, көтмәм, уйламам,
Өзелмәм, сөймәм, янмам.

Ашыктырма. Бу бәхетле
Көннәр озакка бармас:
Беркем сине «сөям» димәс,
Сагынмас, көтмәс, янмас.

Мин булырмын соңгы аккош
Күңелең күлләрендә. —
Сагышлар булып калырмын
Гомерең күзләрендә.

* * *

Саубуллашмый гына китеп бардың,
Күзләр яфрак сипте эзеңә.
Яңгырлары кунды йөрәгемә,
Сары яфрак төсе — йөземә.

Сызып ташлап мине тормышыңнан,
Яшисеңдер рәхәт тынлыкта...
Җан тынычлыгымны урладың да
Салып киттең мине моңлыкка.

Җиңел генә китә алмас идең,
Сөйгән булсаң мине син шашып.
Кире кайтыр юллар ябылган шул...
Киткәннәргә генә гел ачык!

*27.02.1993*

* * *

«...Күзләреңдә нинди сагыш?» — димә. —
Сагышларның миндә бетәсе юк.
Елый... елый... елый күңелкәем —
Кичләре, көндезе, иртәсе юк.

Күздә генә булса — ярар иде,
Бар җанымны сарган сары сагыш.
...Иңнәремә салып ялгызлыкны,
Кояш баешына китеп барыш.

*17.04.1994*

* * *

Ташлаштык, яратуларга
Булмагач башка чара.
Хәзер инде җан әрнүгә
Мәңге түзәсе кала.

Мине бер генә күрергә
Булганда зар-интизар,
Кемнәргә карар җаныем,
Кемнәргә кулын сузар?!

Яратып китә алырмы
Минем кебек берәрсен;
«Әйе» булса, бу хәлләргә
Ничек кенә түзәрсең?!

Бер җир өстеннән йөрсәк тә,
Әйләндек без чит-ятка. —
Ул «онытты» мин барлыкны,
Мин, имеш, аның хакта.

Сер бирмибез, йөрәкләрне
Киссә дә сөю телеп.
...Тик нигәдер һәр сүз саен
«аһ», «ух»лар килә кереп.

Көтәсе юк: «Аңлашырбыз,
Үтсен генә, дип, ара...»
Чөнки кояш баешына
Гомерләр кереп бара...

*24.10.2003*

* * *

Аерылганга әле минут та юк, —
Борылыштан гына күмелдең.
Әйтерсең лә гомер үтеп китте, —
Инде сагынып та өлгердем.

Юлларыңа каршы чыгыйм диеп,
Биек таулар аша йөгердем. —
Юкса әле тау уртасы гына,
Инде арырга да өлгердем.

Гомер буе шулай...
Йә барып җиталмый,
Йә узып киталмый тилмердем...
Әле яши генә башладым күк,
Сизмәдем үткәнен гомернең.

Булыр микән асылына кадәр
Аңланганы минем күңелнең?!
Көтәм әле һаман, сабыр итәм —
Түзелде... түзәрмен... түземмен!

*30.08.1990*

* * *

Мине сагынудан синең дә
Үзәгең өзеләдер, —
Бу дөньяның аклыклары
Дөм кара күренәдер.

Ничек исә юатыйм дип,
Үзәк өзелүләреңне —
Берәм-берәм саныйсыңдыр
Минсез мизгелләреңне.

Берәм-берәм өзәсеңдер,
Җаныңа тезәсеңдер... —
Мин булсам түзалмас идем,
Син ничек түзәсеңдер?!

* * *

Төнге ут күрсәң тәрәздә,
Минеке дип алданма!
Һәм ышанма үзең уйлап
Чыгарган шул ялганга.

Ут яндырып көткән чаклар
Калды инде бик ерак. —
Ут яндырып ут йотулар,
«Килер» дип һаман юрап...

Ялгыш кына янган утны
Алданма инде күреп! —
Тәрәз түгел, күңелдәге
Утым да бара сүнеп...

*22.01.2002*

* * *

Үзең мине ташлап киткәч...
Ташлап киткәч, ялгыз иткәч... —
Кем генә соң, кем генә соң
Мине синдәй сөя алсын?!

Синсез күпме еллар үттем...
Сагыш эчтем, хәсрәт кичтем... —
Кем генә соң, кем юатсын,
Янымда чит-ят булгачтын?!

...Үткәннәрне кузгатмачы,
Тимә хискә! Уятмачы! —
Яшим әйдә синсез генә! —
Кояш... айсыз... көнсез генә.

Сузма кулың, үрелмә син...
Чайпалдырма — түгелмәсен!
Күңелкәем тулып тора —
Чайпалдырма, чайкалдырма!

...Янган чакта, көйгән чакта,
Җылы сүзең кирәк чакта, —
Кая киткән идең үзең —
Шундый түзем, шундый түзем!..

Кылларыма кагылма син,
Өзгәләнмә, ялынма син! —
Күңелемдә яңгыр ява...
Аязлы-болытлы һава...

*25.04.1982*

* * *

Син сизми дә калдың: мин бит сине
Алып киттем үзем белән урлап.
«Кая китеп югалдым соң?» — диеп,
Йөрисеңдер әле эзләп-юллап.
Бур кеше түгел дә, нишлисең бит,
Түзә алмаганга урладым.
Үзем теләгәнчә иркәләрмен,
Назлап сөярмен дип уйладым.
Ни эшләргә белми торам хәзер:
Бер алам да сине, бер куям.
Ә син серле генә елмаясың,
«Ни майтардың инде?..» дип сыман. —
Кинәт иңгән бәхет аптыратты.
Күнегермен әле берзаман.
Менә ничек әйбәт! Болай булгач,
Мин күрми дә сине торалам.
Телим: тотып җиде күккә чөям,
Телим икән җиргә төшерәм.
Бик теләсәм (булдыралмас димә),
Йөзеңә дә әле төкерәм —
Төкерә алмый дөнья кануныла,
Мине һаман урламаган өчен,
Миннән башка торалганың өчен,
Сине күрми тора алмаганга
Сурәтеңне урлаганым өчен!

*4.02.2005*

## *Син мине күрмәдең*

Син минем иң гүзәл чагымны күрмәдең:
Яшенләп янганын күзләрем.
Син минем иң моңлы чагымны күрмәдең:
Еладым, еладым — түзмәдем...

Син минем иң назлы чагымны күрмәдең:
Аһ орып, ятларга сыендым.
Син минем иң иләс чагымны күрмәдең:
Нур булып күкләргә уелдым.

Син минем иң изге чагымны күрмәдең:
Фал ачып, төшемне юраттым.
Хәзер мин... гап-гади җир заты. —
Югалттың син мине, югалттың!

## *Әле мин сине гафу итмәдем*

Әле мин сине гафу итмәдем,
Иңемә килеп сарыла күрмә,
Күз яшьләреңне күрсәтмә миңа,
Ялына күрмә, ялына күрмә!

Әле мин сине гафу итмәдем,
Өметләр баглап, чәчәк китермә.
Йомшак ла аның күңеле диеп
Гафу үтенмә, гафу үтенмә!

Әле мин сине гафу итмәдем,
Каршыма килеп, башыңны имә.
Яратуымны белеп торасың, —
Кире кайт, димә, кире кайт, димә!

*21.07.1984*

## *Якты сагыш*

Синнән башка үткән көннәремне
Сәгатьләргә бүләм, минутка...
Йөрәгемдә йөртәм сөю хисе,
Син юк инде минем тормышта.
Яннарыңа очып китәр идем,
Ерак инде, ерак аралар...
Гомер адымнарын саный-саный,
Еллар һаман алга баралар.

Син уйлама, яшьлек белән бергә
Уза диеп садә хисләр дә;
Яшәү кадерен тоя башлыйм чынлап,
Син төшкәндә һәрчак исләргә.
Йөрәгемдә яши сөю хисе —
Үткәннәрдән якты хатирә;
Узган гомерең әгәр искә төшсә,
Яшьлегеңдә мине хәтерлә.

* * *

Бер җавапсыз, газиз башымдин
Мең сорау вә дә мең уй ява:
Мин генә яраткан күзләрең хәзер
кемгә бага?
Кулың кемгә «сөям!» дип яза хат?
Көненә мең үлеп, терелә мең кат.
Әйтче, бу халәттән бардыр ни дәва?! —
Кояшым батмактыр чыгышка таба...

*21.04.2004*

## *Орышам*

Иң яман сүзләрне сайлыйм да
Мин гелән үземне орышам... —
Җанымны биздереп җисемеңнән,
Исемеңне онытырга тырышам.

Кай җирдә йөрсәм дә, һәрвакыт
Шат булып күренергә тырышам...
Исемең тибрәтсә — телемне,
Яшь сыкса, күземне орышам!

«Оныттым!» дип кенә тибәргә
Көн саен йөрәккә булышам...
Син мәңге онытылмас булганга
Орышам үземне, орышам...

*22.09.1989*

* * *

Уйла, зинһар, исеңә төшер мине,
Өзелеп сагын, ярат аннары...
Минем инде, дөрләп яна-яна,
Янар чамаларым калмады.

Яши алма минсез бер минут та!
Ә мин... Күптән синсез торалмыйм...
Бу хәлемдә «Икәү бергә!» диеп,
Киләчәккә уйлар коралмыйм.

«Үләм инде!» диеп кычкыр әле,
Мин чыгармын өзелеп каршыңа. —
Янып бетәм инде... янып бетәм...
Риза килеш барысы-барысына!

*11.07.2002*

* * *

Сиңа ярты җаным ярып бирәм,
Бөтенләен бирсәм — үләрмен.
«Юләр лә бу!» диеп аптырама,
Сине яратканга юләрмен.

Телисеңме, күкрәгемне ярып,
Йөрәк тибешемне тыңлатам.
«Дөрес түгелдер...» дип уйлый күрмә,
«Яратам!» дип әйтеп туймасам.

Күңелемне өермәләп алган
Сулар сибеп сүнмәс ут әле.
Минем хәлем аңлашылмас сиңа —
Мин яратам, ә син — юк әле...

Беркөн килеп, сүрәнләнгән җаның
Биләп алыр шушы ут инде...
Ул чак миңа аңлашылмас хәлең —
Син сөярсең, ә мин — юк инде.

* * *

Төнлә төшләремә кереп
Уятма инде мине; —
Элекке кебек өзелеп
Яратмыйм хәзер сине.

Яна-яна көлгә калды
Сөю учагы күптән. —
Сине инде беркайчан да
Элекке кебек көтмәм!

Үткәннәргә кайтулар юк,
Кайтулар юк кабаттан! —
Сине сөйгән кебек, башка
Беркемне дә яратмам!

*22.01.2002*

* * *

Хәзер инде килмәсәң дә була —
Туктадым елаудан...
Күземә ак-кара күренмичә,
Гел сине уйлаудан.

Хәзер инде килмәсәң дә була —
Сызылып бетте йөрәк...
Арды телем көне-төне һаман
«Килсен!» диеп теләп.

Хәзер инде килмәсәң дә була —
Барыбер чыкмас фәтва...
Урам мәчесенеке кадәр дә
Кирәгем юк хәтта...

Хәзер инде килмәсәң дә була!..

*28.04.2002*

* * *

Мин синсез дә яши алам икән, —
Өметләнеп ишек какма әле.
Сөю вәгъдә итә алмыйм сиңа, —
Йөрәгем буш түгел. Кайтма әле.

Елмайганымнан да көнләшеп, син
Бер сәбәпсез гаеп таккан мәлне
Искә төшерәм дә — исем китә;
Сагыналмыйм сине. Кайтма әле.

Картлык ни икәнен аңламыйча,
Баш әйләнеп йөргән чаклар әле. —
Син картлыкны күптән үз иткәнсең, —
Миңа бераз иртә. Кайтма әле!

«Синсез яши алмыйм» дигән булып,
Төче сүзләр уйлап тапма әле.
Гомер үтә, әмма яратулар
Мәңге кала икән! Кайтма әле...

*18.12.2003*

* * *

Язмышыма кереп калдың
Елмаеп-көлеп кенә, —
Иң кирәк җирдә бүленгән
Төсле төш кебек кенә.

Шул төшемне кабат күрсәм,
Аптырап калмас идем:
Син минеке булмый торып
Бер дә уянмас идем!..

*15.02.1983*

* * *

Кичер, синнән башка яши алам, диеп,
Сине алдавымны.
Ә үзем...
Ярты сәгать тә яши алмавымны.
Кичер, сиңа сиздермим дип,
Атсам салкын караш. —
Нишлим инде, йөрәгемне
Тоташ ялкын алгач...
Кичер, шылт иткән тавышка
Әйләнеп карасам,
«Син килә икән...» дип, шулай
Үземне алдасам.
Кичер, шушы яшькә кадәр
Булмаганга сөеп,
Аңлатып булмас хис белән —
Сине сөйгән кебек.
Кичер, синнән башка яши алмасам да,
Синсез яшәвемне.
Алай ярамаганын белсәм дә,
Берни дәшмәвемне...
Кичер...

*13.05.2002*

## *Минем өчен бары шул җиткән*

Уйсу гына җиргә күлләр күчкән,
Ай шәүләсе суларын кискән...
Синнән башка күңел көткәнем юк, —
Минем өчен бары шул җиткән.

Ай сарысы микән, сагыш микән
Күл өстенә сары төс сипкән...
Белеп яшим синең бар икәнне, —
Минем өчен бары шул җиткән.

Сары гына төшкән күл суларын
Ярларына ятып кем эчкән?..
Уйлыйм син дә мине көтәдер дип, —
Минем өчен бары шул җиткән.

Күл суларын эчеп үлән үскән,
Үлән өсләренә чык төшкән...
Көтә белү олы бәхеттер ул, —
Минем өчен бары шул җиткән...

* * *

Бармы җанның өзелмәгән,
Исән берәр җепселе? —
Иртәсен дә, көндезен дә,
Кичен дә уйлыйм сине.

Бу дөньяда бер мин генә
Шулайдыр көткән сине.
Киләчәгеңә юрыйм мин
Синсез үткән һәр көнне.

Киләчәгеңә юрыйм да,
Киләчәккә табынам.
Үткән көннәремне түгел,
Киләчәкне сагынам!

*24.12.1995*

* * *

Мин яраттым сине, хәтта онытып
Кеше сүзе, гайбәт, киртәне... —
Сине уйлап, кичен күзем йомдым,
Сине уйлап ачтым — иртәне.

Исемеңне дәштем — бар җиһаннан
Кабатлатыр булып артымнан!
Белмим: булды микән миңа кадәр
Шулай сөйгән, шулай талпынган?!

Үлеп сөйдем сине, белеп сөйдем
Кавышмасны... — Ходай кичерсен! —
Нәзерем шул: беркөн килеп, сине
Минем үлеп сөю «үтерсен»...

*2.01.2001*

* * *

Үкенүдән, газап, сагышлардан
Йөрәккәем өзелеп төшәр кебек.
Сөя алсам иде берәр кемне —
Яшьлегемдә сине сөйгән кебек.

Көндәлек мәшәкать, эшләр белән
Җете хисләр онытыла да кебек...
Өзгәлисең нигә үзәгемне,
Төннәр саен төшләремә кереп?!

Яшьлегемнән сине эзли-эзли,
Гомер көзем йөгереп җитәр килеп...
Сөя алсам иде тагын бер кат —
Яшьлегемдә сине сөйгән кебек...

*27.07.1985*

* * *

Иделемә төшеп сулар алам,
Иделләрдән чиста сулар юк.
Җан сөйгәнне көтеп яшим һаман,
Күңелемдә башка уйлар юк.

Иделкәйнең биек ярларында
Карлыгачлар гына оясы.
Язмышлардан узмыш булмаса да,
Җан сөйгәнне килми җуясы.

Иделемә карап таңга калам:
Кайгыданмы суы болганган?
Язмышлардан узмыш булса булыр,
Мин барыбер сиңа булалмам...

* * *

...Көз шул инде. Үтеп китте җәйләр,
«Яратам!» дип янып йөргән чаклар.
Яфрак булып очып йөри әнә
Синең миңа язылмаган хатлар...
«Яратам! Я-ра-та-м-м! Яратам!»
Үзең күрмисеңдер. Оча әнә хатлар,
Яңа сөю эстәп, җиһан буйлап...
Өзелдермә инде син җаныңны,
Бүген кинәт минем хакта уйлап...
Ачык тотма инде тәрәзәңне —
Тышта яңгыр, салкын...
Очып керер ачык тәрәзәдән
Минем сиңа язылмаган хатым:
«Яратам! Я-ра-та-м-м-м! Яратам!»
...Көз шул инде.
Гел тамарга тора
Күзләремнән тотрыксыз яшем...

Өметләнәм күк күкрәр диеп,
Сызылыр дип яшен!
Күк йөзенә язар утлы бер сүз:
«Яратам! Яратам! Я-ра-та-м-м-м!»
Нинди күкрәү ди ул, нинди яшен?!
Җәй түгел лә, галәмдә — сары көз.
Безнең инде тәрәзәдән генә карар чаклар...
Яфрак булып очып йөри әнә
Синең миңа язылмаган хатлар,
Минем сиңа язылмаган хатлар...
«Яратам! Я-ра-та-м-м-м!»
Ә мин сине һаман яратам!

*25.11.2001*

* * *

Мәхәббәт юк җирдә — бары мәкер,
Мәхәббәт юк җирдә — түбәнлек. —
Шул түбәнлек чокырына төшеп,
Тын алалмый батып үләрлек.

Мәхәббәт юк җирдә — мәңге хәйлә,
Үз-үзеңне генә ярату.
Адым саен, сырхауга сабышып,
Көйләтү үзеңне, карату.

Мәхәббәт юк җирдә — байлык җыю,
Ашау өчен яшәү, бирәнлек.
Сүнгән күзләр, һәрнәрсәдән көнләү,
Үч алырга теләү, юләрлек...

Мәхәббәт бар җирдә — эчкерсезлек,
Туры акыл, сөю-сәгадәт,
Мәхәббәтсез йөз ел яшәгәнче,
Бер көн сөеп яшә, җәмәгать!

*29.04.2002*

* * *

Төне буе буран улый.
Тәрәзәгә чиртеп елый
Кар бөртеге. Син түгел!
Капкаларны шыгырдатып,
Синең кебек керде ачып
Җил китеге. Син түгел!
Язлар җитәр-җитмәс чакта
Җылы яктан безгә кайта
Очар кошлар. Син түгел!

Кар суларын бездән куып,
Яз егете китте узып
Ат өстендә. Син түгел!
Үзәкләрне өзә-өзә,
Көткән сине көн дә, төн дә
Мин инде ул. Син түгел!
Өмет өзмим килерең,
Ышан минем сөюемә
Башканы түгел. Сине!

*7.03.1994*

* * *

Кояш кына батып, ай калыккач,
Авыл урамнарын биш үтәм.
Тәрәзенә сарылып карап тора,
Язган ярым әллә шул микән?!

Карасын ла, җаныем, әй, карасын,
Агартмасмы төннең карасын?
Агарталмаса да, әй, карасын,
Басалмасмы йөрәк ярасын?!

Агарса да төннең, әй, карасы,
Басылмас шул йөрәк ярасы —
Арабызда урам гына түгел,
Язмыш белән язмыш арасы...

*30.08.1988*

* * *

Кайчан гына килерсең син? —
Күзләреңә генә карар идем;
Бер сүз әйтмәсәң дә, күзләреңнән
Аңлар идем сине, аңлар идем.

Кайчан гына килерсең син? —
Башкаларга күзем салмас идем,
Көлеп торган май кояшы кебек,
Үзеңнән мин бер дә калмас идем.

Кайчан гына килерсең син? —
Янар идем бары синең хистә.
Үземне бәхетле тояр өчен
Синең тик янымда булу җитә.

..Күңелемдә моң диңгезе
Дулкынлана талгын гына...
Килер әле диеп көтә-көтә,
Гомерем үтә ялгыз гына...

*18.02.1987*

* * *

Мин сине Ходайдан сорап алдым,
Очрат, дидем, миңа шундыйны:
Күкрәгенә газиз башым салып,
Эч серләрем сөйләп булырны.
Очрат, дидем, миңа шундый ярны:
Күзләремә карап аңласын...
Һәм яратсын шулай:
Җанда, тәндә
Сөелмәгән җирләр калмасын!
...Сораганны бирде миңа Ходай —
Бер күрүдә сине яраттым!
Моң сирпелгән уйчан күзләреңнең
Төпкеленә кереп адаштым.
...Юлсыз җирдән киттек сукмак салып.
Артка борылырга соң инде!
...Махсус оешмадан документсыз
Яратулар гаеп шул инде...
Безнең сөю махсус өйрәнелмәс,
Беркем докторлык та якламас...
«Вәт, ичмасам, яратканнар!» — диеп,
Күккә чөеп беркем мактамас.
Акламас та, кызганмас та беркем,
Диеп, язмышлары шулайдыр...
Кызганса да... мине тик бер кеше —
Газиз әнкәм генә кызганыр.
Ә аңлавын... Аңламас шул ул да,
«Нәрсә җитми, — дияр, — шул яшьтә
Адәм көлкесенә кала-кала,
Кеше ире белән йөрмәсәң...»
Акыл белән уйлап, беркем әйтмәс,
Беркем әйтмәс безгә карата:
«Туктагыз әле! — дип. — Күрмисезме,
Алар бит бер-берсен ярата!»
«...Все возрасты...» дисәләр дә,
Мәхәббәтнең бар шул үз чоры!

Чоры үткәч, никтер «уйнашлык» дип
Атала ул, каһәр суккыры!
...Мин сине Ходайдан сорап алдым!
Нишлим инде — иртә бирмәгәч?!
Уйнаш түгел, чын яратам сине! —
«Үз вакытында» сөю күрмәгәч...
Соңга калдык! Ләкин тукталу юк!
Без тукталсак — яшәү тукталыр!
Бер-беребездән киталмабыз мәңге!
Ходай бирде. Тик Ходай алыр!..

* * *

Абау Аллам, уф инде!
Китәм, бәгърем, хуш инде,
Берьялгызың каласың;
Инде кемгә карарсың,
Күңелләрең тулганда?
Абау Аллам, аһ кына,
Сабыр итим чак кына, —
Карап торыйм китмичә,
Ничек китим көтмичә
Чын дөрес җавапларын.
Үзем эзләп тапмадым,
Син әйт, белсәң, көттермә.
Кем мин синең өченгә:
Вакытлымы, бакыймы? —
Шундый хисләр татыймы
Синең дә күңелләрең;
Яндырган, көйдергәнең
Минекенә охшашмы,
Бәгырем, сөюләрең?

*4.11.2001*

* * *

Без кабат очраштык,
Күп еллар узылган.
Күзләрдә — моң-сагыш,
Кул кулга сузылган.
Үзгәргәнбез бераз.
Шатлыклар бик-бик аз —
Калгандыр томаннар эчендә...

Очраштык. Әйдәле,
Онытыйк үткәнне.
Син миңа рәнҗүле,
Мин сиңа каргышлы икәнне.
Очрашкач, кабаттан
Янәшә атлыйк без,
Бүгеннән үткәнгә кайтмыйк без.

Аңлашып тормыйк без —
Кем хаклы, кем хаксыз.
Сызлатмыйк, кагылып,
Яраларны саксыз...
Таң аткач, китәрбез
Аерылып кабаттан.
Ләкин син белеп кит:
Элекке кебек үк
Мин сине яратам!

*7.03.1994*

* * *

«Ярый әле, — дисең, — яшибез без
Синең белән икәү бер урамда, —
Йөгереп кенә килеп җитеп була,
Сиңа әйтер тәҗел* сүз булганда...»

Әйе, дөрес! Йөгереп килеп була
Һәм йөгереп китеп була, — туйсаң.
Аңлар идең, бәлкем, хәлләремне
Үзең бермәл минем хәлдә булсаң.

Бер урамда яшәү бәхет түгел,
Бәхет — яшәү икең бер фатирда.
Чын сөюнең кадерен белгәннәргә —
Бәхет — яшәү хәтта бер чатырда...

Син белеп тор! —
Яшәү уты сүнәр көннәремдә
Синең күзләреңә табынам мин!
Бер урамда түгел, бер фатирда,
Хәтта...
Бер түшәктә сине сагынам мин...

* Тәҗел — ашыгыч, мөһим.

* * *

Үзебез дә сизми калган
Диванамы әллә без?! —
Бизәргә кирәк, дибез дә
Ныграк берегәбез.
Инде «поезд»лар да киткән,
Бушап калган «перрон» да...
«Уф» та «уф» дияр вакытлар
Карап узган юлларга.
Кайнарлык та сүрәнләнгән,
Очкын чәчми күзләр дә...
Белмим инде, нәрсә җитми
Безгә — ике юләргә?!
Дөнья күзеннән курку юк,
Шүрләү — гайбәт сүзеннән...
Минсез син яши алмыйсың —
Беләм моны үземнән.
Ходай бербөтен яраткан
Ике җанмы әллә без? —
Ничек элек җитмәгәнбез
Бу — бүгенге хәлгә без?!
...Диваналыгын сизмәгән
Диванамы әллә без?! —
«Бизәргә кирәк!» — дибез дә...
Ныграк берегәбез!

*7.04.2004*

* * *

Кешеләрдән минем кемлегемне
Сорап йөрмә — дөресен кем сөйләр?
Яхшы кеше кешене хурламас,
Хурлаганы — үзе шыр юләр.

Җанны җанга терәп, тәнне — тәнгә,
Күпме еллар бергә яшәп тә,
Кемлегемне белмәгәнсең икән,
Юләрлегең миргә күрсәтмә.

Әгәр мыскал гына акылың булса,
Уйлап карар идең яхшылап:
Мин үземнән начаррак булмам
Һәм үземнән булмам яхшырак.

*23.10.2003*

* * *

— Яратма син, — дисең, — мине алай,
Мин бит лаек түгел сөюгә... —
Лаекларны гына сөяр өчен
Яратылган җаным түгел лә.
Яратсам, мин бары шулай гына —
Бар җанымны биреп яратам.
Бик сәердер, беләм, яратмаган
Күзләр белән миңа карасаң.
Бик сәердер... Сәер генә түгел,
Юләрләнгән, тиле кебектер...
Акыл белән яшәү өчен, бәлкем,
Кеше яратмаулар тиештер.
Яратырга тик үзеңне генә!
Башкалардан яраттырырга!
«Яратам!» дип җан атучыларга
Сәерсенеп карап торырга.
...Юк шул, җаным! Нигәдер без андый
Туфраклардан яратылмаган.
Яры өчен утка-суга төшкән,
Алдын-артын карап тормаган.
Яраткан без бары җан канатып,
Күз яшьләре түгеп, аһ орып;
Кер тидерми җанына-тәненә,
Ап-ак дигәннәрдән ак булып.
...Яратудан мәхрүм туганнарга
Бары салкын акыл баш булыр.
Күрсәтмәсен Ходай! Андыйларның
Йөрәк урынында таш булыр.

*21.02.1998*

* * *

Тик үкенмим: һәрнәрсәне ихлас
Ышанып һәм чынлап яраттым!

*Р. Фәйзуллин*

Укыйсың да кайчак шигырьләрем,
Тотынасың сорау алырга:
«Йә, әйт әле, менә бусы кемгә,
Монысы... кемгә атап язылган?»

Аңлатырга сүз җитмәүдән түгел
Сиңа каршы дәшә алмавым. —
Кемгә атап язылган дисәм дә,
Шикләндерә мине аңлавың.

Аңлар булсаң — тик сокланыр идең,
Бәйләналмас идең шигырьгә...
«...Кемгә?» диеп сорау бирү үзе
Акылсызлык инде шагыйрьгә.

*18.12.2003*

* * *

Альбомымнан карточкалар карап,
Исемнәрен, җисемнәрен санап,
Үлгәнме-исәнмелеген сорап,
Минем гаеп-гөнаһларны юрап
Азапланма.
Алар күптән юк!
Бер син генә минем өчен икән!
Сурәтеңне йөрәгемдә йөртәм.
Бер син генә инде!
Бүтән юк!

*27.04.2002*

* * *

Бу җиһанда без тик икәү —
Син дә мин...
Һәм мин сине беркемнән дә көнләмим!
Уйламыйм да юк дип безнең киләчәк. —
Бик теләсәк, ул киләчәк киләчәк!
...Яңгыр ява шыбыр-шыбыр урамда.
Эчем пошмый анда беркем булмауга... —
Яңгырдан да курка кеше, җилдән дә.
...Дөнья буйлап тик без икәү килгәнгә
Көнләшәдер тик, көнләшсә, табигать.
Ә кешеләр...
Сөйләрләр «потлап» гайбәт.
Ярар әйдә, чәйнәсеннәр, бик әйбәт! —
Пошмый эчем бернәрсәгә бүгеннән!
Барысына-барысына күнелгән!
...Тәкрарлый җаным фәкать бер исем! —
Син җанымны ишетмисең, килмисең.
...Торасыңдыр карап син дә яңгырга,
Минем турында уйлаштырып аз гына.
...Бу җиһанда тик без икәү — син дә мин!
Һәм мин башка һичбер нәрсә теләмим!

*08.10.2001*

* * *

*...га*

Бу җаемне синең белән
Җәйлисем килә.
Ике язмышны төенләп
Бәйлисем килә.

Бу җаемне генә түгел,
Бөтенесен дә!
Хәтта...
Шагыйрь булмаска әзер мин
Синең өченгә!

*29.02.2000*

* * *

Син жәлләмә мине! Бу дөньяда
Күпне күргәнсең дип жәлләмә!
Миләшләр дә әнә җимешләрен
Кырау суккач кына тәмләнә.

Син кызганма мине! Бу иңнәрең,
Диеп, бигрәк күпне күтәргән... —
Кабат кайтыр булсам, гомеремне
Башкача, мөгаен, үтәлмам!

Кызганма да мине! Жәлләмә дә! —
Яратырга гына рөхсәт!
Дөнья үзе салыр кәләпүшен —
Каршысында икәү күренсәк!

*25.04.2002*

* * *

«Бәгырем» дип сиңа көн эчендә
Ничә әйтәм икән — санамадым.
Мин шул болай, бәгырь җәрәхәтләп,
Беркемне дә сөеп карамадым.

Бер ата-анадан туганмыни —
Чит-ят төшең тапмый азапланам;
Янымда чакта да сине сагынып,
Үз-үземнән көнләп газапланам.

Дөнья канунына төкермим дә,
Тәгәрәшеп кала гайбәтләр дә.
Көн тәртибен сиңа карап төзим,
Һәм... үзгәрде гореф-гадәтләр дә...

Күз-караш, эш-гамәл, сүзең белән,
Телем-телем бәгырь телгәлисең...—
Чи ярага тоз сибәләрмени! —
«Бәгырькәем!» дими, нәрсә дисең?!

*16.05.2003*

* * *

Назсыз кебек тоелсам да,
Наз тулып ташкан инде!
Оятлы да... Көем тапсаң,
Оятым качкан инде!

Тугры кебек булмасам да,
Җаным табынган сиңа!
Мин — су сибеп торган саен
Дөрләгән учак сыман.

Кеше саен сөйләп йөреп
Булмый кем икәнемне...
Ышанам: мине «табып», син
Гел *Үзем* итәреңне!

*19.12.2003*

* * *

Беләм: синең белән йоклап булмый,
Икәү бергә йоклап. —
Бер-беребезгә елышабыз һаман,
Булмый гына туктап!!!
...Ә иртәсен! Тәннең хәле беткән,
Сүнеп калган күзләр,
Йөрми аяк-куллар, эшләми баш,
Бөгелмиләр тезләр,
Куллар күтәрелми билдән ары,
Селкенми бармаклар...
«Сафсата!» дип кемдер көләр, бәлкем,
Башка акыл сатар. —
Әйтер: алай булмый ла ул, диеп,
Ялган бу, ерунда!
...Мин бит сезнең турында әйтмим моны,
Үзебез турында!

*27.04.2002*

* * *

Башымны җуеп яратам сине,
Аптырап үзем хәтта бу хәлгә.
Бер минут синсез торалмасам да,
«Көтәргә кирәк» дисең, «көтәргә».

Йөрәкне ярып карасаң әгәр,
Тоташ ярадан торадыр кебек.
Җибәрәм сине һәр көн янымнан,
Җанымнан өзеп, тәнемнән өзеп...

Назланып туймас чагында гына
Әйтеп куясың: «...Ярар, мин китәм».
«Китмәскә килдем!» — диеп, берзаман
Әйтерсең микән, әйтерсең микән?!

*17.09.2001*

* * *

Җаным телем-телем телгәләнә,
Бертуктаусыз үзәк өзгәләнә,
Ак нәрсәләр кара күренә,
Урын тапмый йөрәк үзенә —
Сине көткәндә.

Күңел мөлдер-мөлдер елап тора,
Һаман сине генә уйлап тора.
Һәр көндәге кебек уйнап-көлеп,
Иртәгесен кояш чыкмас кебек, —
Сине көткәнгә...

Бер эшкә дә никтер кулым ятмый,
Бәргәләнәм, үземә урын тапмый,
Белмим, алда ни язгандыр Ходай?!
Туры килер микән мәңге шулай
Сине көтәргә.

Бар да парлы кебек җир йөзендә...
Япа-ялгыздыр күк бер мин генә.
Сагыш... сагыш... тора түгелергә,
Охшамаган һич тә үтәргә...
Язмасын ла миннән бүтәнгә
Сине көткән кебек көтәргә...

*23.07.1999*

* * *

Өшеп киттем әле кинәт кенә,
Карап торгач сүнгән учакка...
Син кочакла мине. Кочакла! —
Сүнмәсен лә җаным учак кебек,
Дөрләп янулардан өмет өзеп...
Өшеп киттем никтер кинәт кенә...
Ник яшибез әле көйрәп кенә?! —
Дөрләп янар өчен җай барда.
Өлгерәбез әле сайларга
Көйрәү түгел, дөрләп януны,
Бәхетебезгә каршы баруны;
Безнең учак әле сүнмәде.
Чөнки без бит аны якмадык, —
Кабызырга шырпы тапмадык...
Өшеп киттем бүген кинәт кенә...
Җылыт мине! Кабыз учакны!
Сабырларым бетте шулчаклы!
Тиз бул!!!

*3.10.2001*

* * *

Көннәр буе сине уйлаганга,
Башка уйларымны куеп торам;
Күрмәсәм дә, синең һәр сулышың,
Борчу-уйларыңны тоеп торам.
Күзләрем дә, күңелем дә тулган —
Ятим бала кебек боек торам.
Үзен күргәч әйтермен әле, дип,
Әйтер сүзләремне җыеп торам.
Минут кына түгел, секундларның
Сине көткәннәрен кыеп торам,
Беркемгә дә күңелемне ачмый,
Эш-гамәлем белән кыек торам.
Килерсең бер: кара урман түгел,
Арабызда бары сыек томан...
Кочагыңа ыргылмасын диеп,
Үз-үземне чак-чак тыеп торам.

*15.08.2005*

* * *

Утырмале борының салындырып,
Тулды, диеп, иллем.
Чыпчыклар да сандугачча сайрап
Азаплана бүген.

Кыекларда әнә ялт-йолт килә
Көмеш-боз сөңгеләр;
Җирнең йөрәгенә тамчылардан
Бозлы ут йөгергән.

Утырасың авызыңны сузып,
«Йокым килә...»диеп,
Болай булса, язның хозурлыгын
Калмыйсың бит күреп!
Әйтәсең бит үзең: дөньяга, дип,
Әле тудык кына...
Шулай тумас борын картаерга
Рөхсәтем юк сиңа!

Утырмале һаман авыр сулап,
Картаелды, диеп.
Ачуны китерсәң, картлыгыңны
Очырырмын тибеп!

...Бер алдыңа, биш артыңа төшеп,
«Яратам!» дип торам.
Борын салындырып утырырга
Оял бераз, туган!

*2.03.2000*

* * *

Елый-елый таңга күзем ачтым...
Күз яшемне салып кофе эчтем...
Елый-елый гына таңнан — көнгә,
Көннәр аша кара төнгә күчтем.

Ә син мине уйлап та карамый
Йөргәнсеңдер көн-төн уйнап-көлеп.
...Бер-берегезнең аркаларын ышкып
Чыккансыздыр инде мунча кереп.

...Аһ!
Минем әче күз яшемә фәкать үзем,
Башка һичбер кеше сәбәп түгел.
...Акыл белән уйлап яратмагач,
Шулай килеп чыгу гаҗәп түгел.

Ир кеше ул сарык кебек икән —
Муен бавын чәйнәп өзәр түгел!
«Яратам!» дип, дөнья туздырырга,
Ул бит синең кебек юләр түгел.

...Әярату?! Булган һәм булачак, —
Гаилә җимерми дә барачактыр.
...Ярык тагаракка яшен коеп,
Шул бер мескен —
Шул мин калачактыр...

*28.04.2002*

* * *

...Сине болай сөю, беләм, гөнаһ.
Гөнаһ кына түгел, җинаять!
Төксе карап кала әнә арттан
Безнең «эш»не белгән җәмәгать.

Җинаятькә җәза бирү тиеш, —
Гөнаһ кына булса — бер хәер! —
Заман хөкемдары башы җитмәс,
Безнең җинаять шул бик сәер.

Сәерлеге нидә булу мәгълүм —
Бер-беребезне өзелеп ярату.
Фани дөнья канунына абынып,
Җан яралау, йөрәк канату.

Фани дөнья кануннарын уйлап
Аңгыра адәмнәр чыгарган.
Ходай язган гына камил юкса,
Өстен канун юк бит шуңардан!

Юк шул!
Кая барсаң, шунда кәгазь кирәк,
Түрә имзасы һәм мөһере.
Чын сүзеңә мәңге ышанмыйлар
Шуннан башка, каһәр төшкере!

Бәгырькәем! Кара әле миңа! —
Бармы мәкер, бармы бер хәйлә?!
Төкер әле пүчтәк кануннарга!
Ныграк ярат мине, сөй әйдә!

Кемнәр белсен тузга язмаганны —
Кемнең кайчан, ничек үләсен...
Атнага бер түгел, минем сине
Мизгел саен килә күрәсем.

Сыенасым килә иңнәреңә...
Тәнең генә түгел — җаныңа!
Һәм яшисем килә, карамыйча
Бу дөньяның кара, агына!

Икең тигез сөю — олы бәхет!
Бәхет кенә түгел — мәртәбә!
Ычкындырыйк әле йөгәннәрне,
Тибик әле әйдә тәртәгә!

Гомер аты китсен тугарылып!
Һәм җилдерсен әйдә җаена!
Төкер әле дөнья гыйбадына!
Кеше ни әйтер дип кайгырма!

Сөйләсеннәр әйдә, чәйнәсеннәр!
Бер туктарлар әле, арыгач. —
Рекордларның Гиннес китабына
Икебезнең исем язылгач.

...«Сөю» дигән иң олы байлыкның
Кадерен белик ахыр көнгәчә.
Без бит бу дөньяда кунак кына. —
Яшик әйдә Ходай дигәнчә!

*22.09.1999*

* * *

Тормышыңа ямь өсти алмадым.
Кан өстәдем бары яшеңә...
Авыр икән, авыр, яшьрен сөю,
Килеп җиткәч «шушы» яшеңә.

Мин, уятып, утларга салсам да
Йоклап яткан сөю хисеңне, —
«Яратам!» дип, ярып әйтә алмыйм
Кешеләргә синең исемне.

Сөйгән өчен, шөкер урынына
Каһәрен ишетәм кемнеңдер...
Тик шулай да, кача-поса гына,
«Сөяләр!» дип, син дә сөен бер!

Мин бит синең җаның сафландырдым!
Һәм... аралап алдым вак-лык-тан!
Буласы булганга булган инде! —
Үкенеп торырга вакыт тар!

*19.12.2003*

* * *

«Ник шылтыратмадың?» — димә әле.
Йоклыйсыздыр, дидем, кочаклашып;
Уяндым да туңып...
«Чәй эчәләрдер», — диеп уйладым,
Ялгыз чынаякка
Чәй ясагач куеп...
«Чөкердәшеп аш ашыйлардыр», — дип
Уйлап куйдым көндез...
Өем ямьсез, чәем салкын, ашым тәмсез,
Бәгърем, минем синсез...
«Ник шылтыратмадың?» — димә әле.
Кичен ятсам,
«Уянмасам иде, — дип сорыйм Ходайдан, —
Иртәгә...»
Белмим, синсез ничек көнем үткәрергә,
Синсез ничек гомер итәргә.
«Ник шылтыратмадың?» — димә әле.
Киенәсем килми матур итеп,
Аш пешерсәм, димен: «Кем өчен?..»
Ә син, күпме илереп сорасам да,
Мин «кал» дигән чакта, калмыйсың ла,
Мин чакырган чакта, килмисең.
«Ник шылтыратмыйсың?» — димә әле.
Шылтыратырмын да... ялгыш килеп
Кысылырмын сезнең тормышка.
Син дә, бәгърем, мине генә уйлап
Торган кеше кебек тырышма!

«Ник шылтыратмыйсың?» — димә әле...

*12.05.2002*

* * *

Син нишлисең икән бу минутта? —
(Үзәгемә үтте гаҗизлек!)
Ышаналмыйм, сине минем кебек
Очар кош булырга әзер дип.

Гел «законча» гына булмыйк әле —
(Үзәгемә үтте «дөрес»лек!)
Офыкларда кояш байый әнә, —
Әйдә язмыш белән килешмик!

Кайтыйк әле болыннарны урап,
Бездән башка гөлләр боектыр.
Мин килермен зәңгәр күлмәк киеп,
Син офык чигендә көтеп тор.

Көзгеләрдән карап торма инде! —
(Үзәгемә үтте көтүләр!)
Яннарыңнан меңәр урап киләм
Бер мизгел эчендә мин — юләр.

...Син нишлисең икән бу минутта? —
«Сине уйлыйм!» — диеп алдама!
Йөрисеңдер:«Вакыт бар әле...» — дип,
Мәңге яшәр булып дөньяда.

...Баткан кояш таңда чыгар, беләм!
Безнең «кояш», бәлкем, чыкмас та.
«Кадерләрен белмәгәнбез...» диеп
Үкенербез кебек шул чакта...

*11.07.2002*

* * *

— Хәлең ничек? — диеп, синнән никтер
Килми әле, килми сорыйсым.
Син болай да һәрбер әйткәнемне
Гел кирегә генә юрыйсың.

— Хәлең ничек? — диеп сорар өчен
Хәлләрем дә инде юк бугай...
Бер-береңнең хәлен белмәүдән дә
Нинди чара бар соң бик улай?!

— Хәлең ничек? — диеп сорамыйм да,
Сорасам да, әйтмә җавабын...
Синең хәлнең ничек икәнлеген
Үз хәлемнән яхшы чамалыйм!

*3.10.2001*

* * *

Әйләнәсең дә китәсең,
Утларга саласың да.
Ә үзең йөрисең һаман
Ике ут арасында:

Синең утыңда янучы
Бер мин генә түгел лә!
Утыра, мин дә бар, диеп,
Шундый берәү өеңдә.

Сиңа рәхәт — ике утта
Берьюлы җылынасың;
Мәңге шулай җайлы гына
Яшәмәкче буласың.

Озак түзеп тора алмам,
Бер чарасын табармын:
Тотармын да йөрәгеңә
Мәңгелек ут ягармын.

Шуннан ни булыр, дисеңме?
Әйтимме карарымны:
Мин читтән карап торырмын
Син дөрләп янганыңны.

Мәңге сүндерә алмассың,
Сүндереп карарсың да!
...Мин утырырмын җылынып
Ике ут арасында.

*19.06.2003*

* * *

Әгәр һич уйламаганда,
Әгәр һич көтмәгәндә
Яннарыңа килеп чыксам,
Бәгырем, үпкәләмә.

«Нигә?» — дип сорама миннән, —
Күңелнең китек чагы.
«Бик шәп булган!» — дип әйтә ал,
«Яратам!» — диген тагы.

Әгәр сиңа бара алсам,
Син шулай әйтә алсаң;
Алдын-артын уйлап тормый,
Яныңда кала алсам,

Йөрәктәге сөю хисе,
Димәк, сүнмәгән һаман.
Шул учактан утлар алып,
Мин яңа учак ягам.

Җыелсын учак янына
Мәхәббәттә янганнар,
Сөю хисен бар нәрсәдән
Өстен куя алганнар.

*20.01.2004*

## *Кем belә*

Көлүең тора гел исемдә...
Яраттым күзләрең өчен дә...
Чәчләрең өчен дә яраттым...
Табылдым... Мең кабат адаштым...

Синме соң гомерем буена
«Килер...» дип, төшләрдә күрелгән?
Ә бәлки, алай да түгелдер —
Чын дөрес җавабын кем белгән?!

Гел аек яшәлгән бер мәлдә
Рәхәт бит хисләрдән исерү!
Ни белән бетәрен белмичә,
Сагышлы газаплар кичерү.

Кем белә: бәлкем, бу хәлләрнең
Азагы бөтенләй булмас та!
Ярату кирәк ул кешегә —
Картлыкны тоймаска, сулмаска...

* * *

Сикереп кенә атланыр да идең... —
Атлары шул ап-ак бүз түгел!
Кем беләндер бергә булу әле —
Ялгыз булмау дигән сүз түгел!

Булса булсын атның тик акбүзе! —
Башка атлар безгә үз түгел!
Кем беләндер бергә булмау әле —
Ялгыз булу дигән сүз түгел!

*27.04.1985*

* * *

...Син бар, мин бар, ул бар! —
Арабызда юллар
Гел сикәлтәле дә киртәле.
Соң табыштык микән, иртәме?
...Мин бар, син бар, ул бар! —
Кемдер артык бугай чылбырда!
Бәлки... миндер, бәлкем... улдыр да. —
Син беләсең фәкать җавабын.
Кирәк түгел миңа алдавың
«Син генә!» дип, «әнә карале!»
Юк! Түгел шул! Ул да бар әле!
Димәк...
Ул бар, син бар, мин бар!

*3.10.2001*

* * *

Бу дөньядан туеп киттем әле —
Озакка түгелдер... Тик бер мәлгә; —
Язын, бар табигать уянганда,
Берьялгызым булгангамы әллә?

Кадерли алып та, кадерсезгә
Калып кимсетелгән өчен әллә?
Әллә инде алтын кебек гомер
Бер бәһасез үткәнлеге жәлгә?

Әллә инде мәңге сөяр булып
Ымсынганга кеше «өлеше»нә? —
Ул бит юкса язмыш очраштырган,
Ходай табыштырган минеке лә!

...Бу дөньядан туеп киттем әле, —
Аңлашылмаганга эш-гамәле... —
Әллә сине артык сөйгәнгәме? —
Бу дөньядан туеп киттем әле...

*11.05.2002*

# Мин дә бит
# бу фани дөнья колы



* * *

...Мин дә бит бу фани дөнья колы. —
Гөнаһлыдыр мин дә...
Сезнең эш-гамәлләр кабатлану
Гаепмени миндә?!
...Шул пычрак авызларга кушылып,
Ник сөйлисең син дә?!
Минем каралыгым-аклыгымның
Сәбәбе бит — синдә!
Син кысылма, минем гаебемне
Сөйләгәндә алар; —
Кемдә гөнаһ күпме җыелганын
Бер Раббым санар.
...Кемнәр белә: меңнәр арасыннан
Бәлкем, мине аклар... —
Җуелыр шул вакыт гөнаһларым,
Агарырлар таплар...
Кемнәр белә: бәлкем, башкалардан
Мин әле «аграк» карадырмын! —
Гайбәт сөйләгәннәр каралырлар,
Ә мин агарырмын!

*27.04.2002*

* * *

Син минеке диеп хис итәм дә
Киләчәккә якты уйлар корам...
Соры күктә сары яфрак икән, —
Мин бит аны яшьлек диеп торам...

Язмыш дәфтәремне актарам да —
Анда җилләр, давыл, яңгыр, буран...
Шушы минем олы бәхет икән,
Мин бит бәхетсезлек диеп торам...

Ни кылсам, ни күрсәм, нишләсәм дә,
Гел яктыга, гел яхшыга борам...
Барысы да ялган гына икән,
Мин бит аны дөрес диеп торам...

Мин генәме әллә бу җанымның
Гөнаһларын юар өчен туган?!
Газапларым, әче күз яшьләрем
Яшәү булган икән, яшәү булган...

*23.10.2003*

* * *

Шундый рәхәт! Җәйге чыклы иртә.
Дөнья тыныч, җылы саф һава.
Бу ни хикмәт: хозурлыкны бозып,
Шыбыр-шыбыр җиргә боз ява.

Төшкәнче үк эреп бетә үзе, —
Бер мизгелдә суга әйләнә.
Шундый халәт никтер Хак Тәгалә
Бирмәгән шул безгә — бәндәгә. —

Ничә тапкыр өзелеп сөйгән ярым
Йөзгә бәреп нахак сүз атты.
Шул нахактан нәүмиз йөрәгемә
Мәңге эремәслек боз катты.

*19.09.2002*

* * *

Менә тагын җитте туган көнең,
Бер елга арттырды яшеңне.
Гомер үтә, диеп моңаймале,
Сагыш-моңга салма башыңны.
Котлы булсын, дустым, туган көнең.
Бәхетләргә яшә күмелеп,
Озын гомер бирсен сиңа Ходай,
Сәламәтлек бирсен иң элек.

Шатлык бит ул, олы шатлык бит ул
Җирдә яшәү исән-сау булып.
Тиң ярыңны табып, гомер итү
Ахыргача икәү пар булып.
Һәр туган көн саен куанычлар,
Бәхет, шатлык өстәлә барсын.
Дус-ишләрең белән йөз яшеңне
Бергә бәйрәм итәргә язсын!

*23.01.2005*

* * *

Гөлләр алдым, суга салдым,
Агып китте гөлләрем.
Аккан сулар кебек, яшьлек
Үтәр диеп белмәдем...

Гөлләр алдым, суга салдым,
Тотып алдылар микән,
Гөлләр кебек яшьлегемне
Күреп калдылар микән?

Гөлләр алдым, суга салдым,
Ярсып аккан суларга.
Яшьлегемнең үтүләрен
Охшаттым шул суларга.

Гөлләр алдым, суга салдым,
Үкенмәм салганыма, —
Яшьлегем кабат әйләнеп
Кайтса минем яныма.

Кире барсам, гөлләр алсам,
Суларга салмас идем.
Яшьлегемнең кадерләрен
Белмичә калмас идем шул,
Белмичә калмас идем!

*23.12.1981*

* * *

Бар иде шундый чакларым:
Кычкырып көлә идем...
Һәр сәгатьне, һәр минутны
Тоемлый белә идем,
Мин шулай көлә идем...

Бар иде шундый чакларым:
Кычкырып җырлый идем...
Кешеләрдән яхшы түгел
Дип уйлап тормый идем,
Мин шулай җырлый идем...

Бар иде шундый чакларым:
Өзелеп елый идем...
Җырласам да, еласам да,
Сагышлар тоймый идем...
(Шулай дип уйлый идем!)

Хәзер инде чама беләм:
Кызык булса да көлмим,
Еламыйм да, җырламыйм да,
Кирәк сүз генә сөйлим...
Тик нигәдер күңелемне
Сагыш баса көннән-көн... —
Үзеңне үзең югалту
Шулай була, күрәмсең...

*17.10.1984*

* * *

Гомер буе кара эштән башка
Берни күрми гомер иткән әнкәм,
Ни була иде: «Дөнья катлаулы ул,
Хәйләкәррәк бул», — диеп әйтсәң.

Күңелемә шигырь уты салган
Гади укытучы апаларым,
Әйтмәгәнсез шигырь генә түгел,
Бу дөньяда проза да барын.

Иң беренче иренемнән үбеп,
Җанга ялкын салган тәүге ярым,
Ник әйтмәдең, сөю генә түгел,
Хыянәт тә әле җирдә барын.

Үзем әни, әби, укытучы, —
Бу дөньяны аңламыйча торам.
Өмет-ышанычым сынмасынга
Сабырлыклар бирсен Раббым-Ходам.

*2.12.2004*

* * *

Бала чагым калды урманнарда —
Көчем җитмәсә дә, утыннарның
Юан башын гына күтәреп...
Аякларда буй-буй кан тамыры —
Шул еллардан калган «истәлек».

Кая барсам, мине бала чагым
Ятимәлек белән ардырды...
Һәм... култыклап килеп, мине беркөн
Ялгызлыкка биреп калдырды.

Гәрчә мин бит алай үтенмәдем,
«Шулай эшлә» диеп кушмадым.
Ялгызлыкка юлдаш булу нигә?! —
Мин бит ***кешелеккә*** сусадым...

*8.01.1995*

* * *

«Син бик бәхетле!» — дигәнгә,
Мин сезгә нәрсә әйтим? —
Әйтегезче, була микән
Җирдә бәхетле ятим?!

«Ятим түгел бит син, бары
Ялгыз гына!» — диярсез,
«Башы буталып беткән...» — дип,
Шыпырт кына көләрсез.

Әйтегезче: ялгызлык ул —
Ятимлекме, кимлекме? —
Дошманыма да теләмим
Мондый «бәхетлелек»не...

*12.02.1997*

* * *

Киту авыр микән, калумы?
Сүнү авырдырмы, янумы?
Югалтумы, әллә табумы?
Дару дәва микән, агумы?
Өметләнү микән әз генә,
Өмет өзү микән мәңгегә?
Көтеп — килмәү микән,
Әллә соң,
Көтмәгәндә килеп керүме?
Нәфрәт җиңел микән, сөюме?
Дәшмәүдерме, бәреп әйтүме?
Кире килү микән, кайтумы?
Җан җылыну микән, катумы?
Пыску җиңел микән, ялкынмы?
Көмеш кадерлеме, алтынмы?
Гел җәй кирәк микән, кыш тамы? —
Дөрес кенә җавап юк тамы?..

*3.10.2001*

* * *

«Аек акыл белән сөям...» дим дә,
Гаҗәпләнәм үзем әйткәнгә,
«Аек акыл» белән генә булгач,
«Сөям» диеп йөрү нәрсәгә?!

Яныш сөяр өчен акыл түгел,
Акылсызлык кирәк мең кочак!
Тиле-миле, шашкын хисләр кирәк! —
Сөеп була фәкать шушы чак!

*19.02.2003*

* * *

Биек кенә тауның башларында
Лачын кошлар корган пар оя.
Хәсрәт кенә аша хәсрәт белән
Сабырларны сыный бу дөнья.

Лачын гына кошкай үз баласын
Киек җәнлекләрдән алдырмас.
Акыллы ла бәндә дөньялыкта
Яман гына атын калдырмас.

Җиккән генә атның турылары
Үргә таба ыргып менмидер.
Гомерләрнең ике килмәгәнен
Гамьсез генә бәндә белмидер.

Биек кенә тауның итәкләре
Менгән генә саен түгәрәк.
Ходай сөеп биргән бер гомерне
Үткәрик лә, дуслар, бергәләп.

*14.09.2004*

* * *

...Берәүне мең күрсәң дә сөймисең. —
Ник сөймәгәнеңне белмисең.
Берәүне бер күрәсең — сөясең. —
Нигә сөйгәнеңне беләсең:
Уе — синекечә,
Буе — синекечә;
Күзләрендә — кояш!
Җаны — сиңа тоташ —
Әйтерсең лә бер җан,
Бер анадан туган.
Эш-гамәле ап-ак!
Барсаң бергә атлап
Гомер чигенәчә —

Кайгы чигенәчәк,
Бәхет күренәчәк
Һәрбер борылыштан.
Шатлык эзләп юктан,
Торачаксың көлеп,
Якты йолдыз кебек!
...Менә шуңа күрә:
Ник сөймәгәнеңне белмәгәнне —
Сөймә!
Бер күрүгә сөяр үз тиңеңне эзлә!
Юктыр димә. Бар ул!
Янәшәңдә генә.
Бел бары тик күрә! —
...Бары тик бер генә!

*7.08.2001*

* * *

«Илле» диләр, «илле» диләр...
Иллене күргәнем юк.
Бергә-бергә иңне иңгә
Сыенып йөргәнем юк.«Илле» диләр,
«илле» диләр...

Белмим әле тәртибен.
Барып күргәч, парлап йөргәч,
Ни икәнен әйтермен.
«Илле» диләр, «илле» диләр...

Алтмыш түгел, илле шул.
Качып китеп бара идем,
Илле мине күрде шул!

Тотып алды, борып салды!
Ятам менә тәгәрәп...
Кырык тугыз — ерунда ул!
Илле менә га-лә-мәт!

* * *

Әгәр кемдер берәр эштә
Әкрен кыймылдаса,
Әйтеп куялар: «Янар! — дип. —
Чабуына ут капса».

Мин дә йөрдем мәхәббәттә
Әкрен генә кыймылдап,
Язган ярым үзе эзләп
Табар әле дип уйлап.

Ә кемнәрдер минем сыман
«Табар...» диеп ятмады,
Көтеп тормады берзаман
Итәккә ут капканны.

Үз кирәген үзе тапты,
Кая ди ул сайлату!
Нигә кирәк ут кабулар,
Нигә кирәк ярату?!

...Яши алар гомер буе
Әкрен генә кыймылдап,
Татлыдан татлы ризык,
Затлы киемнәр уйлап.

Безнең исә гомер буе
Яну да яну гына...
Ни эшлисең, сөю уты
Эләккәч чабуыңа.

Янсын гына, димен, берүк,
Юк исәп сүндерергә.
Чабуымдагы шул утым
Җитсен иде гомеремә.

*17.03.2004*

* * *

Их, димен, яшьлектә туя
Сөясе калган икән!
Чәч агаргач, садә хисләр,
Нигәдер, ялган икән.

Битеңдәге сырларыңа
Сыена икән яшең.
Юкка гынамы хатын-кыз
Яшерә ничә яшен?!

Яшь чагындагы җилбәзәк
Хисләрме кадерлерәк?
Тәнеңә кан куар өчен
Генәме хәзер йөрәк?!

Күңелеңдә сутлап яткан
Сөю хисе нишләсен?
Яшәвеңнең төп асылы
Шушы булса — нишләрсең?

«Кояшың баеган» диеп,
Кемнәр әйтмәс кемнәргә?!
...Әй! Башыңны юләргә салып
Сөяргә дә сөяргә!

*19.12.2003*

* * *

Җитәр инде, диләр, сөеп арыдык.
Йөрмик хәзер кеше көлдереп. —
Ятып кына торыйк караватта,
Күзебезгә йокы «элдереп».

Аһ! Кирәкми! Истә әле яшьлек,
Йокысыз үткәргән айлы төн!
...Яшьлегемне алса алсын Ходам,
Сөюемне генә калдырсын!

Янам әле һаман, дөрләп янам!
Яшь илледән үтеп китсә дә...
Күңелеңдә былбыл сайрамаса,
Бу дөньяда яшәү нәрсәгә?!

Сайрый әле былбыл, өзелеп сайрый!
Хәйран калып тыңлый һәр тараф...
Аһ! Бу сөю хисе нигә икән
Олыгайган саен татлырак?!

*25.04.2002*

* * *

Билгеле бер яшькә җиткәч,
Ирләр эзли яшь кызлар.
Их, сез, ирләр, юләр ирләр,
Һәр яшьнең үз яше бар!

Яшь кызларның сезнекенә
Охшамаган дәрте бар.
Сез «карт» дигән ханымнарның
Сез белмәгән яше бар.

Акыллы ир парын эзләр,
Эзләп йөрмәс яшь кызлар.
Илледән узган ханымның
Сез тоймаган яше бар!
(Колак салыгыз, кызлар!)

*19.04.2006*

* * *

Мин хаклык эзләдем.
Юлларда ялгызым.
Күкләрнең караңгы челтәре
Каплаган яктысын йолдызның.
Ялгыз ут сүнә шул җилләрдә,
Өметең учагы янса да...
Күшеккән күңелем җылынсын —
Кулларым учыңа алсана!
Күшеккән күңелем җылынсын —
Җанымны учыңа салсана!
Мин хаклык эзләдем.
Буранда адашып.
Кышларның салкыны өтүдән
Югалттым язмышның юл башын...
Мин хаклык эзләдем.
Киртәле юллардан,
Болганчык сулардан...
Болытлар артында
Кошларның эзләре югалган...
Мин хаклык эзләдем.
Утлардан... сулардан...
Җанымның ярасын ямарга
Саплаган җепләрем чуалган...

*7.03.1994*

* * *

Айның бүген җиденче кичәсе.
Ай нурында кырда атлар йөри үлән утлап.
Дөнья талган тын йокыга,
Гүя яшәү калган туктап.
Күзен ачар иртән кояш белән
Яңа көнгә куәт-егәр туплап.
...Ә мин ятам күз-яшь түгеп,
Китә алмый йоклап.
Йөрәгемдә леп-леп итеп сөю ята сутлап.
Кемдер: «Шәп бит инде сөйгәч!» — диеп
Куяр мине хуплап.
Кызыкмагыз, көнләмәгез!
Җанымда сутлаган ул сөюнең
Җавапчысы юк ла!..

*12.05.2003*

* * *

Юлдаш кирәк ерак юлга чыксаң,
Якын гына юлга чыксаң да...
Унсигездә, утызда да кирәк,
Кирәк җиткәндә дә туксанга.

Юлдаш белән юллар кыска була,
Юлдаш белән гомер озыная. —
Юл кыскартыр, гомер озынайтыр,
Җан теләгән юлдаш, син кайда?!

Юлларыңнан язып йөрисеңме,
Очрамыйча иң кирәк чакта?!
...Юлларымны озынайттың инде,
Гомеркәйләремне кыскартма!!!

*25.04.2002*

* * *

Киң офыкта шәфәкъ алсулана,
Әкрен генә сызылып таң ата.
Соңлап килгән сөю җыры булып,
Кошлар китеп бара көньякка.

Китә кошлар, китә пар-пар булып,
Таң ягына таба — офыкка.
Кайда соң син, җан җылытыр кешем?
Туңа җаным янда син юкка.

Кар-буранлы кышлар җитә, диеп,
Кошлар кебек китмә, кал әйдә!
Ак кар безнең сөю сукмагына
Түшәп куяр җылы ак җәймә. —

...Исә әле, исә йөрәгемдә
Узып киткән җәйнең җылы җилләре...
Калкан итик изге сөю хисен,
Кертмик әле җанга көзләрне.

*3.10.2000*

* * *

Мин юлларга карыйм. Шатлык килсә,
Нәкъ шул яктан килер шикелле...
Кайгыларым булса, юлга чыгам,
Җыеп «бетте» дигән көчемне.

Мин юлларга карыйм. Гел юлларга.
Иртәләремме ул, кичемме.
Мин юлларга чыгам. Юлсыз яшәү
Яшәү түгел кебек шикелле...

Мин юлларга карыйм. Сине көтәм —
Бәхет алып килер шикелле...
Мин юлларга чыгам. Кайнар килеш
Сиңа бирим диеп хисемне.

*25.10.1996*

* * *

Син көт кенә!
Мин килермен
Яшьлектәге сукмак буйлап
Биек үкчә киеп...
Кирәк булса, дөньяны мин
Мең әйләнеп чыгарга да әзер хәзер
Биек үкчә белән.
Кирәк икән — тау күчерәм,
Елгаларның борып куям юнәлешен
Төн чыкканчы.
Биек үкчә белән...
Кирәк икән —
Комнан чыбыркы да үрәм
Менә дигән!

...Тик син, тик син
Янәшәдән генә барчы
Күзең йомып, яланаяк.
Ә мин...
Әгәр кирәк булса,
Төшәрмен гүрнең үзенә!
Менәрмен язмыш үренә
Биек үкчә белән!
Корып куярмын бер тирмә
Икебезгә!
Биек үкчә белән...
Тик син түзмә генә ялгызлыкка,
Минсезлеккә!
Язмышың белән килешмә!
Сикереп тор да
Яланаяк чыгып йөгер!
Гомерләр үтеп киткәнче өлгер,
Өлгер!
Борчылма син ташлар диеп,
Өр-яңадан башлар диеп,
Биек үкчә киеп...
Мин яшәрмен гомерем буе
Сине генә сөеп!
Биек үкчә киеп...

*14.01.2006*

* * *

«Бер сәбәпсез ник елмаясың?!» — дип
Әйтмә миңа, дустым.
Хәтереңдәме, берчак үзең миңа
Еламаска куштың.
Хәтереңдәме: тышта коеп-коеп
Яңгыр ява иде.
Минем җанымда да болытлы көн,
Елак һава иде...

Мин еладым сыенып күкрәгеңә,
Эч серләрем сөйләп...
Ә син кырыс кына әйтеп куйдың:
«Еламаска кирәк!
Елардай чакта да үз-үзеңне
Елмаерга өйрәт!
Беркем сиңа, хәлең ничек, димәс,
Беркем тормас көйләп...»

...Мин елмайдым, үксеп елый-елый,
Тешләремне кысып...
Онытылган кебек булды кайгым,
Күңел куйды очып.
Шуннан башлап, мин кайгыларымны
Гел йөгәнләп торам...
Елмаям да гүя башларына
Күсәк белән орам!

«...Гел елмаеп кына торасың» дип,
Гаҗәпләнмә, дустым!
Теге чакта син бит үзең миңа
Еламаска куштың...

* * *

Минем йөзгә ышанма син, —
Боек чагын күрмәссең;
Йөземә карап беркайчан
Күңелемне белмәссең!

Минем йөзгә ышанма син, —
Кара булмас, ак булыр!
Йөрәккәем мөлдер-мөлдер
Елап торган чак булыр...

Минем йөзгә ышанма син,
Кара бер күңелемә! —
Ышанмасаң да йөземә,
Ышанырсың үземә!

*7.09.1988*

* * *

Артык бәхетле булганда,
Мин шигырь язмыйм бугай... —
Үземне артык бәхетле
Тойганым да юк болай.

Тоялмавым — хисләремне
Бәйгели белүдәндер.
Бәхетле була алмавым,
Мөгаен, үземнәндер.

Бәхетле булудан, ахры,
Мин куркам бугай «үлеп»... —
Бәхетле булсам, шагыйрә
Булмас та идем кебек.

*19.12.2003*

* * *

Апрельдә мин гел башкача янам —
Апрельдә мин янам Тукайча.
Гомер исәбемне саный башлыйм
Янган уттан сүнгән уткача.

Апрельдә мин гел башкача сөйлим —
Туган телнең тәмен мең татып. —
Тукай үзе тыңлап торыр кебек,
Шыпырт кына «тегеннән» кайтып.

Апрельдә мин гел башкача ярсыйм —
Апрельдә мин ярсыйм Тукайча!
Гел Тукайча көләм, елыйм, яшим, —
Күргән булмасам да һичкайчан.

Апрельдә мин гел Тукайча язам... —
Бу сүземне Ходам кичерсен! —
Мине дә бит шагыйрь дип йөртәләр —
Тукай юклыктандыр... Нишлисең!..

*27.04.2002*

* * *

Пушкинның төшендә шигырь
Язганын бала чактан
Ишетеп үскән идем.
Төшемдә үзем дә шигырь
Язасым килеп йөрдем.

Шагыйрь булгач, төшкә шигырь
Минем дә килә кереп;
Тик, торып, язып куярга
Ирендерә бит нилек?

«Иртән язып куярмын» дип,
Әй, ятлыйм тотып-тотып.
Таң атканчы бөтенесен
Куйган булам онытып.

Их! димен йоклыйсы калган
Кулыма каләм тотып.

*19.12.2003*

* * *

Зарлана да зарлана, дип
Әйтсәгәр берәү-кемдер, —
Минем бер генә шигырь дә
Андыйлар өчен түгел!

Бу дөньяга яралуым,
Мөгаен, бушка түгел! —
Зардан түгел, моңлылыктан
Мөлдерәп тора күңел.

«Елый белсә, җырлый белер...»
Димиләр юкка гына. —
Шигырь булып түгелүем
Түгелдер бушка гына!

Шигырь аңламаганнарның
Җан дуслары мин түгел!
Бар язганым — моңлыларга,
Зарлылар өчен түгел!

*28.01.2001*

* * *

Иң беренче каеннарга
Инә никтер көз төсе...
Уйлап куйдым: мин дә, диеп,
Шушы каеннар төсле
Моңаям да, уйланам да, —
Әкрен-әкрен саргаям...
Саргаймаска сабырлыкны
Алыйм икән, дим, каян?!
Йә Раббым, нигә мине
Бу кадәр җәберлисең?
Була алмас идеммени
Кемнеңдер кадерлесе?!
Кадерли алам лабаса,
Өзелеп сөя алам. —
Нигә бәхет капкаларын
Ябык тотасың һаман?
Ач әле! Керсен ябырылып
Аклыгы, сафлыклары...
Әллә ниләр өмет итмим,
Яшисем килә бары!..
Яшисем килә бары тик
Кемгәдер кирәк булып.
...Уянсам иде йокыдан
Бик тә бәхетле булып!
Озак көттермәче, Ходам,
Шул бәхетле көннәрне. —
Мин дә бит, каеннар кебек,
Алдан сизәм көзләрне...

*5.09.2001*

* * *

Яфрак очып керде тәрәзәмнән...
Ялгыз яфрак.
Җылы эзләп, урын сорап...
Язда түгел, көздә.
Язда булса, аерылмас иде
Агачыннан ялгыз яфрак.
Очмас иде җылы эзләп,
Урын сорап.
Көз шул инде...
Шуңа да ул
Тәрәзәмнән очып керде
Җылы эзләп...
Тагын берсе — сарырагы —
Пыялага ябышып калды,
Табалмыйча соңгы көчен
Очар өчен...
Яше генә агып төште пыяладан.
Туңган, сулган...
Өметен өзеп табарына җылы урын,
Юеш пыялага чиште күңел моңын. —
...Минем кебек.

*30.09.2001*

* * *

Кышын һич җылына алмыйм
Киенеп ничек тә...
Әче салкын кулны, аякларны,
Бит очым, колакны өшетә.
Башымда — шәл, өстә — җылы туным,
Бияләй, итекләр югыйсә.

Салкын караш, гайбәт, кеше сүзе,
Һәм, ниһаять, начар кеше үзе
Кагылса махсусмы, көнләпме —
Ул җаныңны синең бәреп вата,
Туңдыра туп-туры йөрәкне.

*16.05.2003*

* * *

Әллә ничек кенә үтте гомер.
Иртә киләм, дидем, — соңладым.
Рәхимсез вакыт күзем нурын,
Чәчләрем карасын урлады.

Миннән урлап, чәчем караларын
Бүләк иткән, ахры, төннәргә...
Ә мин менә ап-ак төсләр белән
Аклык өстим туар көннәргә.

«Күзләремнең нуры сүнде...» дим дә —
Кояш бит көн саен яктырак!
Үзең өчен иң-иң кадерлене
Кешегә өләшү яхшырак!

*2.11.2004*

## *Иделемә карыйм*

Иделемә карыйм. Идел көлә.
Кояш нурларында коена.
Дулкыннары, уйный-уйный килеп,
Иркә кыздай ярга сыена.

Иделемә карыйм, ул борчулы.
Киң ярлары әллә тар микән?
Идел кебек ярсу йөрәгемнең
Тынып торган чагы бар микән?!

Иделемә карыйм... Иделкәем
Минем белән гомер буена.
Шатлыгымны сөйлим җилләренә,
Кайгыларым салам суына.

*27.05.1986*

* * *

Авыз-борыннарын каплап
Йөргәндә бөтен кеше,
Һава яңгыратып көлеп,
Янымнан кызлар үтте.

Кара инде син боларны —
Салкында бер эше юк!
Гаҗәп инде: бу яшьлекнең
Җитмәгән бер төше юк!

Җил-давылдан да курыкмый,
Җитешә бөтен җиргә! —
Төркемнән аерылган коштай,
Моңаеп калдым мин дә...

*11.02.1982*

* * *

Тып-тып... тып-тып...
Кемдер кага дисәм,
Түбә кыегыннан
Тамчы тама икән.

Тып-тып... тып-тып...
Йокысымы качкан?
Хәбәр алган мәллә
Язлар килгән яктан?!

Тып-тып... тып-тып...
Уяттың мине дә.
Йоклап буламыни
Яз килгәндә җиргә?!

Әй, Җир-ана, уян!
Уяныгыз, кошлар!
Әнә шулай тып-тып...
Язлар килә, дуслар!

*21.04.2004*

* * *

Алмадай тулышкан бөреләр,
Кар эри, боз китә, яз җитә.
Яз кебек нәзберек күңелгә,
Сулардай ташыган хисләргә
Бер караш, бер сөю, наз җитә.

Кояшка үрелер бар гөлләр,
Чәчәкле җәй килер яздан соң.
Өлгереп тулышыр сөю-наз,
Күңелдә башка уй-хис булмас,
Көләрсең, еларсың, янарсың.

Көзләре куркытмас гомернең,
Җанында җәй булса, яз булса.
Күңелгә кагылмас кыраулар —
Мәңгелек булалса тугрылык,
Саф сөю, мәхәббәт, наз булса.

*4.07.2003*

* * *

Таң алдыннан сандугачлар
Җанымны салды моңга.
Алай моңлы түгел идем,
Әллә ни булды миңа?!

Чык бөртеге, таждан күчеп,
Керфек очыма кунды...
Мөлдерәп елап җибәрдем —
Миңа соңниләр булды?!

Тезләнеп торам каршыңда,
Сәер карама миңа!
Үзең мине моңга салдың, —
Күңелемне ач, дөнья!

Кил әле, тезләнә каршыма,
Тотыныйк кулны кулга.
Куеныңа салып кына
Юатчы мине, дөнья!

*14.03.2005*

* * *

Уелып төшәрдәй булам,
Үз-үземә карыйм да;
Сөяр яр тапмый тилмерәм,
Сөелергә ярыйм да...

Кемгә ачыйм, кемгә сөйлим,
Кемгә түгим зарымны?
Каян эзлим тәнем түгел,
Җаным терәр ярымны?!

Җилләр исеп киткән саен,
Төшә гомер кыелып. —
Узасым килә калганын,
Тиң ярыма сыенып.

«Булыр!» дисәң, була, диләр,
Минеке булмас инде. —
Тиң өлешем тумагандыр,
Туса да, тормас инде.

Хур кызлары бар икән, ди,
Җәннәтләрдә — оҗмахта.
Хур егетләре бар микән? —
Ләм-мим бер сүз ул хакта.

...Барып карагач, әйтермен, —
Анда хәлләр ничектер...
Белеп торам — үз тиңнәрең
Анда да дефициттыр!..

*24.01.2004*

## *Борын чөючеләргә*

Нәрсә әле борын чөясез сез,
Артык кемнән кайсы җирегез?!
Башкаларны мыскыл итә-итә,
Мыскылга калмагыз үзегез!

Нәрсә әле, шапырынган булып,
Һәр ярыкка кысылып йөрисез?
Кеше чәйни-чәйни, сукыраеп,
Борын астыгызны күрмисез!

Кеше башын оста ашыйбыз, дип,
Җае саен каһ-каһ көләсез.
«Кеше» дигән исем ят бит сезгә,
Бөтенләй ят — шуны беләмсез?!

Нәрсә майтардыгыз мактанырлык,
Бармы бирәр чиста көнегез?
Карамагыз безгә түбәнсетеп,
Без сезләрдән түбән түгелбез!!!

*17.09.1988*

* * *

Кешеләрнең нинди генә юк...
Синдәйләре, минем ишеләр.
Маймыл, сарык, дуңгыз төслеләре,
Ишәк, куян, елан төслеләр.
Арысланнар, филләр, төлкеләре,
Бөркет, сандугачлар, күкеләр...
Бигрәк төрле-төрле кешеләр!
Кара, сарылары, ап-аклары,
Зәңгәр, аллар — төрле төслеләр, —
Гадел, намуслылар, ихласлары...
Рәнҗеткәне юкка нахак тагып,
Изгелекне бар дип белмәгәне,
Үзеннән башканы күрмәгәне,
Тән сатканы, хәтта ден сатканы,
Акча, байлык диеп төртенгәне,
Чиста хезмәт белән көн күргәне,
Чит баланы карап үстергәне.
...Үз әти-әнисен үтергәне,
Балалысы, бала тапмаганы,
Хатын-кызны санга сукмаганы,
Ирләр белән ирләр йоклаганы, —
Ай-һай, төрле-төрле кешеләр!
Сере нидә? — Беркем төшенмәгән...
Һәм, мөгаен, мин дә төшенмәм!
Үзем дә бит кеше булган өчен,
Җанда өмет тулып торган өчен —
Мин яратам сезне, кешеләр!

*2.11.2004*

* * *

Нәрсә әле — без кешедән кимме?!
Хас түгелме безгә тугрылык? —
Ул тугрылык — җырда җырланырлык,
Меңнәр табынырга торырлык!

Ә без нәрсә?! Көтә белмибезме?
Без, дисезме, көтә белмәгән!
Чагыштырыр өчен сүзләре юк,
Андыйлар юк тиңләп сөйләргә!

Мактанырлык сәбәп юктан түгел,
Тыйнаклыктан дәшми торабыз.
Өстенлекләр безнең күптән өстә!
Түбәнсетеп карап тормагыз!

*5.08.1986*

* * *

Хәл дә сорый белми, диеп,
Гаепләп торасызмы?
Ярар, үзе дә күрер, дип
Рәнҗегән буласызмы?

Кеше хәлләрен сорарга —
Үз хәлләрем хәл әле.
Кеше жәлләрлек хәлем юк,
Үземә үзем жәл әле.

Маңгай күзем генә түгел,
Күңел күзләрем сукыр.
Сез дә бит минем хәлемне
Беркайчан сорамыйсыз.

*28.07.1998*

* * *

«Кеше...» диеп, кеше тикшерергә
Кыюлыгым җитми, базмый торам...
Калды микән бер зат —
Фани дөнья коткысына бирелеп
Азмый торган?!
Юктыр!
Камил акыллы дигәч тә... —
Җиде күктә бардыр камилрәкләр.
...Азынып алсаң да, хатаң тану кирәк
Чын йөрәктән!
Берәү була: ябыша да икенченең чабуына,
Сукыр кебек бара шулай дөнья буйлап
Абына-абына...
Ярый аңа кимсетелү, җәбер, золым...
Берәм-берәм китерә тора улын, кызын...
Икенчеләр —
Сөю эстәп гомер-бакый,
Ярсу аттай, араннарны ватып ташлый...
Иңрәп эзли дөнья буйлап
Үз яртысын, үз дигәнен. Һаман тапмый!
Мәңге эзли! Егылып үлсә үлә! —
Сөя генә! Сөелә генә!
...Уйлап торам: боларның, дип,
Кайсысы дөрес яши? —
Ә хакыйкать! — дәшми!..

*18.12.2003*

* * *

Ачулы кеше эчендә агу йөртә.
Күңеле актан мәкер көтмә,
Хөсет көтмә.
Изгелектән таба ләззәт
Ак җанлылар.
...Ничек кенә яшәсәң дә, гомер үтә.
Юмартлыклар коелыр бары
Актан гына.
Хөсет бәндә кызып китәр юктан гына.
...Һәм җаныңны кисәкләргә өзеп ташлар.
Юктыр әле ачулыдан изге тапкан.
Аннан хәтта, диләр, шайтан үзе качкан.
...Безгә аклык иңгән инде
Сабый чактан. —
Яшәмәдек дошманга да ачу саклап.
...Тик аклыктан күрдек җәбер,
Күрдек золым.
Ни булса да, шушы актан
Тайпылмасын мәңге уем,
Барыр юлым!

*6.11.2001*

* * *

Озын халат киеп... икенче каттан...
Камин каршысында креслода... —
Каян соң бу хыял? —
Тормышка ашмаган.
Искәртәме әллә затлы нәсел —
Ерак бабам?
...Ә мин кирпеч ташыйм, кадак кагам,
Бәйлим, тегәм, төзим, такта, тирес ташыйм...
Баш бераз ял күрсә, янә хыяллана башлыйм.
Күз алдыма килә кабат-кабаттан:
Ефәк халат киеп, икенче каттан
Йөзеп кенә төшкән сылу төз гәүдәм...
Камин каршысында, икенче мәлдән,
Кәнәфигә чумып, бер гамьсез...
Утыра бер ханым. Күрәмсез?!
Сез соң аны кем дип беләсез?
Мин бит инде! Шул бер мин һаман!
Бер тамчы су кебек охшаган
Дөнья куып яткан «мин»емә.
...Шундый шөгыль таптым үземә —
(Җитмеш җиде генә җитмәсә!)
Иртәләрдән алып кичкәчә,
Алам да «бүген»нән кубарып,
Очып менеп китәм югары! —
Җиде кат күкләргә — еракка!
Әкрен генә төшәм аннары
Затлы халат киеп... икенче каттан!..

*30.08.2004*

* * *

Дөнья йөген ат шикелле
Тәртәгә җигелеп тартам.
Ат шикелле аягүрә
Йоклап алам, бик арсам.

Беләм: дөньяның бар йөге
Төшә һаман атларга.
Сыерлар белән беррәттән
Оныталар тик мактарга.

Беләм лә мин — ярап булмый,
Ат кебек күп эшләсәң;
Иң әйбәте: сөтең биреп,
Көне буе күшәсәң!

Бөтен түрә ат янына
Басып сурәткә төшә;
Аннары, сыерны мактап,
Каймак ашап, сөт эчә.

Ни дисәң дә — сыер түгел,
Ат барыбер ат инде! —
Аның хәтта тизәге дә
Бөтенләй башка төрле...

*20.05.2000*

* * *

Әле һаман акыл кергәне юк,
Җитеп килсәм дә мин илле бишкә.
Әллә нинди сәер халәт шунда:
Әз дә кебек бу яшь, бик-бик күп тә...
Зурдан кубып берни майтармадым,
Чыгармадым том-том романнар да...
Шуңа күрә, адресымны тапмый,
Чит-ятларга китте гонорар да.
Язган шигырьләрем сөрсеп ята,
Әллә нәүбәт, әллә чират көтеп...
Мин «тукта!» дип, сөрән салып торам,
Янәшәдән гомер бара үтеп.
Ни елар, ни көләргә белмичә
Утырам да кабат сикереп торам;
«Кара аны, — дим, — кабалансаң,
Тотып алып колагыңны борам!»
Гомер үзе миңа бармак яный:
«Акыл, — диеп, — утыртырга вакыт!
Берәү булса, череп баер иде
Хет бы көйчеләргә шигырь сатып.
Син бит үзең дөрес яшәмисең:
Имеш, аңа Ходай шулай кушкан!
Әле һаман аера алмыйсың:
Кемнәрең — дус, ә кемнәрең — дошман...»
Тукта әле, гомер, шулай булгач,
Минем яшьне ничу арттырырга!
Берәр ун ел йөрим әле шулай:
Картайганны белми, яхшы гына!
Әле минем, оныгыма кушылып,
Йә җырлыйсым, йә биисем килә!
Уйлама син, оныт минем хакта,
Хет кая кит, миңа гына тимә!
Кара инде, ниләр кылана бит
Бу сакаллы сабый, димәс өчен,
Кануныңа бераз төзәтмә керт:
Яшьне бирмә миңа, яшьлек бир син!

*9.09.2005*

* * *

Тормыш тегермәне мине
Бик вак итеп тартты.
Булып чыктым шуңа
Иң югары сортлы.

Тарткан булса әгәр мине
Карап-җәлләп кенә, —
Булып чыгар идем
Бары тик мәкинә.

Шуңа күрә кем иренми, шулар
«Пешерәләр» мине. —
Иң югары сортлы булгач,
Нишлим инде...

*12.04.2002*

* * *

Күңелемә ниләр булды икән?!
Гомер нигә бик тиз үтеп киткән? —
Мин атымны тыеп калганмын.
Тарткан саен, ныграк төявемне,
Эштән генә бәхет эзләвемне,
Ай-һай, бигрәк соңлап аңладым.

Күңелемә ниләр булды минем?!
Бармы берәр тыныч торган көнем? —
Үз-үземне нигә битәрлим.
Йөгәнемне тартып кына торам,
Атын тыйган ерак юлчы сыман,
«Тр-р-р! Ашыкма! Тукта! Җитәр!» дим.

Күңелемә ниләр булды әле?!
Йөгреп кенә узган гомер җәлме? —
(Соң шул инде: җәллә-җәлләмә!..)
Безнең кебек җилкенмәсен өчен,
Соңга калып үкенмәсен өчен —
Бирче, Ходам, акыл бәндәңә!

*29.05.2002*

### *Га-җә-мәт!*

Гомер юлларын узганда
«Аһ» белән «уһ» димәсәң...
Сәламәт буласың, имеш,
Әгъзаларың сизмәсәң.

Озак яшисең, ди, имеш,
Бер җирең авыртмаса,
Көн саен куаныч белән
Кояшың баеп барса.

Шулай булды. Сизелмәде
Кая аяк, кая кул...
Турыдан гына элдердек! —
Нигә сукмак, нигә юл?!

Елмайсаң, энҗеләр кебек
Ап-ак иде теше дә...
«Арыдым...»га гел урын юк —
Эш бирегез, эш кенә!

Күз яна иде ут чәчеп,
Күкрәк тулы дәрт-дәрман!
Дәвам итәр иде кебек
Мәңге шулай, гел, һаман.

...Беркөн?! Сикреп торам, дисәм,
Кинәт аяк туктатты:
«Мин барлыкны онытма!» ди,
«Кабаланма шулчаклы!»

Ялт кына үрелгән идем
Почмактагы капчыкка,
Кулларым шып туктаттылар:
«Чү, сабыр, дип, ашыкма».

Алар белән янәшәдә
Сүзгә кушылды йөрәк:
«Гомер буе дилбегәдә,
Миңа да, дип, ял кирәк...»

Аны элеп алды күзләр,
Колак, тешләр... — һәммәсе!
Әгъзаларым сизмим, имеш,
Бар икән бит һәммәсе!

Гафу итегез, җәмәгать,
Кадерегезне белмәдем,
Сезне саклыйм, яклыйм диеп,
Бер чара да күрмәдем.

Теләсәгез ни эшләгез —
Каккалагыз, борыгыз...
Сез коллыктан азат хәзер,
Ә мин... — сезнең колыгыз.

*2.12.2005*

* * *

...Билдән генә тотып алса иде!
Ега кайчак тормыш аяктан.
Шуңадыр ул — Ходай ир җанында
Иярләнгән атлар яраткан.

Аргамакка сикереп менәр ирләр,
Бәйләнсә дә аяк-куллары,
Һәм җилдерер Каф тау артларына,
Безгә калыр тик юл тузаны...

Дөнья гаме, тормыш мәшәкате
Тотып ала кайчак билләрдән. —
Тешен кысар, билен өзмәс өчен
Мең сабырлык сорый ирләрдән!

«...Мин үзем!» дип күпме мактанса да,
Менгән чакта биек үрләргә,
Хатын-кызның көчсез беләкләре
Үрләрнең иң биек ноктасына
Тотынып менә шушы ирләргә!

Алмаштырып алам, дияр идең,
Байлык, алтын, әллә ниләргә! —
Бүлгән чакта Ходай ир-атларны
Өлеш тимәгән шул безләргә...

*12.07.2002*

* * *

Яшәүмени — сиңа үз гомереңдә
Ирләр кулы бер дә сукмаса.
Нәрсә кызык: ике мендәр салып,
Үз-үзеңне кочып йокласаң.

Яшәүмени — тәмле ашың белән
Сыйламагач газиз кешеңне,
Нәрсә кызык: аны гына уйлап
Үткәрмәгәч иртәң-кичеңне.

Яшәүмени — әгәр шифоньерда
Ирләр киеме эленеп тормаса,
Нәрсә кызык: назлап исни-исни,
Ирләр киемен чайкап юмасаң.

Яшәүмени — иртән, изелеп бетеп,
Ир кеше куеныннан чыкмасаң?!
«Ни пычагыма соң алар!» — диеп
Сөйләп торган булма, ичмасам!

*4.08.1998*

## *Бергәлек*

Иртәсен, чәчемә кагылып,
Уята ул мине йокымнан.
Бергәләп бит-кулны юам да
Янәшә ашарга утырам.

Эштә дә китми ул янымнан,
Кушыла һәр әйткән сүземә...
Чәчемне бөртекләп агарта,
Йөземә сарылар иңдерә.

Кушылып елый ул яшемә, —
Юатмый, «тукта!» дип бүлдерми.
Нигәдер шатланмый һичкайчан,
Көлми... һәм мине дә көлдерми.

Төннәрен качыра йокымны,
Туктаусыз куенга сыенып...
Сөенеп яшисе урынга,
Мин сулам көннән-көн боегып.

Ничәмә-ничә кат кусам да,
«Кит!» диеп ялварып-ялынып,
«Без бергә! Мәңгегә икәү!» дип,
Җаныма сарыла... Ялгызлык.

*22.09.1989*

* * *

Бер шатлыгым булса, тирәсендә
Мең борчулар йөри өер-өер.
Килә дә бөелә, килә дә бөелә
Тамагыма «сабыр» дигән төер.

Бер кычкырып елар идем дә бит —
Кеше сизәр, димен, кеше сизәр.
Елмаям да тагын туктап калам,
Менә шундый кеше инде... Юләр!

Кисә дә төшерә телем-телем
Ак җанымны нахак әйткән сүзләр.
Ул да мине, димен, рәнҗеткәч,
Кемлегемне белер икән кемнәр...

Китеп барсам, аңа авыр булыр,
Яши алмас минсез, янар, көяр.
Кемнәр аны, димен, минем кебек
Сөеп назлар икән, үлеп сөяр...

Бу җанымны, аңлап, сыендырыр
Җир йөзендә юкмы бер бөртек җан?!
...Бәлки әле, бәлки, бәлки... диеп,
Һаман «китми» сабыр итеп торам.

*23.10.2003*

* * *

Бу дөньяга газап дәрьясында
Йөзәр өчен генә килгәнменме?
Талбишектә тибрәлгән чакта ук
Газап ни икәнен белгәнменме?
Әллә тәпи баскан туфрагыма
«Газап» дигән келәм түшәлгәнме?!
Нигә соң мин киләчәкне түгел,
Иңнәремә салам үткәннәрне?
Нигә газапланам гомерем буе
Сыенырга таба алмый бер иң? —
Бу дөньяда аңлау эстәп кенә
Иңрәп йөрер дәрвишме әллә мин?!
Кайда соң ул, мин бәхетле булыр,
Иңнәренә башым салыр бер яр? —
Юкса Ходай кануны буенча
Ул булганга гына җирдә мин бар.
Китәрмен микәнни бу дөньяны
Аңлауларга бер көн нокта куймый? —
Нинди җан соң миндә талпынучы
Кеше язган кануннарга сыймый?!
...Нинди иде икән бу җиһанга
Мин беренче аваз салган вакыт?
Әллә Ходай әмер бирде микән
Яшәсен, дип, кануннарны ватып.
Шулай икән...
Кичер мине, Ходам, яшәгәнгә
Язган кануннарга башым иеп. —
Белмәдем мин газабымның башы,
Азагы да шул канунда диеп...
Ник соң, дисәм, үзем газап чигәм
Газапламас өчен бүтәннәрне? —
Ул икән бит минем тугры җаным
Синең кануныңны үтәгәне...

Шулай икән, рәхмәт сиңа, Ходам,
Фаниларда күргән газап өчен!
Бу дөньяда бөтен күргәннәрем —
Ахирәттә җаным азат өчен.

*12.06.2005*

* * *

Әнә генә — кул сузымы гына —
Без бик биек диеп йөргән кояш.
Кулларымны биреп исәнләштем
Беркөн, үзе белән бергә торгач.

Әнә генә — кул сузымы гына —
Дәрья суларының аргы ягы.
Каршы ярга йөзеп чыгар өчен
Көч-егәрең генә булсын бары.

Әнә генә — кул сузымы гына —
Мин «килер» дип гомер буе көткән.
Ераклардан эзләп тапмаганым
Кул сузымы гына ара икән.

Әнә генә — кул сузымы гына —
Без «юк» диеп кул селтәгән бәхет.
Ләхеткә дип җыйган такталардан
Җитте менә тәхет төзер вакыт.

* * *

Әй дөнья, көйсез лә син,
Көйсез баладан да көйсезрәк!
Өйрәтмәдең: синең соң
Көйләр көең ничегрәк?
Көйсез баланың да көен табып була,
Йә җырлап, йә биеп, йә кулга алып була.
Ә син, дөнья!
Җырласаң да, ишетмисең, биесәң дә...
Аңламыйсың, тыңламыйсың ни дисәң дә.
Карап торам: йә, нишлибез,
Аерылыйкмы вакыт җитми,
Көең килер чакны көтми?
Йә түзикме, чама белеп.
Шул түзү атала бугай
ЯШӘҮ диеп...

*12.05.2003*

* * *

Җилләр исә Каф тау артларыннан,
Җилләр исә кыйбла ягыннан...
Мин йөгереп үтеп кенә киттем...
Орлыкларым чәчеп калдырам...

Ике генә бөртек! Ике генә
Бөртек булды бөтен җыешым...
Уңыш кына бирә күрсен берүк!
Җир куенына гына сыенсын!

...Китеп барам Каф тау артларына. —
Үзем белән берни алмадым...
Йөгереп кенә үттем гомеремне! —
Орлыкларда калсын дәвамым!

*25.04.2004*

* * *

Кояш көткән чакта яңгыр ява,
«Яңгыр» дисәң — кояш кыздыра.
Кеше шулай, үзенең бар гомерен
Булмаганны юрап уздыра.

Шатлык көткән чакта кайгы килә,
Көләм дисәм — елыйм нигәдер...
Адәм баласына бу дөньяда
Бары да чиратлашып киләдер.

Сөю көтеп гомер узып бара...
Чәчемдә чал күреп уфтанам.
Хәле миннән мөшкелләрне күреп,
«Шөкрана» диеп тукталам!

Өмет итмим бары бәхет кенә,
Кайгысы да булсын, зары да...
Язмышыма нәрсә язылса да,
Тансык миңа бары, бары да!..

*12.02.1996*

* * *

*(Кояш белән серләшү)*

Саумы, Шәмс?! Без бит бер тамырдан,
Икәү бер нәселдән булмасак та, —
Икебез дә күңел җылыбызны
Һәр кешегә тигез юлласак та...

Син беркөнне әгәр чыкмый калсаң,
Иңри-шаша дөнья йолкыр чәчен.
Ялварырлар соры күккә карап:
«Чыкчы!» — диеп, коя-коя яшен.

Ә мин беркөн әгәр чыкмый калсам,
Беркем сизмәс, искә алмас һичкем.
Берәр айдан кемдер әйтеп куяр:
«Күренмәгән иде... Үлгән икән... Мескен...»

*28.04.2002*

* * *

*(Авырып ятканда үлем турында уйланып)*

Кайсы яклап карасаң да,
Минем «китү» яхшы булыр:
Эшемдә — урындык бушар...
Балаларга — фатир булыр...

Яхшы гына булып калмас,
Минем «китү» әйбәт булыр:
Дөньялыкта кем булганым
Шуннан чыгып шәйләп булыр.

Әйбәт кенә булып калмас,
Минем «китү» авыр булыр:
Дошманнарны — сөендерер,
Әнкәемә — кайгы булыр.

...Кемдер бу хәлгә ышанмас.
Кемдер чынлап чынга алыр. —
...Фани дөнья читлегеннән
Чыгалмыйча, гәүдәм калыр...

*5.08.2001*

* * *

...Мин бер тапкыр яшәгәнмен инде
Ерак әлмисагта.
Хәтерләмим ниләр кылганымны
Анда булган чакта.
...Инде менә тагын яшәп йөрим,
Кадерен белми генә...
Үз кадеремне үзем белмәгәнгә,
Кадер күрми генә.
Юл салмадым, мәчет төзетмәдем,
Утыртсам да агач.
Байлыгым юк Ходай бирмәгәнгә,
Ир юк — Ходай алгач...
«Вакыт!» диеп, беркөн Газраил
Килсә минем арттан,
Кәфенлегем куеп янәшәмә,
Ятагыма ятмам.
«Юк! — диярмен. — Китмим әле пока,
Яшәп өлгермәдем!
Чыгып кит, — дип, —
моннан яхшы чакта!» —
Аягым тибәрмен.
Исбатлармын шулай, миннән куркып,
Хәтта
Үлем кадәр Үлем чигенгәнен! —

...Ә сез мине: «Син бик юаш!» — дисез...

*28.05.2002*

* * *

Кеше гомере кызык кына икән...
Иртән, көндез, кичен... — мәңге эштә!
Дөнья ямен, яшәү хозурлыгын
Аңлар өчен вакыт җитми һич тә.

Эштән бушаганда зарланабыз,
Дөньяда, дип, яшәү кызык түгел...
...Әкрен-әкрен генә җан тарая,
Йөрәк ката, кечерәя күңел.

Кеше хәлен түгел, үз хәлеңне
Белергә дә җаен табып булмый.
Шулай әкрен-әкрен вакыт — явыз —
Алтын кебек гомеребезне урлый.

Авырып ятам... Эшләргә хәлем юк,
Укып булмый... Башым, күз авырта...
Ә урамда, юлга яфрак түшәп,
Кыш ягына икән көз авыша.

Бу ни хәл бу?! Яңа май иде бит!
Бар агачлар иде шау бөредә!
Мин бит әле өлгерми дә калдым
Җәйне түгел, язларны күрергә.

Ә урамда әнә яфрак туе!
Күзләр генә түгел, уй камаша!
Кичер, дөнья! Авыру күз белән дә
Син бик гүзәл икәнсең ләбаса!

*16.05.2003*

* * *

Авыл җаны — шәһәрләрдә,
Дурт стена эчләрендә...
Шигырь булып түгелә ул
Төннәрендә, кичләрендә.

Бәргәләнә читлектәге
Яраланган бер кош сыман.
Түзә алмас, өзелер күк, —
Калган инде нечкә кылдан...

Язмышмы бу, фаҗигаме? —
Авыл җаны — шәһәрләрдә!
Бу халәткә дучарлыкта
Үзеңнеме каһәрләргә,
Үпкәләргәме әнигә —
Җибәргән, дип, нигә читкә?
Йә Ходайга, кешеләргә
Сылтаргамы ахыр чиктә?!

...Беркемнең дә өлеше юк
Без яшәгән гомерләрдә.
Каерып алам да читлектән,
Җаным салам шигырьләргә.

*17.03.2004*

* * *

Ач күзеңне — дөнья бу!
Синең белән миңа бу!
Рәхәтләрен татый белсәң —
Искитмәле дөнья бу!

Ач күзеңне — дөнья бу!
Күчә кулдан-кулга бу!
Синнән-миннән калыр өчен
Яратылган дөнья бу!

Ач күзеңне — дөнья бу!
Елатып та сынар бу,
Көлдереп тә сынар бу,
Байлыгыңны пыран-заран
Бөлдереп тә сынар бу!
Бөгелдереп, сыгылдырып,
Сындырып та сынар бу!
«Эһ» дигәнче узар бу! —
Газиз әнә шуңар бу!

*2.03.1994*

Ә туган як...
Тәүге сагындырып,
Бар җанымны синең
җирсетә



* * *

Китеп барам ерак җиргә,
«Сау бул!» диеп туган илгә.
Җилкән салдым Иделләргә,
«Исегез!» дидем җилләргә,
«Исегез, — дидем, — уңайга,
Читен бит миңа болай да
Юлсыз җирдән юллар табу,
Туган илсез-җирсез калу...»
Башымны җилләргә салу,
Туган илдән китеп бару,
Җилгә салу язмышымны —
Читтә диеп уйлар уйлап...
Туган илсез калулары
Җиңел икән кемгә генә?!
Бары туган илдә генә
Йомшак төсле җилләре дә...
Җилләре дә, җирләре дә
Изге — туган илләремдә.
Булса әгәр язмыш узып,
Атар идем гөлең булып,
Сузар идем тамырымны
Гөлләр булып синдә генә.
...Китеп барам. Кайтырмынмы,
Кайталмыйча калырмынмы? —
Алдан күрми, белми генә...

*1—6.10.1994*

## *Туган нигез*

Туган нигез, үскән нигез,
Тәпи басып киткән нигез,
Ничә бала бер оядa
Үстек бергә, үстек тигез.

Үсеп җиттек, очып беттек,
Бәхет эзләп ерак киттек.
Чит-ят җирдә, чит нигездә
Юллар ерак, күңел китек...

Ерак инде әти-әни,
Без аларга һаман бәби.
Эшләргә әзер әллә ни,
Җанын да бирер жәлләми.

Кайтыр өчен вакыт тапмый,
Йөрибез без һаман читтә.
Туган йортны ташлап беркөн
Әти китә, әни китә...

Әти-әни исән торса,
Ходай әгәр кабул кылса,
Туган нигез, үскән йортка
Еллар аша юллар булса,

И туган йорт, и үскән йорт,
Кайгы-шатлык бүлешкән йорт,
Тагын кайтып җыелырбыз,
Балаларың исеңдә тот.

Әткәйләрнең, әнкәйләрнең
Фатихасын алып калыйк.
Туган-үскән нигезләргә
Кайтып, яңа йортлар салыйк.

*20.01.2004*

* * *

Әйдә, дустым, кайтыйк әле
Авыл сабан туена. —
Быел барыбер кайтам, диеп
Җыендым кыш буена.

Кашык кабып йөгерербез,
Аркан тартып уйнарбыз,
Колга башына менәрбез,
Катыкка да чумарбыз.

Батыр калырмынмы-юкмы —
Мин дә көрәшкә керәм;
Сөлге булмаса, һич югы,
Кулъяулык эләктерәм.

Сабантуймы, җыенмы ул —
Хикмәте анда түгел!
Мәйданнарны урыйк җырлап,
Ачылып китсен күңел.

Их, дускаем, әйдә, әйттер,
Гармуның бар кулыңда.
Җырлап була, елап булмый,
Диләр сабан туенда.

* * *

Гүзәл җирдә туып үссәм дә мин,
Авылымда калып булмады.
Язмыш миңа юлдаш иткән икән
Борма-борма урау юлларны.

Гомер үткән саен, үзәк өзеп,
Сагындыра икән туган як.
Ата-бабам шунда гомер сөргән,
Безнең өчен нигез корган як.

Юлларыма йөгереп чыгып баскан
Ак каеннар белән ярышып,
Кырык эшем кырык якка ташлап,
Туган якка кайтып барышым.

Борма-борма юллар ыргый алга,
Тезелеп кала нарат-имәннәр.
Кайтып җитсәм, илдә үләннәр дә
“Саумы?!” диеп башын иярләр.

*4.07.2003*

* * *

Туган якка кайтып килим әле —
Көтә анда газиз әнкәем.
Миннән берни өмет итми генә,
Бары: «Кайтыр, — диеп, — бәбкәем».

Кай җирләрне барып бер күрәсең,
Гомерең буена шул җитә.
Кабат сагындырмый, табындырмый,
Уйга салып сине кич-иртә.

Ә туган як... Мәңге сагындырып,
Бар җаныңны синең җирсетә.
Төшләреңә кереп, исләреңә төшеп,
Оныттырмый үзен ничек тә.

Монда сиңа һәрбер үлән таныш,
Агач-куак, хәтта бөҗәге.
Монда гына — туган якта гына —
Бар синең һәркемгә кирәгең.

Һәрбер кылган эшең белеп тора
Гамәл китабыдай картлары.
Шул «китап»ны кат-кат укыр өчен
Син вакытын гына тап бары.

Менә шулай, җае чыккан саен,
Шул «китап» битләрен актарам
Диеп, кабат-кабат юлга чыгам...
Күнегелгән... башка юк чарам.

*2.11.2004*

* * *

Бу дөньяда миннән бай кеше юк,
Кайгыларга урын тар әле;
Һәрбер яңа көнгә рәхмәт укыйм,
Мин бәхетле, — әнкәм бар әле.

Ятимлекнең ни икәнен белмим,
Йөзем һәрчак көләч, ак әле,
Чөнки миңа «балам» диеп дәшәр
Газиз әнкәм һаман бар әле.

«Әни» диеп дәшә ике балам,
«Дәү әни» ди онык — кара әле!
Үзем әби хәзер, әмма минем
Газиз инәкәем бар әле.

*26.11.2004*

* * *

Әнкәем!
Син бирдең гомерне
Тигезләп безгә — дүрт балаңа —
Рәнҗемә көткәндә кайтмасак,
Кермәсәк синең кул араңа.

Рәхмәт, үстердең наз белән,
Өйрәттең гел уңай сыйфатка.
Онытылмый биргән һәр киңәшең —
Кем булып, кайларда торсак та.

Җил-давыл тимәде тормышта,
Булганга син һаман янәшә.
Мең рәхмәт барысы өчен дә,
Мең яшә, әнкәем, мең яшә!

*27.02.2002*

* * *

Әнкәй, дүрт кыз арасыннан
Мин булдым елак балаң.
Гөлләрнең таҗы сынса да,
Мөлдерәп елап алам.

Парлы кошлар аерым-аерым
Очып китсә тирәктән,
Күзләремнән генә түгел,
Яшем тама йөрәктән.

Күктә болыт парлы булып
Йөзеп барган җиреннән
Ике якка аерылса,
Яшем тама күземнән.

Парлап яшәгән җиреннән
Дөнья куйса берәрсе, —
Үзем ялгыз калган кебек,
Агыла күземнән яшем.

Кырын карап куйса берәү,
Яшьләнә ник күзләрем?
Усал сүз белән урынына
Утыртасы үзләрен! —

Юк, авыздан сүзем чыкмый,
Күздән генә яшь тама.
Илле яшемнән узсам да,
Мин һаман елак бала.

*22.01.2004*

* * *

Син әйтәсең, әнкәй: «Бик картайдым,
Чәч агарган, тешләр калмаган...
Син укыган кеше. Сиңа, кызым,
Ярамас шул миңа яраган.

Мин дә, дисең, буйга о-о-зы-ы-н идем,
Синең кебек идем... Чүгелде.
Дөнья булгач, кайгы-хәсрәтләр дә,
Авырлык та бик күп күрелде...

Тыныч кына китим инде, дисең,
Күп яшәлде. Бетте кирәклек...»
Әй әнкәем! Миндә булса иде
Синеке кадәрле зирәклек.

Белсәң иде, әнкәй, минем өчен
Зирәкләрдән зирәгрәк син,
Чал чәчләрең, чүккән буең белән...
Кирәкләрдән кирәгрәк син!!!

* * *

Кайларга җыендың, әнкәем, —
Сандыгың тутырып куйгансың...
Нигә ул — шулкадәр ак ситса,
Тастымал, яулыклар җыйгансың?!

...Төсләре уңа ник күзеңнең,
Чәчләрең аграк көннән-көн?
«Боларын, дисең, бир кешегә,
Монысын... йә үзең киярсең...»

Нигә соң гел авыр сулыйсың:
«Китәм, — дип, — каласың... төпчегем!
Бәхетем, өметем син! Мин сине
Үземә алмашка үстердем...»

Нинди җыр җырлыйсың гелән син:
«Кайтулар булмас ул илләрдин...»
...Кирәкми, әнкәем! Кирәкми!
Мин сине беркая җибәрмим!
Җибәрмим!!!

*11.02.1982*

* * *

Инәкәем минем, йөрәк парәм,
Менә тагын сиңа кайтып барам,
Дүрт йөз чакрымны якын итеп...
Төшләреңдә һаман мине күреп,
Тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп,
Арыгансыңдыр, гел мине көтеп.

Инәкәем минем, күңел җылым,
Син көткәнгә уңар минем юлым.
Терәгем син иң кирәк чакта.
Берүк, зинһар, авырып кына китмә,
Югалтасым килми сине һич тә, —
Минем хакка үзеңне сакла.

Инәкәем минем, җан җимешем,
Ниләр кылыйм икән синең өчен?!
Үкенмәскә аннан соңарып...
Кайткан саен сине исән күрсәм,
Һаман үз аягың белән йөрсәң, —
Иң зур бәхет менә шулары.

Инәкәем минем, газиз генәм,
Менә тагын сиңа кайтып киләм, —
Бар җаныма сагыш-моң тулгач...
Исән-имин сиңа кайтып җитсәм,
«Кайттым!» диеп, тәрәзәңне чиртсәм,
«Балам!» диеп, үзең ишек ач!
Үзең генә, зинһар, үзең генә...

*29.05.2002*

* * *

Әй, кызым, китәргә кирәк инде, күп яшәлде...

*Әнкәм сүзләре*

Китмә әле, әнкәй, китә калсаң,
Ятим калыр өең, абзарың...
Иртүк чыкмасаң да, ишегалдың
Тоеп тора әле син барын...
Китә күрмә, әнкәй, карт алмагач
Түзә алмас, корыр, син китсәң.
Син утырткан һәрбер чәчәк, үлән
Белеп тора әле — син исән!
Китмә, әнкәй, зинһар, китә күрмә! —
Тавыкларың калыр шыр ятим,
Морҗабыздан төтен чыкмас бүтән...
Ышандырып тагын ни әйтим?!
Әй, әнкәем, китмә әле, китмә,
Ятим итмә төпчек кызыңны...
Әйтелмәгән сүзләр күпме әле!
Сиңа юлым — йөрәк сузымы.
Ерак түгел лә ул дүрт йөз чакрым —
Йөрәгеңә йөрәк сузылса!
Авыл ямьле әле, урам ямьле,
Өебез җылы, әнкәм, син булсаң.
Китә күрмә, әнкәм, ятим итмә!
Мин бит үксез инде болай да...
Синең изге догаң белән генә
Эшләрем бит бара уңайга.
Син әйт кенә — нишлим, ниләр бирим,
Гомерең озын булсын өченгә?!
Китсәң, өзелер җанның соңгы кылы —
Үтермә син мине, үтермә!
Китә күрмә, әнкәй! Китә күрмә!

*13.12.2005*

* * *

Бу дөньяда шактый хәсрәт чиктем:
Әткәем юк, ирем югалттым.
Ни генә булса да, үз-үземне
«Әнкәем бар!» диеп юаттым.

Әйе, шөкер, газиз әнкәем бар!
Иртәләремдә бар, кичтә дә;
«Ялгыз», «ятим», «картлык» дигән сүзләр
Кереп чыкмый әле искә дә...

Күңелем киң — изге, яхшылыкка,
Хәсрәт-борчуларга урын тар.
Илледә дә һаман сабый әле,
Бәби әле, чөнки әни бар!

*2.11.2004*

* * *

Кайтсам-китсәм, нурлы йөзең белән
Ишек ачып каршы аласың.
Шулай өзелеп тик әнкәйләр генә
Яратадыр газиз баласын.

Авызыңнан өзеп, өем-өем
Күчтәнәчләр төяп куясың;
Миңа рәхәт: инде картайсам да,
Килә һаман бала буласым.

Кайчакларда, куеныңа сыенып,
Килә үксеп-үксеп елыйсым.
Син генә бит, әнкәй, һәр сүземне
Ихлас күңел белән тыңлыйсың.

...Итәгеңдә утырасым килә,
Тоеп кулларыңның җылысын.
...Кайткан саен нигә миннән, әнкәй,
«Килдеңме, балам?» дип сорыйсың?

Ничек инде килим?! Очып кайттым!
Җан иңдергән изге нигезгә.
«Синең өең Казанда бит», — димә,
Күңелем ятмый минем ул сүзгә.

Туган йортка кайтып кына була! —
Тагын ничә йортың булса да.
Монда мине тибрәлдергән бишек,
Тәпи атлап чыккан бусага.

Инде күптән искергән булса да,
Паркет түгел булса да идән...
Дөньяның бу Җәннәт иңгән җире,
Мәккәм шушы минем, Мәдинәм!

Метр да җитмешнең яртысына
Тигезләшеп килсә дә буең, —
Газиз, кадерлерәк беркемем юк! —
Иртә уем синдә, кич уем...

Әни генә түгел, хәзер инде
Үзем әби кеше булсам да,
Син әнкәем минем тумышта да,
Бүген дә, иртәгә... кайчан да!

Синең янда үткән бала чагым
Серле әкият кебек мәл миңа!
Туган йортсыз, назсыз, тәмле сүзсез, —
Синсез үткән гомерем җәл миңа.

*11.10.2004*

## *Хатирә*

«Шәһәрләшеп» беттем инде тәмам...
Кыска итәк, биек үкчә киям.
«...маем», «бед...»ләр күптән төшеп калды,
«ич»ләр белән чуарланды сөйләм.
Эч серен кешегә бушату юк,
Күршеләргә кермим йомыш белән...
Чәнечке — сул, пычак уң кулымда
Булырга тиешен яхшы беләм.
...Болар барысы челпәрәмә килә
Баегыма кайтып төшү белән. —
«Кыдыл бодау» булам бер мизгелдә,
Эт-мәчегә хәтта сәлам бирәм.
Яланаяк чабам су буена,
«Башкорт ягы»н яңгыратып көләм.
Чишмәләргә иелеп сулар эчәм, —
Битләремне назлый бәбкә үлән.
Сарашлыдан зирек алкаларын
Өзеп алып, колагыма эләм,
Кулым сузсам — күккә кулым тия,
Кояш «качыш» уйный минем белән.
...Өйгә кайтсам, әнкәм аш пешергән
Мин ярата торган умач белән,
Өйалдына җәйгән ашъяулыгын,
Бер өем ит тора табак белән.
«Чәй эчәргә төш пешерәм» диеп,
«Булышып» йөри әнә камыр белән...
Көтү кайткач, хәтта сарыклар да
Ятсынмаслар мине, таныр, беләм,
Ә мин менә үземне танымыйм... —
«Минме соң бу?!» диеп, әле һаман
Гаҗәпләнеп торам күңелемнән.

*16.05.2003*

* * *

Әнкәй белән икәү чәй эчәбез,
Ни сөйләшсәк, шул сүз килешә.
«Алай ярамас!» — дип уйлап тормыйм,
Тарсынмыйм, оялмыйм мин һич тә.

Әнкәм миннән бер гаеп эзләми,
Бәйләнми һәр әйткән сүземә.
Телем белән «былбыллар сайратам»,
Сүзләр сайлап тормыйм үзем дә.

Шәһәрдә бит алай яшәп булмый,
Һәр сүзеңне үлчәп сөйлисең.
Дөнья тулы кеше арасында
Япа-ялгыз иңрәп йөрисең.

Анда сиңа бөтен кеше дошман,
Эч сереңне сөйләр кеше юк.
Кайгың бармы, шатлыкларың бармы —
Беркемнең синдә бер эше юк.

Әкрен-әкрен ваемсызлык баса,
Битарафлык били җаныңны.
Минем дә бит садә күңелемә
«Шәһәр җиле» килеп кагылды...

Эчик әле чәйләр тәмләп-тәмләп,
Гөр-гөр килеп икәү, энкәем.
Авыл җанын пакьләр өчен кайтты
Шәһәрләшкән газиз бәбкәең...

*2.11.2004*

* * *

Мин тартынам сиңа сыенырга, —
Сыендыммы, килә елыйсы.
Хәтерлисем килә, ничегрәк
Иде микән әнкәм җылысы.
Кагылуың телим чәчләремә,
Сыйпавыңны, назлы сүзеңне.
Ничә еллар наз күрмичә яшәп,
Тупаслыкка шундый күнелде.
Назлаучылар булыр иде анысы —
Һәр чиләккә, диләр, капкачы.
Их, әнкәем, синең назың белән
Назлаучыны ләкин тапсамчы!
Ул назны мин инде хәтерләмим —
Вакыт чоңгылында җуелган.
Тик шул наздан күңелемә минем
Мәңгелеккә садә уелган.
Исемә төшер, нинди иде ул наз —
Әнкәм назы, әнкәм җылысы.
Картайсам да, дәү әни булсам да,
Синең нәни балаң булыйм чы!
Әллә нишләп сыкрап куя күңел
Син, әнкәем, искә төшкәндә.
Бишекләрдә бер тирбәлер идем,
Белмәгәндә әллә нишләргә...
Әнкәй, бәгърем, назла әле мине!
Оят булса булыр... ни чара?!
Кояш баешына кереп барам
Ирсез... назсыз... горур... бичара...

*22.07.2003*

* * *

Салмакланды йөрешләрем,
Кылган гамәл һәм эшләрем;
Күз күрүләр тоныкланды,
Ашкын хисләр тынып калды,
Инәкәем!
Тыйнаклыгым чыкты өскә.
Күз яшемне тыям көчкә
Җылы сүз, җылы караштан.
Уйлар, уйлар... бертоташтан
Йөри башта өер-өер.
Инәкәем!
Сизеп торам: килми калмас картлык,
Килер.
Өмет итмим артык өлеш, —
Нәфеслелек юк ла яшьли.
Карап торам берни дәшми
Бугаз киереп акырганда кемдер, —
Чөнки усал түгел күңел
Бала чактан.
Инәкәем!
Уйчанландым, йомшардым,
Юашландым, тыйнакландым,
Елакландым...
Синең көчең, синең максат-гамәлләрең,
Гомер буе миннән нәрсә теләгәнең
Белдем хәзер, белдем хәзер...
Инәкәем!
Озын булсын гомеркәең,
Исән генә була күрче! —
Мин дә исән булыр өчен
Кирәк синең исәнлегең!
Ә мин... Шундый! Шундый!
Инәкәем! Син дигәнчә!
Һәм шулай булып калырмын
Ахыргы көнгәчә, гомергәчә,
Тар гүргәчә!

*19.11.2003*

* * *

Бүләк иткән ак шәлемне, әнкәй,
Иңнәреңә бер дә япмыйсың;
Керләнмәсен, диеп, төреп кенә
Иске сандыгыңда саклыйсың.

Мин бит аны сатып алган идем
Ашка барган чакта ябар дип,
Озак кайтмый торып сагындырсам,
«Кызым бүләге» дип карар дип.

...Ә син аны һаман кызганасың,
Кара тисә, дисең, керләнсә...
Ап-ак күңелеңә ак шәлкәең
Бик килешер иде югыйсә!

Ничә әйттең инде: «Шәлеңне, дип,
Үлсәм, кире алып китәрсең...»
Әй, әнкәем, ак шәлкәең сине
Алмаштыра алыр микән соң?!

*4.02.2005*

* * *

Киереп ач, әнкәй, капкаларны,
Ярым-йорты гына калдырма!
Гаярь аттай мин керермен ыргып, —
Кайттым бүген иләс чагыма,
Кайттым бүген яшьлек чагыма;
Күңелемнең лачын бөркетләре
Кыя эстәп канат кагына!
Сүнгән иде инде, сүнгән иде
Күңелне яктырткан соңгы шәм...
Һәм... чыкты да бүген күзге кояш!
Юк! Килешмәм әле, килешмәм
Тынлык белән, ваемсызлык белән,
Салмак йөреш белән — сөртенеп...
Ярсу атларымны җиктем менә! —
Бер әйләним әле ду! килеп
Авылым урамнарын,
Яшьлек бормаларын
Узып китим әле салулап! —
Япь-яшь чакны, һай ла, юләр чакны
Яши ләса күңел талымлап.
...Мин кузгалдым инде.
Борылу юк!
Тыйма атны, әнкәм, чү, дип, тт-ы-ыр-р-р! —
Мин ыргылып килеп кергән чакта,
Капкаңны киереп ачып тор! —
Хыял капкаларын ачып тор!
Һәм... үзең дә утыр! —
Булсын!.. Нәрсә?!
Сиңа — туксан! Миңа — илле биш!
Икебез дә исән!
Бераз гына исәр
(Кемдер әйтер)!!!
Тик... акыллы!
Шөкер, Аллам!
Шөкер! Исән ич!

*3.11.2005*

* * *

Бала чактан әнкәмнең бер сүзе
Колагымда чыңлый ник һаман:
«Авызыңа шайтан керер юкса,
Әппәреңне иттеңме, балам?!»

«Шайтан» дигән сүздән уттай куркып,
Чынга алып әнкәм әйткәнне,
Бер урынына дистә, йөз мәртәбә
Әйтә идем «Аллаһу әкбәр»не.

Шул «Аллаһу...» белән гомер иттем,
Улымны, кызымны үстердем.
Җаннарына иман нуры салып,
Оныгыма китереп җиткердем.

Хәзер менә онык «әппәр» итә,
«Шөкер!» диеп карап торалам...
Колагымда һаман әнкәм тавышы:
«Әппәреңне иттеңме, балам!»

*28.01.2006*

# Аклык юлдаш булсын безгә



* * *

Бер улым, бер кызым иде...
Бер улым булды тагын.
Оныгым бар! Җан бөртегем!
Алма битем! Илһамым!

* * *

Бөтен эшемне ташладым,
Кулым бармый бернигә.
Тәрәздән тәрәзгә йөрим:
«Хәзер оныгым килә, дип,
хәзер оныгым килә».

* * *

Күрегезче бу Ходайны!
Кылып куйды әллә ни —
Син һаман да әни әле,
Мин әби булдым, әни!

*2.11.2004*

* * *

Мактаныша хатын-кызлар:
«Мин — дәү әни, дәү әни!»
Тыңлап торам тыныч кына.
Исем китми әллә ни.

«Баланыкы — балдан татлы...»
Нәрсәсе татлы — белмим.
«Нишләп шулай әби булу
Куаныч икән?» — дим мин.

...Минем дә оныгым туды.
Әле бер генә күрдем. —
«Балдан татлы»ның мәгънәсен
Нәкъ шул минуттан белдем!

*2.11.2004*

* * *

Әй, ат җиктем, ат җиктем! —
Кидердем өзәңгесен,
Камыт, дуга, арканын,
Бәйләдем шөлдерен дә...
Утырып өлгер генә!
Утырттым мин барын да,
Кемгә кая барырга?
Дәү әни: «Кунакка!» — ди,
Дәү әтием: «Чәйгә!» — ди.
Әти белән әнием:
«Эшкә киттек, әйдә!» — ди.
Китим дисәм кузгалып,
Булмый гына бит барып!
Исемә төште шулчак —
Онытылган ыңгырчак,
Онытылган дилбегә! —
Белмәгәнмен ат җигә...
Куыйм дисәм атымны,
Табалмыйм чыбыркыны!
Ирешалмагач моратка,
Караштырып як-якка,
Бары да аттан төштеләр,
Таралышып беттеләр.
Әни алды китабын,
Әти ятты диванга,
Әбием белән бабай
Утырды чәй эчәргә,
«...Ярар инде, кунакка
Барырбыз, — дип, — иртәгә».
Ә мин... белмим нишләргә.
Үзе бераз оят та —
Җигә белмәгәч ат та...
Мин бит әле кечкенә,
Яшем бары өч кенә!

Өйрәнермен зур үскәч,
Яшем унөчкә җиткәч,
Җикмәм әле таякны,
Җигәрмен чып-чын атны!

*22.01.2006*

## *Улым бәбкә саклый*

Үзе нәни бәбкә кебек
Әвеш-тәвеш атлый;
Тик сер бирми,
Чыбык тотып,
Улым бәбкә саклый.

Безнең бәбкәләр янына
Чит бәбкәләр килсә,
Чыбык селтәп
Уңга-сулга,
Куркыткандай итә.

Файдага ярый бит хәзер,
Йоклап кына ятмый!
Бәбкәне — улым,
Улымны
Дәү әнисе саклый.

*12.05.1977*

* * *

Нәни әле минем онык — түмгәк кенә,
Кигәне — егерме дүртле күлмәк кенә.
Һәрнәрсәне белү уе, аңлау уе —
Сорау арты сорау бирә көннең буе.

Килсә дә ул тар сукмактан алпан-тилпән,
Сорыйм юри: «Минем улым кая икән?»
Тотып чәчен, борын, колак, авыз, күзен:
«Менә бит, — ди, — синең янда
мин бит үзем...»

Әле өчкә тулмаса да аның яше,
Бөтен эштә кул сузып ярдәм итмәкче,
«Дәү әнием, эшләмә, — ди, — үзем эшлим,
Үскән бит мин, олы малай, зуп-зур ич мин!»

Көрәк алып, кирәкмәгән җирдән казый. —
Ничек дөрес икәнлеген белми сабый.
Әй улкаем, эшчәнлегең, киң күңелең
Гомереңнең озынына җитсен, димен.

Һәрчак шулай ярдәмчел бул, эчкерсез бул,
Көчсезләргә онытма, дим, сузарга кул.
Иманны син юлдаш итсәң һәрбер көнгә —
Буең белән бергә үсәр бәхетең дә.

*31.08.2005*

* * *

— Ник саргайдың болай? — дип сорамагыз,
«Юкка янып көя бу» дип уйламагыз.
Чәнчеп-чәнчеп йөрәк әрни, җаным иңри, —
Газиз улым чирли минем, улым чирли.

Сабыемның йөзе сулган, ирене кипкән,
Күкрәк сөтем имәрлек тә хәле беткән;
Күзләреннән мөлдер-мөлдер яше тама.
Йә Раббым, ниләр кылыйм, бармы чара?!

Сыныйсың ла мине, Тәңрем, ниләр өчен, —
Әллә «Түзәр, сабыры җитәр...» дияр өчен.
Телем-телем сабыр җепләрем киселә,
Абау Аллам, аһ читен лә, бик читен лә!

Бу хәлемнең (сиңа мәгълүм!) чарасы бар!
Теләгемне кабул кылсаң, риза шуңар:
Мөмкин булса, чирен үземә алыр идем,
Улым өчен үзем генә авырыр идем.

*27.02.2003*

* * *

Кызым инде зур үсте:
Матур күлмәкләр сорый,
Көне буе караса да,
Көзгедән бер дә туймый.

Чәчләрен әле тегеләй,
Әле болайга тарый,
Әле кызыл, әле зәңгәр
Күлмәген киеп карый.

Аның инде тиз-тиз генә
Әни буласы килә.
...Мин кызыгып карап торам:
Бәби буласым килә.

* * *

*Кызым Гөлназга*

Кошлар бүген бала очыралар...
Мин дә, кызым, сине очырдым.
Аердым оямнан кошчыгымны, —
Иртә түгелме, дип, борчылдым.
Канатларың ныгымаган килеш
Мин очырдым сине... ашыгып...
Абына күрмә, кызым, егыла күрмә,
Вакытыннан алда талчыгып.
Канатларың каерылмасын, балам,
Язмыш җиле каршы искәндә;
Ходай ныклык бирсен көрәшергә,
Тормыш давылларын кичкәндә,
Кошлар бүген бала очыралар...
Бушап калды оям минем дә...
Моң күрмәсәм иде йөзләреңдә,
Яшь күрмәсәм иде күзеңдә...

*24.04.2002*

* * *

*Кызым Гөлназга*
*27 яшь тулу уңаеннан*

Кызым минем!
Мин сине бу якты дөньяга
Олы сөю белән китердем.
Күңелемнең бөтен садәлеген,
Бар назымны биреп үстердем.

Күңелеңә иңгән садәлеккә
Тимәсен дип кырыс кул җиле,
Иңем генә түгел, җаным белән
Бардым гел-гел ышыклап сине.

Уйламадым, дөнья каралары
Кизәнәсен синең күңелгә.
Син бирешмә, кызым, башың имә,
Гел алга бар, көрәш, җиңелмә!

Мин ышанам алда бары бәхет,
Куанычлар сине көткәнгә.
Яшә үз-үзеңә тугры булып,
Үкенмәслек итеп үткәнгә!

*20.07.2005*

* * *

*Киявем Элмирга*

«Элмир улым» диеп дәшәм сиңа,
Чын күңелдән ихлас яратып,
Эш-гамәлең, әйткән сүзең өчен
Торам һәрчак эчтән җан атып.

«Улым» дию ялагайлык түгел,
Түгел куштанлану, төчелек.
Үз баламдай сине якын итү —
Җан олылык, күңел кечелек.

Кабул иттем сине бер күрүдә —
Хәерлегә булсын азагы.
Минем яктан кире уйлау булмас,
Бары синнән тора калганы!

*14.12.2005*

* * *

*Назыймга*

Давылларга каршы
Берьялгызым барып,
Берчак, түзалмыйча,
Туктамаммы арып,
Сынмаска күңелнең
Иң нечкә кыллары –
Җитәкләп барыр соң
Мине кем куллары,
Ыргытмасмы язмыш
Тирән упкыннарга...
Дип кайгырмыйм әле,
Синдәй ярым барда,
Синдәй парым барда!

*29.10.1986*

## *Назыймга*

Назыйм Хикмәт булмасаң да,
Хикмәтләрең бар синең,
Мине шаян яки уйчан
Итмәкләрең бар синең!

Ярты сүземнән аңлыйсың,
Миңа иң кирәк чакта. —
Китералмыйм күз алдына
Үземне синнән башка!

Балаларның әтисе син,
Ә минем — газиз ирем!
Карыйм да куанып куям:
Юк бер килмәгән җирең!

...Назыйм Хикмәт булмасаң да,
Хикмәтләрең бар синең:
Мине гел бәхетле итәр
Исәпләрең бар синең!
(Беләм бит мин!)

*23.12.1981*

* * *

Малеевка урманында йөрим,
Һәрбер агачына тукталып:
Күккә кулын сузган наратларга
Каен кызы карый сокланып.

Күкрәп үскән усак егетенә
Япь-яшь чыршы килеп сыенган.
Имән кәүсәсенә тукраннарның
Гыйшык җыры гүя уелган.

Тук-тук кына тукран җыры булып,
Имәннәргә имән эндәшә...
Тукраннар булып тукылдарсың,
Сандугачлар булып чутылдарсың,
Эчләреңдә сагыш дөрләсә.

Агачларның да бит үз язмышы:
Кайсы парлы, кайсы ялгызак...
Ялгыз үскән агачларга карап,
Йөрәккәем куйды айгызап.

Ялгызлыклар басты иңнәремә —
Җиңәрменме язмыш сынавын?!
Ялгыз агач хәле, белмим, ничек —
Адәм баласына, һай, авыр...

*Малеевка, март, 1990*

* * *

Мин яраттым сине
Җаным-тәнем белән.
Яныпкөеп. Дөрләп. Ут кабып.
Ләкин синең саран күңелеңдә
Кабынмады җавап учагы.

Син сындырдың
Ике канатымны...
Мин егылдым. Хәлсез. Әлсерәп.
Суга гына белгән ике кулың
Йөрәгемә үрелә... җан сорап.

* * *

Ак күлмәгем, ак күлмәгем
Бер киюдә каралттым...

Ак күлмәгем күптән салдым инде...
Караларын хәзер мин киям.
Гомер үтеп бара, ләкин сине
Яшьлегемдә кебек мин сөям.

Кара күлмәгемнең якаларын
Ак нәкышләр белән бизәдем...
Сине сөйгән кебек, мәңгегә, дип,
Беркемне дә кабат сөймәдем.

Кара кидең ни дә ак кидең ни —
Йөрәгеңне сагыш биләгәч...
Гомер юлы буйлап ахыргача
Икәү бергә атлап килмәгәч.

Ак күлмәкләр тиз карала икән, —
Шуңа кабат аклар кимәдем.
Тик күңелем генә боек һаман,
Яшьле һаман никтер күзләрем...

*14.11.2005*

* * *

Тере мәет кебек, берьялгызым,
Урманнарга барып урап кайттым.
«Пар каеннар безгә тиң түгел...» дип,
Ялгыз каен төпләрендә яттым.
Ялгыз каен төпләренә ятып,
Җир-әнкәмә түктем яшьләремне, —
Башларыма гына сыйдыралмый
Киләчәктә ялгыз яшәремне.
Киләчәктә ялгыз яшәүләрем
Башка сыймаса да, күз алдымда...
Сагышларга каен түзәдер дә...
Минем башкынаем түзалырмы?!
Башкайларым әгәр түзалмаса,
Ялгыз каеннарга сыенырмын. —
Читтән карап узган кешеләргә
Каен белән парлы тоелырмын...
Каен белән парлы тоелсам да,
Ялгызлыклар булыр берәм-берәм...
Тик барыбер, ялгыз каен эзләп,
Көзге урманнарга барып керәм...

## *Җуйдым сине*

Салкын чишмәләрдән су эчсәм дә,
Җаным тынмас, сусау бетмәс инде. —
Дәрьяларга төшкән энҗе кебек,
Җуйдым бугай сине, җуйдым сине.

Бәхетебезне кайчан күпсенде дә,
Бар дөньяга чәчте вакыт җиле. —
Көннәремнән, әллә төннәремнән
Җуйдым инде сине, җуйдым сине.

Иртә шиңгән назлы гөлләр кебек,
Ник сүрелде күңел, нигә сүнде? —
Күзләремнән түгел, күңелемнән
Җуйдым инде сине, җуйдым сине...

*21.07.1984*

* * *

Мин яраттым сине яшьлегемдә,
Яраталмас булып кабаттан.
Үтсәләр дә еллар, аерылса да юллар,
Яраттым, яратам, яратам!

Якты дөньяларны ташлап киттең,
Мәңге кайтмас өчен кабаттан...
Көндәлеккә язып калдыргансың:
«Яраттым, яратам, яратам!»

...Зиратларга киләм — синең янга.
Иртән килсәм, киләм кабаттан.
Кабер ташың миңа пышылдый күк:
Яраттым, яратам, яратам!

Язмышымнан һаман сине сорыйм,
Эзлим икән кайсы тарафтан?
Мәңге сиңа тугры калыр җаным. —
Яраттым, яратам, яратам!

*24.05.2005*

* * *

*Ирем Назыймга теге дөньяга хат*

Йә,
Ничек анда хәлләр җиде күктә?
Сизеп торам: бик тә әйбәттер.
Юкса күптән хәбәр салыр идең,
Хәлләремне сорап, жәлләп бер.
Киткәнеңә ун ел булды инде...
Шуннан бирле ләм-мим берәр сүз!
Ә мин монда фани дөньяларның
Ачы-төчесенә әйдә түз!
...Юкса без бит меңнәр арасыннан
Эзли-эзли генә табыштык.
Алла насыйп иткән никах белән
Мәңгелеккә диеп кавыштык.
Йә, нәрсәсе җирнең ошамады?
Нигә киттең бик-бик ашыгып?
Әллә туйдырдымы яшәү «монда»
Бер хатынга гына баш булып?
«Анда» ничек? Күпме хур кызлары —
Ун — алдыңда, бишме — артыңда?
Тәнсез генә күккә иңгән жаның
Салдылармы тере ялкынга?!
Нәрсә, минем назым җитмәдеме,
Ризыкларым тәмсез идеме,
Тегү, бәйләүләрем оста түгел,
Буем — кәтүк, ямьсез идемме?
Ошап җитмәдеме җигелеп тарту,
Бөтен эшкә сүзсез өлгерү,
«Ирләр эше» диеп бүлеп тормау,
Чәчем белән җирләр себерү?
Тар булдымы әллә дүрт кешегә
Өч бүлмәнең бер зур бүлмәсе,
Ике бүлмәдәге күршеләрнең
Артык идеме әллә берәрсе?

Бер ул белән бер кыз әз идеме,
Әллә, киресенчә, күбрәкме?
Җиде күккә ни дип китеп бардың,
Ни җитмәде, ниләр кирәкте?
Егерме ел яшәгән идек бит,
Иткән булыр идек илле дә...
«Пар канатлар» диеп, күккә чөеп,
Әй мактарлар иде безне дә...
Уйламадыңмыни хатыныңа
«Ялгыз» дигән мөһер сугыласын,
Сүзе — үтмәс, күздән яше кипмәс,
Адымнары кыек буласын?!
Сөелергә генә туган җаны
Эт типкеләренә каласын,
«Ятим» мөһре суккан балаларың
Берьялгызы сөйрәп барасын?!
...Безнең «монда» кемдер байлык җыя,
Кемдер бөлә бара көннән-көн...
Кайтып күрсәң, кая эләктем дип,
Хурлыгыңнан кабат үләрсең.
Кыш көнендә яңгыр явып китә,
Җир убыла, янгын, су баса...
Сугыш, үтереш, фәхеш, наркоманнар...
Сәрхуш, хөсет, нахал, илбасар...
...Берни уйламыйча ятасыңмы,
Хур кызлары белән типтереп?! —
Уйлар булсаң, хәлем белер идең
Һич югында елга бер килеп...
Кемнәр белсен хәзер җанкаеңда
Нинди гамь икәнен, нинди уй...
«Берәр заман килеп җитәрләр...» дип,
Үз яныңнан урын алып куй.

*20.05.2004*

* * *

Көзнең соңгы ае...
Көн уртасы,
Сукмак буйлап атлыйм ялгызым.
(Парлыларның гына юлы кыска,
Ялгызларга сукмак та озын...)
Күңелемдә — бушлык...
Уйлар, көйсез әби кебек,
Башкаема керми йөдәтә.
Шуңадырмы
(Минем өчен гайре табигый хәл),
Тирә-юньне әрсез күзәтәм.
Әнә!
Иске өйне яндырганнар —
Яшь каенны өткән ялкыны.
Каенкайның кара кәүсәсендә
Тормыш түгел — үлем шаукымы...
Тыңлап тордым чырык-чырык иткән
Көзге песнәкләрнең җырларын.
Мендәр сүткән кебек пыр-пыр килеп,
Саесканның очып узганын.
Көзге яфракларга борын төртеп,
Эт малае йөри иснәнеп,
Карт наратка кунган тукранның
Күлмәгенә исең китәрлек:
Башы — кызыл кәпәч кигән кебек,
Койрык очы ачык ямь-яшел...
Янәшәдә ялгыз ихатадан
Җыры ишетелә әтәчнең...
Тын һавада тәмле төтен исе —
Мунча якканнардыр, ахрысы...
Рәхәт сыман булып китте яшәү, —
Барган саен кила атлыйсы.
Атлыйм һаман, адым саный-саный,
Таулар төштем, мендем үрләргә...

Зират тирәсенә җиткәнмен бит,
Ә зиратта... кеше күмәләр.
Шушы күзге хозурлыкны ташлап,
Китә кемдер соңгы сәфәргә...
Песнәк, әтәч, тукран, этләр белән
Мин яшәргә телим, яшәргә!
...Тау астында тормыш кайный иде.
Үрләрендә — кабер тынлыгы.
Юк, кирәкми! Кермим зиратларга, —
Мин... тормыш ягына борылдым...

* * *

*( Шул ук урын — ун ел үткәч)*

Көзнең соңгы ае. Көн уртасы.
Сукмак буйлап атлыйм кабаттан.
Имеш, шактый еллар элек булган
Хатирәләремне яңартам...
Тукраннарны эзлим, саесканны,
Эт малае, йөргән иснәнеп...
Ни гаҗәп хәл: берсе дә күренми!
Барган саен куям сискәнеп.
Ут ялкыны өткән каенкайның
Кәүсәсеннән эз дә калмаган...
(Шулай «шома» итеп бу җирләрне
Замана җилеме ялмаган?!)
Ялгыз ихатадан җилләр искән!
Әтәче дә кая киткәндер?! —
Хуҗа агай аны, күптән суеп,
Итен шулпа итеп эчкәндер...
Һаваларны ярмый төтен исе,
Өе белән беткән мунча да...
Бер-берсенә охшаш таш йортларның
Яшәү рәвеше дә бер чама.
...Таулар төшеп, текә үрләр мендем
Һәм... юлыктым шул ук зиратка!
Әтәч, тукран, маэмай, кешеләр юк,
Өйләр беткән. Ләкин — зират бар...

*19.11.2004*

* * *

Яшел чирәм.
Кояш көлә.
Яшь балалар чыр-чу килә.
Йомгак кебек сары бәбкә
Өзмәк була яшел чирәм,
Ава-түнә...
Хәле җитми.
Тагын, тагын тартып карый,
Булмый!
Сабый көлә.
Атлап китә ава-түнә
Чирәм буйлап — киләчәккә!
Әби елый:
Бар микән, дип, күрәчәкләр
Җәй җиткәнен җәрөнгә* дә...
Әби елый...
Күз яшьләре бит сырына
Бөялеп кала.
Әле яңа кыз идем, диеп уфтана,
Кая китте, кая китте?!
Күзләр сүнгән, кул калтырый,
Аяк тотмый...
Бары да бетте, бары да бетте!
...Ә тереклек
Каударланып яшәү сутлый.
Әби елый...
Китәр иде яшел чирәм өсләреннән
Йөгереп кенә яшь чагына,
Хәле җитми.
Сөйгәне дә гүрдә күптән.
Бер күрергә зарлар булып гомер үткән...

---

*Җ ә р е н г ә — киләсе елга.

Әби елый...
Оҗмахтамы,
Тәмуг микән язганнары?
Әби елый...
Сагынырга калды бары яшь чакларны,
Сөйгән ярны, —
Сөя-сөя оныкларны;
Күзли-күзли офыкларны
Чыгыштан түгел, баештан...
Әби елый...
Яшел чирәм! —
Суты тула бар җаныңа!
Бу дөньяның хушбуйлары сыйган аңа.
Бала тоя.
Бәбкә тоя.
Әби тоймый.
Быел никтер чирәмнең дә
Хуш исе юк диеп уйлый...
Яшел чирәм...
Кояш көлә.
Язлар килә.
Бала көлә,
Әби елый әллә нигә...

*14.01.2006*

* * *

Вак-вак кына басып,
Пар чиләкләр асып,
Кызлар китте әнә суларга.
Сулар ага ташып,
Йөрәк куя ярсып,
Күзең төшсә шушы кызларга.

Ак алъяпкыч кигән
Нечкә генә билләр
Алган чакта сулар иелеп,
Буламыни түзеп,
Кызлар биле кебек,
Егет күңеле китә өзелеп.

Көянтәләр асып,
Вак-вак кына басып,
Кайтып килә кызлар чишмәдән. —
Сулар ага икән,
Йөрәк яна икән,
Димәк, яшьлек әле үтмәгән,
Димәк, сөю әле бетмәгән,
Димәк, гомер әле үтмәгән.

## *Мең карадым, бер күрдем*

Кара чәчеңне үргәнсең,
Толымнарга толымлап.
Күңелемне юатыймчы,
Синең хакта җыр җырлап.

Зәңгәр күлмәк, балитәк —
Кайсы оста өлгесе?!
Апасына караганда
Сөйкемлерәк сеңлесе.

Читегеңнең нәкышләрен
Арчадамы чиктердең?
Күзем ала алмый торам —
Мең карадым, бер күрдем.

Ак алъяпкыч бәйләгәнсең
Талдай нечкә биленә.
Алып кайтыйм әле сине
Әнкәемә киленгә.

Бохарадан кайтарттыңмы
Сөрмәләрне күзеңә?
Әнкәемә килен булсаң,
Яр булырсың үземә.

Йөзләреңә бик килешә
Озын керфек, кыйгач каш.
Пар былбыллар булып кына
Сайрашырбыз кавышкач.

*2.02.2006*

## *Казаныма мәдхия*

Казанымда бүген карлар ява,
Агачларны ап-ак бәс сарган.
Ап-ак күлмәк киеп, чистарынып,
Яңа көнгә керәсең, Казан!
Еллар имин булсын,
Табыннар мул булсын,
Бар халыклар тату яшәсен.
Көннән-көнгә шулай матурланып,
Әй, Казаным, һаман яшәр син!

Синең белән уртак шатлыгыбыз,
Эш-гамәлләр уртак, уй-теләк.
Халкыбызның даны, күрке булып,
Мәңге шулай яшә син гөрләп.
Мең яшьлек Казаным,
Меңьяшәр Казаным,
Киләчәккә безне дәшәсең.
Мең яшькә җитсәң дә, япь-яшь булып,
Әй, Казаным, мәңге яшә син!

Дөньяда дан тоткан калалар да
Бүген сиңа көнләп карасын.
Иманың саф, кыйблаң туры синең,
Көннән-көнгә алга барасың.
Юлларың уң булсын,
Бәхетең мул булсын,
Дөнья карап торсын таң калып.
Халкымның син йөз аклыгы, диеп,
Дәшәм сиңа бүген сокланып,
Горурлыгым минем, Казаным, дип
Дәшәм сиңа бүген шатланып.

*24.12.2003*

* * *

*Дустым шагыйрә*
*Халисә Мөдәррисовага*

Бүген Казан каласында
Җилләр кыйбладан исә. —
Юнәлешен үзгәртә җил,
Халисә килде исә.
Килә дә ул дер селкетә
Шанлы Казан каласын;
Күңелең ташып түгелгәнне
Сизмичә дә каласың.
Уфа хәлләрен сөйли ул,
Казанныкына кушып;
«Нигә килеп чыкмыйсыз?» дип,
Безне ала орышып.
Җыя безнең һәммәбезне
Чәй өстәле артына,
Җан җылысы җитә аның
Яшенә дә картына.
Китә шигырь укышулар,
Бер-береңне узышып...
Җырлыйсың да, елыйсың да —
Моң буасын ерышып...
Әни дә кебек ул сиңа,
Якын дус та, сердәш тә...
Тәнкыйтенә дә түзәсең —
Халисә дөрес әйтә.
...Ничек килгән дер селкетеп,
Шулай китеп тә бара...
Шул хәлдән соң Халисәне
Сагынмый түзеп кара!

*31.08.2004*

* * *

*Күренекле режиссер*
*Госман Әхмәтҗановка*

Сез үзегез зур бер дәвер
Сәнгать дигән дөньяда.
Җир йөзендә әкият яши,
Яши әле сез барга.

Сезнең гаярьлеккә карап,
Чәчләр үрә торырлык.
Табылырмы тагын берәү
Сезне алмаштырырлык?!
(«Без аны беләбез!» дию,
Безгә чиксез горурлык!)

Сез салып калдырган юлдан
Җиңел безгә барулар.
Югалтулар булмасын ул,
Булсын мәңге табулар!

*24.06.2005*

* * *

*Кайбыч районы башлыгы*
*Җәүдәт Гаффаровка*

Илле яшьтә ирләр нинди була? —
Чабып барган атка сикереп менә.
Илле әле кеше гомеренең
Кыл яртысы гына, үре генә.

Яшьнәп яшә әйдә, күкрәп яшә,
Йөрәгеңдә ялкын дөрләп торсын! —
Йөзгә җиткәч, узган гомерең өчен
Соңга калып үкенмәслек булсын.

Гел янында булсын җан дусларың —
Иң кирәк чагында таянырга.
Бүгенгедәй чын кеше булып кал,
Йөрсәң дә син кайчан кайда гына.

*15.04.2000*

## *Боек булма, бөек бул!*

*Теш табибы*
*Харис Әмирхановка*

Бар шагыйрьләр Ирек мәйданында
Шигырь укып яткан заманда,
Минем уем Тукай белән сине
Бер чыбыктан «сөрә» һаман да.

Юкка гына түгел булыр синең
Тукай туган көндә тууың.
Тик теләмим, Тукай күңеле кебек,
Күңелеңнең боек булуын.

Тукай кебек ләкин бөек бул син! —
Шигырь язма, анысы нипочем! —
Алтын кулың белән тешсезләрне
Тешле итеп бетер, ичмасам!

*26.04.1989*

* * *

*Җырчы Зөһрә Сәхәбиевага*

Син — күңелнең рушандай ак көзгеседер,
Хаклык вә тугрылыкның бер билгеседер,
Яшәү рәвешенең дөрес өлгеседер, —
Син булмаган җирдә яшәү күңелсездер.

Ак күңелгә авырлыклар күбрәк куна,
Сабырлык вә түземлекләр телим сиңа.
Күрми кайгы яшә син гомер буена,
Моңлан бары, уйлан бары — җырда гына!

*31.12.1987*

* * *

*Җырчы Фән Вәлиәхмәтовка*

«Юктыр, булмас!» дисәң дә,
Булып тора, һәрхәлдә,
Кемнәрдәдер бик күп сәләт
Булганы мәгълүм фәндә.

Фәндәгесен кем белгән,
Кем барган да кем күргән?!
Кирәкми безгә башка фән,
Үз Фәнебез бер дигән!

Бәхәсләшеп ни файда,
Аңлашыла болай да.
Бер биргәнгә бирермен, дип
Әйткән ди бит Ходай да.

Эзләп тормыйк бүтәнне,
Әйдәгез карыйк Фәнне. —
Кайсыгызның күргәне бар
Моннан да гаҗәп хәлне:

Оялмый һич берсе дә —
Эт тә җырлый, бете дә...
Тик моң дигәннәре генә
Тәтеми һәр кешегә.

Ә Фәнгә биргән өеп
Гәүдәне дә, моңны да;
Булгач, әйдә булсын дип,
Тоттырган гармунны да.

Менә бит хикмәт нәрсә! —
Барысы да Фән дигәнчә. —
Онытасың дөньяны,
Әгәр җырлап җибәрсә.

Йомгаклап әйтү кирәк:
Андый кешеләр сирәк.
Фәнне бездән аермасын
Дип, дуслар, телик теләк.

*25.01.2006*

* * *

«Аһ, җаныем, Бибисара...» — дип
Сузса Әсхәт Хисмәт,
Тарая башлаган күңел
Куя әллә нишләп.
Уйлыйм: «Монда...
Моңдадыр, — дип, — хикмәт...»

*16.05.2003*

* * *

Нигә һаман «Кайбыч...» дип язасың,
Син бит, диләр, түгел Кайбычтан.
Белмим, никтер шундый якын иттем. —
Бу ярату түгел ялгыштан,
Бу ярату түгел ялагайлык,
Бу ярату түгел вакытлы; —
Һәр йортына, чишмә, елгаларга
Һәм кешеләренә гашыйкмын.
Кайбычларда сулар тирәнрәк,
Кайбычларда сулар серлерәк,
Урманында үскән юкәләр дә,
Чәчәкләр дә башка төрлерәк.
Колач җәеп каршы чыгып тора
Чүти, Борындыгы, Кошманы...
Аш-сулары, катык, каймаклары
Дус иттерер хәтта дошманны.
Үсеп килә яңа Галияләр,
Шәүкәт, Сара, Әбрар, Шәкүрләр...
Беркөн килеп алар бу дөньяга
Үз сүзләрен әле әйтерләр.
Без «...Кайбычым» диеп язган җырны
Элеп алыр яңа тавышлар...
Барыр юлы якты булган өчен
Гашыйк та инде мин Кайбычка!

*Май — август, 2005*

* * *

*Шәфәгать Тәхәветдинов авызыннан*

Ничә еллар төшләремә кереп
Җанымны җирсетә бер сусау —
Итәгенә Зәй елгасын салып,
Әлли-бәлли иткән Кызыл тау;

Чыгырларың чыңы колагымда,
Тимерче Нуриның коесы.
Тешне сындырырлык салкын суның
Йөрәгемә күчкән җылысы.

Әрәмә буенда келдер-келдер
Он тарттырган иске тегермән
Яңа пешкән арыш икмәгенең
Тәмен телләремә сеңдергән.

Хәтер пәрдәләрен ачып кына
Узган гомеремә күз салсам,
Татлы бер төш булып искә төшә
Газиз туган җирем Габдрахман.

*14.11.2005*

* * *

Сыенып утыра Баулы
Урал тау итәгенә.
Кайтам, һаман сагынып кайтам
Еракка китәмен дә.

Ык сулары Баулыларда
Агадыр ярсып, шаулап.
Табигать иң матур өлге
Биргән Баулыга сайлап.

«Һәр эштә мактаулылар» дип,
Җырланмый юкка гына; —
Аңларсың моның мәгънәсен
Баулыда тусаң гына.

Тыйнак кына елмаялар,
Мактауга ис китмичә.
Көн саен яңарсаң да син,
Сөям Баулым искечә.

*27.02.2003*

* * *

Көн ягына карап юлга чыктым...
Юлларымның чиге — Әлкигә.
«Бәлки, калырмын да Әлкидә...» — дип,
Юлдаш итеп уем «бәлки»гә.

«Офык чикләрендә Әлки инде...»
Дип, юлдашым миңа эндәшә.
Мин, «Әлки» дип, аннан көнлим бүген,
Ул, «Мөслим...» дип, миннән көнләшә.

...Яшьлек елларымда мине язмыш
Бәйли язган иде Әлкигә!
Менә тагын... Бу юлысы инде
Мәңгелеккә булыр бәлки дә...

*2.01.2001*

* * *

Тауларга сыенып,
Сихәт иле булып,
Җәйрәп ята «Бәкер» курорты.
Килеп яшәп кара,
Җанга уелып кала
«Тургай», «Аккош»ы, «Сандугач»ы.
Карларның да монда
Ява агы гына,
Кошларның да сайрый моңлысы.
Суы, ләме белән
Тәнгә сихәт бирә
Табибларның күңел җылысы.
Вакыт бик тиз үтә,
Китәр көн дә җитә. —
Сагыныр күңел һаман бу якны.
Изге төбәк булып,
Күңелгә уелып,
Мәңге яшәр «Бәкер» курорты.
«Бәкер» курорты, «Бәкер» курорты!
Шифа-дәваңнан
Сихәтем артты.
Кайда йөрсәм дә,
Ниләр күрсәм дә,
Сагыныр күңел һаман бу якны.

*16.02.2000*

## *Кемгә нәрсә*

Бурап-бурап карлар ява,
Күз ачкысыз — урамда.
Тәрәзәдән карап тора
Ике кеше буранга.
Малай:
— Әни!
Карлар төшә, карлар төшә,
Бөтен җир тулыр инде!
Чана шуарга урамда
Таулар да булыр инде.
Әнисе:
— Улым!
Карлар төшә, карлар төшә...
Авылда явар микән?
Уҗымнарга салкын тияр —
Кырларда кар бар микән?!

*23.12.1981*

* * *

Карлар ява, карлар ява...
Ап-ак әле ул күктә.
Нигәдер кап-кара була,
Шәһәр җиренә төшсә.

Каралата мәллә аны
Кара бәндәләр җаны?
...Хәтеремдә, бала чакта
Авылымның ак кары:

Күзләреңне чагылдыра,
Җаныңа тула кереп,
Күңелеңне сафландыра —
Авыл кешесе кебек!

Нигә сафрак күңелләре
Авылда кешеләрнең? —
Күпме яшәп бу дөньяда
Мин шуңа төшеналмыйм.

Бусы аңлашылмаса да,
Шунысы бәхәссез һич тә:
Шәһәргә нигәдер — кара,
Авылга ак кар төшә!

*9.01.2002*

* * *

Тукталышта басып торам.
Халык йөри тыз да быз.
Чут-чут итеп үбешәләр,
Нәфесен тыя алмаган
Бер егет белән бер кыз.

Кызыктырмый гамәлләре,
Салмый ялкынлы утка, —
Җанны җанга тарта торган
Олы мәхәббәт юкка.

Дөнья хәлләрен күзәтеп,
Урамда торам басып.
Көч-хәл атлап китеп бара
Бер-беренә сыенышкан
Бөкшәеп беткән карт белән
Бөкшәеп беткән карчык.

Көнләп торам. Көнләшерлек
Сәбәп тә юк югыйсә...
Бәхетләргә туендырып,
Бер-беренә сыендырып,
Аларны якты дөньяда
Олы мәхәббәт йөртә шул,
Тигез мәхәббәт йөртә...

*25.11.2001*

* * *

Бу тормышта ак һәм кара
Һаман чиратлашып бара. —
Кайчакта ак, кайчак кара
Язмышларга тамга сала.

Гел ак кына булсын, димә,
Кирәктер бераз кара да, —
Акның кадерен белергә,
Яшәү мәгънәсен аңларга.

Кара көчләр, кара төсләр
Ак өстенә тап төшермәс.
Ак җанлылар каралыкны
Төннәрдән көнгә күчермәс.

Аклык юлдаш булсын безгә,
Кара күлмәкләр кисәк тә...
Бүгенгедән акны алып,
Илтик, дуслар, киләчәккә.

* * *

Гомерләр тормый шул
Гел тоташ шатлыктан,
Борчулар, кайгылар да килә.
Борчуың бүлешер,
Кайгыңны таратыр
Дусларың булсыннар гел бергә.

Кояшың көлгәндә,
Шатлыклар килгәндә,
Дусларың янына килсеннәр.
Бергәләп көлешеп,
Шатлыкны бүлешеп,
Яшәүгә ни җитә, дисеннәр.

Иң садә йөрәктән
Мин сезгә эндәшәм,
Килегез сез миңа, дусларым!
Табыным түрендә
Мәңгегә, гомергә
Тойыйм мин, белим мин сез барын!

* * *

Су буенда — ап-ак казлар,
Урманнарда — алтын яфрак,
Бакчаларда — татлы алма.
Әй, син, Кешем!
Дөнья мәшәкате диеп,
Шул бәхетне күрми калма.

Ак каз кебек ап-ак күңелең,
Алтын яфрак кебек ярың,
Сөюегез — татлы алма.
Әй, син, Кешем!
Дөнья мәшәкате диеп,
Шул ләззәтне тоймый калма.

...Үтеп бара ап-ак гомер.
Узган еллар — алтын яфрак.
Алдагысы — татлы алма!
Әй, син, Кешем!
Дөнья мәшәкате диеп,
Гомер кадерен белми калма!

*7.10.1999*

* * *

Күңелемне назлап тора
Әллә дога, әллә җыр:
«Алла боерса, Ходай кушса,
Барысы да әйбәт булыр!»

Иртән күземне ачканда,
Шуны әйтеп уянам,
Көн эчендә әллә ничә
Кабатлыйм аны һаман:
«Алла боерса, Ходай кушса,
Барысы да әйбәт булыр!»

Сез дә кабатлагыз, дуслар,
Зыяны юк ул сүзнең!
Бәхете күп була, диләр,
Шулай әйткән кешенең:
«Алла боерса, Ходай кушса,
Барысы да әйбәт булыр!
Әйбәт булыр!»

*5.08.2001*

## *Эчтәлек*

Якты моңнар иясе *Харрас Әюп* . . . . . . . . . . . 5

**Рәхмәт сиңа, сөю, телгәләдең...**

«Шигырь ул — күңелнең Коръәне...» . . . . . . . . . 8
«Яшь чагында, әйтегезче...» . . . . . . . . . . . . . 9
«Әй, туктагыз!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
«Рәхмәт сиңа, сөю, телгәләдең...» . . . . . . . . . . 10
«Күзләремә сөрмә, әй, тартаем...» . . . . . . . . . . 11
«Дөрли-дөрли яна-яна...» . . . . . . . . . . . . . . . 12
«Кавыштырды безне август төне...» . . . . . . . . . . 13
«Гомер буе җыйган серләремне...» . . . . . . . . . . 14
Бер адымга гына... . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
«Син булмасаң, бу дөньяның...» . . . . . . . . . . . 15
«Бәхет бит ул, олы бәхет бит ул...» . . . . . . . . . 16
«Синнән элегрәк тусам да мин...» . . . . . . . . . . 16
«Белмим: яз таңында иң беренче...» . . . . . . . . . 17
«Инде кышка җыенып йөргән чакта...» . . . . . . 18
«Сыздырып ла гармун уйнап узды...» . . . . . . . 18
Тик син диеп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
«Үләннәргә чыклар төшеп...» . . . . . . . . . . . . 20
«Янымa ук килеп утыр...» . . . . . . . . . . . . . . 21
«Таңнарда мин изге кояшка бакканчы...» . . . . . . 22
«Синең белән бергә яшәү...» . . . . . . . . . . . . . 23
«Мин яратам сине. Шулай өзелеп...» . . . . . . . . 24
«Мәхәббәтне әче диләр...» . . . . . . . . . . . . . 25
«Сөям дип, сөймимен дип...» . . . . . . . . . . . . . 26
«Әйдә китик әле урманнарга...» . . . . . . . . . . . 26
«Мәхәббәт хакына...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Шулайдыр... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
«...Сизеп торам: бу, мөгаен...» . . . . . . . . . . . 29
«Әгәр минем хакта сорасалар...» . . . . . . . . . . . 29
«Киттең менә тагын...» . . . . . . . . . . . . . . . . 30
«Бер генә көн сине күрми торсам...» . . . . . . . . . 31
«Син килдең дә... китеп бардың...» . . . . . . . . . 31
«Нигә миңа һаман учлап-учлап...» . . . . . . . . . . 32
«Син берзаман мине онытырсың...» . . . . . . . . . 32

«Көнләмә син мине, көнләмә...» . . . . . . . . . . . 33
«...Дүрт ягың кыйбла...» диден бүген...» . . . . . . 34
«Сугышкан да берәү...» . . . . . . . . . . . . . . . . 34
«Син кайчандыр бүтән идең...» . . . . . . . . . . . . 35
«Син миннән сүзеңне кызгандың...» . . . . . . . . . 35
«Күңелеңә уелып калыр» . . . . . . . . . . . . . . . 36
«Саубуллашмый гына китеп бардың...» . . . . . . . 36
«...Күзләреңдә нинди сагыш?» — димә...» . . . . . 37
«Ташлаштык, score яратуларга...» . . . . . . . . . . . . . 37
«Аерылганга әле минут та юк...» . . . . . . . . . . 38
«Мине сагынудан синең дә...» . . . . . . . . . . . . 39
«Төнге ут күрсәң тәрәздә...» . . . . . . . . . . . . 39
«Үзең мине ташлап киткәч...» . . . . . . . . . . . . 40
«Син сизми дә калдың: мин бит сине...» . . . . . . . 41
Син мине күрмәдең . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Әле мин сине гафу итмәдем . . . . . . . . . . . . . 42
Якты сагыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
«Бер җавапсыз, газиз башымдин...» . . . . . . . . . 43
Орышам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
«Уйла, зинһар, исеңә төшер мине...» . . . . . . . . . 44
«Сиңа ярты җаным ярып бирәм...» . . . . . . . . . . 45
«Төнлә төшләремә кереп...» . . . . . . . . . . . . . 46
«Хәзер инде килмәсәң дә була...» . . . . . . . . . . 46
«Мин синсез дә яши алам икән...» . . . . . . . . . . 47
«Язмышыма кереп калдың...» . . . . . . . . . . . . 47
«Кичер, синнән башка яши алам, диеп...» . . . . . . 48
Минем өчен бары шул җиткән . . . . . . . . . . . . 48
«Бармы җанның өзелмәгән...» . . . . . . . . . . . . 49
«Мин яраттым сине, хәтта онытып...» . . . . . . . . 50
«Үкенүдән, газап, сагышлардан...» . . . . . . . . . . 50
«Иделемә төшеп сулар алам...» . . . . . . . . . . . 51
«...Көз шул инде. Үтеп китте җәйләр...» . . . . . . 51
«Мәхәббәт юк җирдә — бары мәкер...» . . . . . . . 52
«Төне буе буран улый...» . . . . . . . . . . . . . . 53
«Кояш кына батып, ай калыккач...» . . . . . . . . . 53
«Кайчан гына килерсең син?..» . . . . . . . . . . . 54
«Мин сине Ходайдан сорап алдым...» . . . . . . . . 55
«Абау Аллам, уф инде!..» . . . . . . . . . . . . . . 56
«Без кабат очраштык...» . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Ярый әле, — дисең, — яшибез без...» . . . . . . . . 58
«Үзебез дә сизми калган...» . . . . . . . . . . . . . 59
«Кешеләрдән минем кемлегемне...» . . . . . . . . . 60
«— Яратма син, — дисең, — мине алай...» . . . . 61
«Укыйсың да кайчак шигырьләрем...» . . . . . . . 62

«Альбомымнан карточкалар карап...» . . . . . . . . . 62
«Бу җиһанда без тик икәү...» . . . . . . . . . . . . . 63
«Бу җәемне синең белән...» . . . . . . . . . . . . . . 64
«Син җәлләмә мине! Бу дөньяда...» . . . . . . . . . . 64
«Бәгырем» дип сиңа көн эчендә...» . . . . . . . . . . 65
«Назсыз кебек тоелсам да...» . . . . . . . . . . . . . 66
«Беләм: синең белән йоклап булмый...» . . . . . . . . 66
«Башымны җуеп яратам сине...» . . . . . . . . . . . 67
«Җаным телем-телем телгәләнә...» . . . . . . . . . . 67
«Өшеп киттем әле кинәт кенә...» . . . . . . . . . . . 68
«Көннәр буе сине уйлаганга...» . . . . . . . . . . . . 69
«Утырмале борының салындырып...» . . . . . . . . . 70
«Елый-елый таңга күзем ачтым...» . . . . . . . . . . 71
«...Сине болай сөю, беләм, гөнаһ...» . . . . . . . . . . 72
«Тормышыңа ямь өсти алмадым...» . . . . . . . . . . 74
«Ник шылтыратмадың?» — димә әле...» . . . . . . . 75
«Син нишлисең икән бу минутта?..» . . . . . . . . . . 76
«Хәлең ничек? — диеп, синнән никтер...» . . . . . . . 77
«Әйләнәсең дә китәсең...» . . . . . . . . . . . . . . . 78
«Әгәр һич уйламаганда...» . . . . . . . . . . . . . . 79
Кем белә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
«Сикереп кенә атланыр да идең...» . . . . . . . . . . 81
«...Син бар, мин бар, ул бар!..» . . . . . . . . . . . . 81
«Бу дөньядан туеп киттем әле...» . . . . . . . . . . . 82

**Мин дә бит бу фани дөнья колы**

«...Мин дә бит бу фани дөнья колы...» . . . . . . . . . 84
«Син минеке диеп хис итәм дә...» . . . . . . . . . . . 85
«Шундый рәхәт! Җәйге чыклы иртә...» . . . . . . . . 86
«Менә тагын җитте туган көнең...» . . . . . . . . . . 86
«Гөлләр алдым, суга салдым...» . . . . . . . . . . . . 87
«Бар иде шундый чакларым...» . . . . . . . . . . . . 88
«Гомер буе кара эштән башка...» . . . . . . . . . . . 89
«Бала чагым калды урманнарда...» . . . . . . . . . . 90
«Син бик бәхетле!» — дигәнгә...» . . . . . . . . . . . 90
«Китү авыр микән, калумы?» . . . . . . . . . . . . . 91
«Аек акыл белән сөям...» дим дә...» . . . . . . . . . 91
«Биек кенә тауның башларында...» . . . . . . . . . . 92
«...Берәүне мең күрсәң дә сөймисең...» . . . . . . . . 92
«Илле» диләр, «илле» диләр...» . . . . . . . . . . . . 93
«Әгәр кемдер берәр эштә...» . . . . . . . . . . . . . . 94
«Их, димен, яшьлектә туя...» . . . . . . . . . . . . . 95
«Житәр инде, диләр, сөеп арыдык...» . . . . . . . . . 96
«Билгеле бер яшькә җиткәч...» . . . . . . . . . . . . 96

«Мин хаклык эзләдем...» . . . . . . . . . . . . . . . 97
«Айның бүген җиденче кичәсе...» . . . . . . . . . . 98
«Юлдаш кирәк ерак юлга чыксаң...» . . . . . . . . . 98
«Киң офыкта шәфәкъ алсулана...» . . . . . . . . . . 99
«Мин юлларга карыйм. Шатлык килсә...» . . . . . 100
«Син көт кенә!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100
«Бер сәбәпсез ник елмаясың?!» — дип...» . . . . . 102
«Минем йөзгә ышанма син...» . . . . . . . . . . . . . 103
«Артык бәхетле булганда...» . . . . . . . . . . . . . 103
«Апрельдә мин гел башкача янам...» . . . . . . . . 104
«Пушкинның төшендә шигырь...» . . . . . . . . . . 104
«Зарлана да зарлана, дип...» . . . . . . . . . . . . 105
«Иң беренче каеннарга...» . . . . . . . . . . . . . . 106
«Яфрак очып керде тәрәзәмнән...» . . . . . . . . . . 107
«Кышын һич җылына алмыйм...» . . . . . . . . . . . 108
«Әллә ничек кенә үтте гомер...» . . . . . . . . . . . 108
Иделемә карыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
«Авыз-борыннарын каплап...» . . . . . . . . . . . . . 109
«Тып-тып... тып-тып...» . . . . . . . . . . . . . . . . 110
«Алмадай тулышкан бөреләр...» . . . . . . . . . . . 110
«Таң алдыннан сандугачлар...» . . . . . . . . . . . . 111
«Уелып төшәрдәй булам...» . . . . . . . . . . . . . . 112
Борын чөючеләргә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113
«Кешеләрнең нинди генә юк...» . . . . . . . . . . . . 114
«Нәрсә әле — без кешедән кимме?!» . . . . . . . . . 115
«Хәл дә сорый белми, диеп...» . . . . . . . . . . . . 115
«Кеше...» диеп, кеше тикшерергә...» . . . . . . . . . 116
«Ачулы кеше эчендә агу йөртә...» . . . . . . . . . . 117
«Озын халат киеп... икенче каттан...» . . . . . . . . 118
«Дөнья йөген ат шикелле...» . . . . . . . . . . . . . 119
«Әле һаман акыл кергәне юк...» . . . . . . . . . . . 120
«Тормыш тегермәне мине...» . . . . . . . . . . . . . 121
«Күңелемә ниләр булды икән?!» . . . . . . . . . . . 121
Га-җә-мәт! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
«...Билдән генә тотып алса иде!..» . . . . . . . . . . 124
«Яшәүмени — синә үз гомереңдә...» . . . . . . . . . 125
Бергәлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
«Бер шатлыгым булса, тирәсендә...» . . . . . . . . . 127
«Бу дөньяга газап дәрьясында...» . . . . . . . . . . 128
«Әнә генә — кул сузымы гына...» . . . . . . . . . . 129
«Әй дөнья, көйсез лә син...» . . . . . . . . . . . . . 130
«Җилләр исә Каф тау артларыннан...» . . . . . . . 130
«Кояш көткән чакта яңгыр ява...» . . . . . . . . . . 131
«Саумы, Шәмс?! Без бит бер тамырдан...» . . . . . . 132

«Кайсы яклап карасаң да...» . . . . . . . . . . . . . 132
«...Мин бер тапкыр яшәгәнмен инде...» . . . . . . . . 133
«Кеше гомере кызык кына икән...» . . . . . . . . . . 134
«Авыл җаны — шәһәрләрдә...» . . . . . . . . . . . . . 135
«Ач күзеңне — дөнья бу!» . . . . . . . . . . . . . . 136

## Ә туган як... Мәңге сагындырып, Бар җаныңны синең җирсетә

«Китеп барам ерак җиргә...» . . . . . . . . . . . . . 138
Туган нигез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
«Әйдә, дустым, кайтыйк әле...» . . . . . . . . . . . 140
«Гүзәл җирдә туып үссәм дә мин...» . . . . . . . . . 141
«Туган якка кайтып килим әле...» . . . . . . . . . . 142
«Бу дөньяда миннән бай кеше юк...» . . . . . . . . . 143
«Әнкәем!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
«Әнкәй, дүрт кыз арасыннан...» . . . . . . . . . . . 144
«Син әйтәсең, әнкәй: «Бик картайдым...» . . . . . . 145
«Кайларга җыендың, әнкәем...» . . . . . . . . . . . 146
«Инәкәем минем, йөрәк парәм...» . . . . . . . . . . 147
«Китмә әле, әнкәй, китә калсаң...» . . . . . . . . . . 148
«Бу дөньяда шактый хәсрәт чиктем...» . . . . . . . . 149
«Кайтсам-китсәм, нурлы йөзең белән...» . . . . . . 150
Хатирә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
«Әнкәй белән икәү чәй эчәбез...» . . . . . . . . . . 153
«Мин тартынам сиңа сыенырга...» . . . . . . . . . . 154
«Салмакланды йөрешләрем...» . . . . . . . . . . . . 155
«Бүләк иткән ак шәлемне, әнкәй...» . . . . . . . . . 156
«Киереп ач, әнкәй, капкаларны...» . . . . . . . . . . 157
«Бала чактан әнкәмнең бер сүзе...» . . . . . . . . . . 158

## Аклык юлдаш булсын безгә

«Бер улым, бер кызым иде...» . . . . . . . . . . . . 160
«Бөтен эшемне ташладым...» . . . . . . . . . . . . . 160
«Күрегезче бу Ходайны!» . . . . . . . . . . . . . . . 160
«Мактаныша хатын-кызлар...» . . . . . . . . . . . . 161
«Әй, ат җиктем, ат җиктем!..» . . . . . . . . . . . . 162
Улым бәбкә саклый . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
«Нәни әле минем онык — түмгәк кенә...» . . . . . . 164
«— Ник саргайдың болай? — дип сорамагыз...» . . . 165
«Кызым инде зур үсте...» . . . . . . . . . . . . . . . 166
«Кошлар бүген бала очыралар...» . . . . . . . . . . 166
«Кызым минем!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
«Элмир улым» диеп дәшәм сиңа...» . . . . . . . . . 168
«Давылларга каршы...» . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Назыймга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

«Малеевка урманында йөрим...» . . . . . . . . . . . 170
«Мин яраттым сине...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
«Ак күлмәгем күптән салдым инде...» . . . . . . . . 171
«Тере мәет кебек, берьялгызым...» . . . . . . . . . . . 172
Җуйдым сине . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
«Мин яраттым сине яшьлегемдә...» . . . . . . . . . . 174
«Йә, ничек анда хәлләр җиде күктә?..» . . . . . . . . 175
«Көзнең соңгы ае...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
«Көзнең соңгы ае. Көн уртасы...» . . . . . . . . . . . 179
«Яшел чирәм...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180
«Вак-вак кына басып...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Мең карадым, бер күрдем . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Казаныма мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
«Бүген Казан каласында...» . . . . . . . . . . . . . . 185
«Сез үзегез зур бер дәвер...» . . . . . . . . . . . . . . 186
«Илле яшьтә ирләр нинди була?..» . . . . . . . . . . 186
Боек булма, бөек бул! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
«Син — күңелнең рушандай ак көзгеседер...» . . . 188
«Юктыр, булмас!» дисәң дә...» . . . . . . . . . . . . 188
«Аһ, җаныем, Бибисара...» — дип...» . . . . . . . . . 189
Нигә һаман «Кайбыч...» дип язасың...» . . . . . . . 190
«Ничә еллар төшләремә кереп...» . . . . . . . . . . . 191
«Сыенып утыра Баулы...» . . . . . . . . . . . . . . . . 192
«Көн ягына карап юлга чыктым...» . . . . . . . . . . 193
«Тауларга сыенып...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Кемгә нәрсә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195
«Карлар ява, карлар ява...» . . . . . . . . . . . . . . . 196
«Тукталышта басып торам...» . . . . . . . . . . . . . . 197
«Бу тормышта ак һәм кара...» . . . . . . . . . . . . . 198
«Гомерләр тормый шул...» . . . . . . . . . . . . . . . . 199
«Су буенда — ап-ак казлар...» . . . . . . . . . . . . . 200
«Күңелемне назлап тора...» . . . . . . . . . . . . . . 201

Литературно-художественное издание

**Зигангирова** Шамсия Гатуфовна

**СВЕТЛАЯ ГРУСТЬ**

*Стихи*

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Җиһангирова** Шәмсия Гатуф кызы

**ЯКТЫ САГЫШ**

Шигырьләр

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *В.В.Фомин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.07.2006. Форматы $70\times90^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 7,61. Шартлы буяу-оттиск 7,90. Нәшер-хисап табагы 7,02. Тиражы 2000. Заказ З-578.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.